ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№4 (363)
АПРЕЛЬ 2022

НӘСЕЛ ҺӨНӘРЕНӘ ТУГРЫ АЛМАШ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

БУЫННАН БУЫНГА КҮЧКӘН ҺӨНӘР

Журналистлар, бер династиягә караган табиб, укытучы, төзүче һ.б. гаиләләрен данлап, династияләр турында язарга ярата... Чөнки гаиләдә, буыннар алмашын саклап, бер һөнәргә тугры калу бик кызык күренеш. Тик шул династияләр турында язучы журналистлар, читеге булмаган читекче кебек, үз һөнәрләрен таныту юнәлешендә эшләп җиткерми кебек. Бәлки шуңа да бүгенге көндә журналист һөнәре әллә ни популяр түгелдер?

Ә бит арабызда әти-әниләр, абый-апалар, балалар, оныклар – тулы бер династия булып, озак еллар дәвамында үзе сайлаган журналист һөнәренә тугры калып эшләүчеләр шактый. Һәр журналист гаиләсенең тарихы уникаль: аларны тыңлау үзенең төенләнеше, чишелеше һәм кульминациясе булган сериалны карауга тиң... Гомумән алганда, барысы да бик кызык һәм мавыктыргыч. Бүген сезгә геройларыбыз өчен балалары, оныклары һәм оныкчыкларында дәвам иткән иң кызыклы һөнәрләрнең берсе турында укырга тәкъдим итәбез. «Журналист династияләре» проекты әле дәвам итә, ул яңа геройлар белән тулылана бара.

Сезнең үз һөнәренә тугры редакциягез.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Гамирҗан Дәүләтшин, Илдус Заһидуллин,
Луиза Шарова
Фотограф: Анна Арахамия, Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: журналистлар династиясе вәкилләре
Зиннур Хәснияр һәм Зилә Фәйзуллина.
Анна Арахамия фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–0998
Басарга кул куелды: 08.04.2022
Басмадан чыкты: 14.04.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «Татарстан» журналына

\# Татарстанның 100 җәүһәре

\# бары тик Татарстанда

Вероника Тушнованың туган ягы

«Не отрекаются любя, ведь жизнь кончается не завтра…», «Сто часов счастья», «А знаешь, все еще будет…». Әлеге атаклы шигъри юлларның авторы Вероника Тушнова Казанда туып-үскән һәм яшәгән, бирелә ул беренче әсәрләрен язган…

Вероника 1911 елның 27 мартында дөньяга килә. Казанның борынгы урамнары, Шеланга дачалары аның өчен җандай якын урыннар була. Ветеринария институты профессоры Михаил Павлович Тушнов гаиләсе башта Зур Казан урамында (хәзерге Зур Кызыл урам), аннары Миславский урамында яши. Бу йортларның берсе дә безнең көннәргә кадәр сакланып калмаган. Әмма Бутлеров һәм Мөштәри урамнары чатындагы ГИДУВ бинасы әле дә бар – сугыш вакытында ул нейрохирургия госпитале була, анда палата табибы Вероника Тушнова яралыларны карый. Танылган «Не отрекаются любя…» шигырен исә ул бер ел соңрак, 1944 елда, Мәскәүдә ире белән аерылышу өчен борчылган-кайгырган чакта яза.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Санкцияләргә каршы – «цифра» белән
Маркетплейслар бизнесны ничек коткара

8. Кан тамчысы буенча куелган диагноз
Моны кайда эшләргә була

11. Хыялны тормышка ашыру сере
Уңышны программалаштырып буламы

15. Очучы-сынаучының йолдызлы мизгеле
Ни өчен саклык – каһарманлыкның төп сыйфаты

игелекле эшләр

24. ММЧ һәм буыннарның синергетик куәте
«Татмедиа»да күпме журналист династиясе эшли

28. Сюжетын фаразлап булмаган детектив, яисә
Ни өчен кешелеклелек эксклюзивтан мөһимрәк

32. «Номер кадагы» турында дәреслек
Зиннәтулла Билалетдинов кемнең үтенечен кире какмаган

36. Басма сүз фәлсәфәсе
Журналист белән су үткәрүче арасында нинди охшашлык бар

46. Репортер булырга беркайчан да соң түгел
Ни өчен яшь хәбәрче булырга кирәк

54. Марсель Зариповның нефте һәм балы
Журналистика аксакалының мавыгулары

мәңгелек кыйммәтләр

62. Тарих сәхифәләре
«Төньякта яшьнәгән бер нур»

66. Күк Алласы химаясендә
Борынгы болгарлар нәрсәгә ышаналар

80. Татар авыллары
Имәндәй нык Утыз Имән

86. Галәмне яулаган көн
Гагаринның үзен күргән кеше

88. Галәм белән элемтә
Яшь азнакайлылар космос белән ничек аралаша

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

22.03

Юрий Борисов, Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – Казанның С.П.Горбунов исемендәге авиация заводында:

– Казан, билгеле булганча, безнең Хәрби-һава көчләре өчен стратегик авиация буенча төп җитештерүче булып тора. Биредә барысы да план буенча бара. Җитештерү башлап җибәрергә әзерләр. Быел без бер модернизацияләнгән һәм тагын бер яңа Ту-160 самолетын күтәбез. Минемчә, биредә завод җитештерүне җайга салуга тулысынча әзерләнгән инде.

24.03

Гүзәл Хисаметдинова, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының җиңел сәнәгать бүлеге башлыгы:

– Кризисны беренче тапкыр гына кичермибез. Сүз дә юк, хәзер катлаулы чор, әмма бу мөмкинлекләр туган вакыт та. Чөнки чит ил компанияләре киткәннән соң, бездәге кием җитештерүчеләр алдында яңа мөмкинлекләр ачыла, һәм Татарстан предприятиеләре тулысынча диярлек Европа брендларын алыштыра ала.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

30.03

Илдар Гыйльметдинов, РФ Дәүләт Думасы депутаты, – «Иҗат аша тынычлык һәм бердәмлеккә – Творчество мира и согласия» студентлар төбәк этномәдәни фестивалендә җиңүчеләрне бүләкләгәндә:

– Хөрмәт, белем, аңлашу, башка мәдәниятkә, гореф-гадәтләргә ихтирам аша гына үз мәдәниятеңне саклап калырга мөмкин. Әлбәттә, туган телләр мөһим урынны алып тора. Тел булмаса, халык та юк. Безнең республикада туган телне өйрәнү һәм саклау өчен зур мөмкинлекләр тудырылган һәм тудырыла. Мондый фестиваль туган телеңне белүгә, өйрәнүгә омтылыш һәм кызыксыну уята, шундый ихтыяҗны тирәнәйтә. Бу бик мөһим. Теләсә нинди телгә кимсетүле карашның аяныч нәтиҗәләргә китерүен күреп торабыз.

Фото: Владислав Шатило, nazaccent.ru, rt-online.ru

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

акыллы гамәлләр

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Үсеш резервларын **КАЙДАН** табарга

Медицина фәне белән тәҗрибә берлеген **НИЧЕК** файдалырак итәргә

Уңышны **НИЧЕК** программалаштырырга

НИНДИ вертолёт санкцияләрдән дә курыкмый

БИЗНЕСНЫ ЦИФРЛЫ СӘҮДӘ КОТКАРА

Ольга Туманская

«Пандемия чоры» тәмамланырга өлгермәде, «санкцияләр эрасы» килеп җитте. Әлеге катлаулы заманда маркетплейс финанс нокаутларыннан сакланып калырга гына түгел, үсеш өчен резервлар табарга да ярдәм итә, дип саный Татарстан эшкуарлары.

Халыкның сатып алу сәләте кими, ә Татарстанның AMIRA бренды ихтыяҗны канәгатьләндерергә өлгерми. Менә шундый икътисади оксюморон. Бренд хуҗасы һәм дизайнер Лилия Җиһаншина фикеренчә, бу компаниянең электрон сәүдә мәйданчыгына чыгуы нәтиҗәсендә генә мөмкин булган.

– Без инде кирәкле продукция күләмен үз көчебез белән генә тегәргә өлгермибез. Әмма юлын таптык – ярты ел дәвамында безнең сәүдә маркасы белән эшләнмәләр тегү буенча берничә тегү производствосы белән килешүләр төзедек.

ИСӘНМЕ, САТЫП АЛУЧЫ!

Хәзер AMIRA бренды продукциясе Ozon, Wildberries, KazanExpress мәйданчыкларында тәкъдим ителә. Әмма алар үз эшләрен 2013 елда ук гади оффлайн-ноктадан башлый. Цифрлы сәүдә турында ул вакытта уйлап та карамыйлар әле – барысын да пандемия үзгәртә, компания кибетләренең бер өлешен ябарга мәҗбүр була.

– Эре маркетплейслар белән хезмәттәшлек итү сәүдә әйләнешен югалтмаска, производствода эш урыннарын һәм хезмәт хакын саклап калырга мөмкинлек бирде, – дип сөйли Лилия. – Алай гына да түгел, без ул вакытта ук бизнесны киңәйтү турында уйлана баш-

Фото: Александр Эшкинин

ладык. Әгәр элек киемнәребезне нигездә Татарстанда гына сатсак, электрон мәйданчыкка чыгу белән, товарыбызны бөтен ил күләмендә һәм аннан читтә дә сату мөмкинлеге туды.

Сүз уңаеннан, башта AMIRA бренды үзен хатын-кызлар өчен мөселман киеме тегүче буларак таныта. Әмма онлайн-мәйданчыкларда эшләү компаниянең максатчан аудиториясе киңрәк булуын күрсәтә. Ябык, әмма заманча модельләр һәркемнең күңеленә хуш килә – сатып алучының нинди конфессиядән булуына бәйсез рәвештә. Әйтик, тыйнаграк күлмәкләрне балалар бакчаларында эшләүче педагог һәм тәрбиячеләр яратып ала, чиста киҗе-мамык тукымадан тегелгән баш киемнәренә химиотерапия узучыларда ихтыяҗ бар.

– Үзебез өчен көтелмәгән сегментларны ачыкладык – маркетплейс безгә яңа кулланучыларны табарга булышты, – ди Лилия. – Һәм барысы да сатып алучы белән мизгел эчендә элемтә урнаштыру – җавап алу, реакция ясау мөмкинлеге нәтиҗәсендә. Шулай итеп, маркетплейслар базар таләпләренә җайлашырга, клиентларыбыз ихтыяҗын исәпкә алып эш итәргә мөмкинлек бирде.

Бүген, Лилия билгеләп үткәнчә, вазгыять шундый ки, төп ихтыяҗ арзанлы кием сегментына күчә. Шуңа күрә компанияләр базарның бу торышын үз бәяләрендә ныклап исәпкә ала. Яңа модель җитештерелә башлый икән, сатып алучының фикерен озак көтәргә туры килмәячәк. Аларга шулай ук җавап та бик тиз бирелә: ошамаган яклар төзәтелеп, складка илтелә торган яңа партиядә теләкләр инде исәпкә алынган була.

Хәер, электрон сәүдә чылбырындагы сыгылмалыкны сатучылар гына түгел, маркетплейслар үзләре дә күрсәтә.

– Бина милекчеләре аренда бәяләрен күтәргәндә (җитмәсә, оффлайн-сатулар кыскарган вакытта), шул ук Wildberries үз складларында товарны саклаган өчен түләү алмый башлады, – дип сөйли Лилия Җиһаншина. – Бүгенге катлаулы заманда электрон мәйданчыклар эшкуарларга ярдәм кулы суза, һәм без бу ярдәмне тоябыз.

Ozon компаниясендә, вазгыятьнең тотрыксыз булуына карамастан, күрелгән чаралар эшкуарларга актив сатуларны сакларга һәм сатып алу бәяләренең артуына җайлашырга булышырга тиеш, дип саныйлар. Март аенда кертелгән яңа чаралар арасында бер мәртәбә түләнә торган акчаны бүлеп түләүне кертү, иң популяр товарларны складларда түләүсез саклау, үз складларыннан яки интернет-витрина моделе буенча сатучыларга заказларны үтәү кагыйдәләрен йомшарту бар.

Сүз уңаеннан, Ozonда узган елда Татарстан сатучыларының саны, аннан алдагы ел белән чагыштырганда, 3,7 тапкырга арткан. Татарстан сатып алучылары да җирле бизнестан калышмый: төбәктә 2021 елда Ozonда сату, аннан алдагы ел белән чагыштырганда, 2 тапкырга, ә заказлар саны 2,8 мәртәбәгә арткан. Шул рәвешле маркетплейслар безнең өчен көндәлек сатып алу урынына, «өебездәге кибеткә» әверелә, дип әйтергә була. Моңа эре онлайн-мәйданчыклар тарафыннан зур акчалар кертелә торган логистика инфраструктурасы үсеше дә ярдәм итә. Әйтик, зур төбәк фулфилмент-үзәкләр, сортларга аеру үзәкләре һәм Ozonның заказларны кабул итү пунктлары җирле эшкуарларга товарларын маркетинг витринасына һәм клиентка китерүне тиз һәм уңайлы башкарырыга мөмкинлек бирә. Татарстанда Ozon инфраструктурасының бер өлеше Яшел Үзәндәге фулфилмент-үзәк, һәм бу республика халкына 1–2 көн эчендә 7 миллионнан артык товарны китерергә булыша. Эшкуарлар өчен мондый зур логистика хабы булу товарларны маркетплейска һәм сатып алучыга тагын да тизрәк китерергә, логистикада экономияләргә мөмкинлек тудыра.

АМЕРИКАДА – КУКМАРА ИТЕКЛӘРЕ

Kiez киез аяк киеме брендына нигез салучы Алмаз Габидуллин да үз товарына булган ихтыяҗны капларга көчкә өлгерә. Сезон инде ябык, ә ул киездән ясалган кыска балтырлы итек – валеши җитештерүне туктатып торырга уйламый да.

Сүз уңаеннан, Алмаз – Татарстанда электрон сәүдәнең чын пионеры. Ул цифрлы сату каналларын актив кулланып кына калмый, аларны Татарстан эшкуарлары арасында да популярлаштыра да.

– Иң мөһиме, маркетплейсларда бөтен эшкуар да тигез мөмкинлек ала, – ди ул. – Эре җитештерүче яисә үзмәшгуль сатамы – кем булуына да карамастан – виртуаль витринада товар бер рәткә баса.

Сүз уңаеннан, Алмаз Габидуллин икътисади дискриминациянең нәрсә икәнен үз җилкәсендә татыган. 2008 елда Кукмара эшкуары үзенең беренче бизнесы – лимонад җитештерүне оештыра. Тик эш авыр бара – кибет киштәләрендә дөнья брендлары белән көндәшлек итү җиңел булмый. Кибет хуҗаларының фикере дә куандырмый, янәсе, «брендны белмиләр!».

Алмаз үзенең яңа продукты – кыска балтырлы киез итекләр сатуны башлап җибәрә. Интернет-кибет ача, социаль челтәрләрдә активлаша. Бизнес үсә, әмма акрын. Барысы да Алмаз АКШка барып кайткач үзгәртә. Анда ул инглиз телен камилләштерергә дип бара, нәтиҗәдә тел өйрәнү белән бергә, сатуларны арттыру күнекмәләренә дә төшенә.

2021 ЕЛДА МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА ТАТАРСТАН СЕЛЛЕРЛАРЫНЫҢ (САТУЧЫЛАРЫНЫҢ) САНЫ 22 МЕҢНӘН АРТЫП КИТКӘН. 2020 ЕЛДА АЛАР НИБАРЫ ӨЧ МЕҢНӘН БЕРАЗ ГЫНА КҮБРӘК ИДЕ.

– АКШта мин электрон мәйданчыкларда аена 4 мең доллар эшләгән егет белән таныштым. Ул гап-гади студент иде! Ә мин тәҗрибә туплаган эшкуар булсам да, аның нәрсә икәнен дә белмим. Өйгә кайткач, теманы өйрәнә башладым. Бүген безнең продукция Россиянең барлык маркетплейсларында диярлек, AliExpressта тәкъдим ителә, өстәвенә, без дөньяның иң эре электрон коммерция мәйданы булган Amazonга чыгуның авыр һәм озын юлын уза алдык.

Маркетплейслар аша сату шулай ук Kiez бренды хуҗасының үз продукциясен сатып алырлык кешеләр турындагы фикерен дә үзгәртә. Көтмәгәндә ул үзе өчен яңа – җылы төбәкләрне ача! Израиль, хәтта кояшлы Португалиядә яшәүчеләр дә кыска итекләрне сатып ала башлый: көньяк белән төньяк алмашу куркынычы яный диярсең. Сәбәбе бик гади: бик эссе вакытта көньякта яшәүчеләрнең күбесе кондиционерларны эшләтә башлый. Бу вакытта боз кебек салкын таш идәндә Россиядә җитештерелгән кыска балтырлы киез итек яисә башмактан да яхшы нәрсә юклыгы ачыклана. Европалылар да мондый итекләрне яратып өлгерә. Алары исә сезон алмашу вакытында кияргә дип ала, чөнки экономия яраткан йорт идарәләре, белгәнебезчә, җылылыкны вакытында кушарга ашыкмый.

– Маркетплейсларда эшләүнең беренче елында ук безнең сату – ике, ә өч елда җиде тапкырга артты, – дип сөйли Алмаз. – Әйе, пандемия һәм санкцияләр үз төзәтмәләрен кертә, кайбер кыенлыклар тудыра, әмма бу проблемаларның күбесен хәл итеп була.

Алмаз Amazonга чыгу буенча әзерлек эшләрен узган елда ук тәмамларга өлгерә, бүген дә бу гаять зур базарны яулаудан баш тартмый. Беренче мәртәбә товарны экспортка чыгару уңышлы уза, сату әкрен генә бара, бренд үз рейтингын туплый. Хәзер Америка базары өчен этикеткалары инглиз телендә язылган яңа партия әзерләнә.

– Барысын да дөрес итеп, җентекләп эшләргә кирәк, чөнки анда көндәшлек коточкыч, әмма базар күләмнәре дә гаять зур. Бәхеткә, безнең продукциягә санкцияләр кагылмый. Өстәвенә, без компаниябезне Штатларда теркәргә өлгердек, аның аша эшли алабыз. Логистиканы хәл итәсе калды – товарны ничек илтеп җиткерергә. Башка берәр ил аша транзит беләнме, диңгез юлы беләнме – әлегә бу мәсьәләдә ачыклык юк.

Бүгенге көндә маркетплейсларда Татарстан селлерлары саны 22 меңнән артып китә. Әлбәттә, аларның барысы да Алмаз Габидуллин кебек инде күптәннән цифрлы базарда эшләми: 19 мең селлер электрон сәүдә мәйданчыгына узган елда гына аяк баскан. Татарстанның мондый виртуаль уңышының сәбәбе бик гади. Бу планлы эш нәтиҗәсе. 2021 елның мартында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча «Маркетплейс.Легко» электрон сәүдә үзәге оештырыла. Шуңа күрә Татарстанның һәр дүртенче селлеры электрон мәйданчыкларда әлеге үзәкнең ярдәме белән теркәлә, ул бүгенге көнгә кадәр уникаль оешма булып кала.

– Без Россиядә маркетплейсларга чыгарга теләгән эшкуарларга консультация бирү, алга таба да ярдәм итү буенча бушлай хезмәт күрсәтәбез, – дип сөйли «Маркетплейс.Легко» электрон сәүдә үзәге башкарма директоры Инесса Яруллина. – Безнең белгечләр инде 19 меңнән артык консультация күрсәтергә өлгерде. Башка төбәкләрдән дә мөрәҗәгатьләр бар. Әле шушы көннәрдә генә Краснодар крае эшкуарларыннан запрос килде, күптән түгел генә Карачай-Черкесиядән сәүдә-сәнәгать палатасы хезмәткәрләре белән тәҗрибә уртаклашу үтенече белән шалтыраттылар. Шулай да безнең өстенлекле бурычыбыз, әлбәттә, Татарстан эшкуарларына ярдәм күрсәтү.

Узган елны республика сатучылары гына түгел, ә KazanExpress электрон сату мәйданчыгы да гаять зур үсешкә ирешә. Хәзерге вакытта бу маркетплейста 17 меңгә якын сатучы теркәлгән, аларның 40 проценты – Татарстан эшкуары.

– 2021 елда без 542 процентка үстек, товар әйләнеше 9 млрд сумны тәшкил итте. Бер ел эчендә сатып алучылар 14 миллион заказ ясады (бу 2020 елга караганда 470 процентка күбрәк), – дип сөйли KazanExpressка нигез

салучы һәм аның генераль директоры Линар Хөснуллин. – Географиябезне шактый киңәйтә алдык: 92 яңа шәһәрдә ачылдык. Товар тапшыру пунктлары саны 73тән 450 гә кадәр артты. Базардагы бүгенге вазгыятькә без әзер. KazanExpressка нигез салынганнан бирле нәтиҗәлелеккә омтылабыз. Бездә заказны үтәү бәясе көндәшләрнекеннән 4-6 тапкырга арзанрак, шуңа күрә авыр заманны ныклы тотрыклылык белән үтү гарантияләнә. Бу хәзер Россия сатып алучысы өчен бик мөһим, дип саныйм.

КАШ ЯСАУ ТАРИХЫ

2020 елның гыйнварында Константин Заболотник эшсез кала: чираттагы бизнес-идеясе уңышсызлыкка юлыга, һәм эшкуар нәрсә белән шөгыльләнергә дип баш вата. Бу юлы Константинны маркетплейслар рухландыра – пандемия вакыты килеп җитә. «Быел Wildberriesта нинди төр товарга ихтыяҗ булачак?» Аналитиклар фикеренчә, матурлык тудыру кирәк-яраклары икән.

Константинның җыйган акчасы булмый, аның каравы 150 мең сумлык лимиты булган кредит картасы бар. Тик юкка гына эшкуарлык – акча янчыгы түгел, ә характер ныклыгы, димиләр бит.

– Без Wildberristа киемнән башларга булдык, – дип сөйли Заболотник. – Бер тегү фирмасын табып, үз брендыбыз белән беренче партиягә заказ бирдек. Бәхеткә, мондый стратегиянең безгә туры килмәвен бик тиз аңладык. Кием-салымны киеп карау ыгы-зыгысы сатучы өчен баш авыртуына һәм кирәкмәгән чыгымнарга китерә Алар аклансын өчен, товар югары маржалы булырга тиеш.

Кредит картасында әле 50 мең сум акча кала, Константин аларны каш ясау косметикасы җитештерүгә тотарга ниятли. Эшнең бу якка борылышы башкалар өчен көтелмәгән саналса да, сөйгәне каш ясарга өйрәтү мәктәбендә укыткан Заболотник өчен алай булмый. Идея дөрес булып чыга. Константин нигез салган TonyBrow бренды бер елдан да кимрәк вакыт эчендә ике башкаладан читтәге иң популяр төбәк косметика брендларының берсенә әверелә. Әйе, Заболотник барыбер – Wildberris, аннары – Ozon , «Яндекс.Маркет», бераз соңрак KazanExpress «йолдызы» булуга ирешә. Шул ук вакытта аның бизнесы кире әйләнешне дә күрсәтә – онлайн-сатулар ярдәмендә үсеш алган TonyBrowны бүген зур косметика оффлайн-ритейлерлары хезмәттәшлеккә чакыра.

– Күптән түгел продукциябез Л'Этуаль кибетендә сатыла башлады, – дип сөйли Константин. – Хәзерге көндә күп кенә чит ил компанияләре Россия базарыннан китә, шуңа күрә бу яктан безгә хәтта бераз җиңелрәк тә булды. Безнең төп производство Казанда урнашкан, башка шәһәрләрдә дә цехлар бар. Җирле чимал кулланабыз. Бүген санкцияләр һәм доллар аркасында туган бердәнбер проблема – Кытайдан сатып алына торган кайбер флаконнарга бәянең бераз артуы. Мөгаен, шул гынадыр. Әмма бу көндәшлеккә каршы торырлык бәяләрне саклап калырга комачауламый. Базар потенциалын күрәбез, шуңа күрә җитештерү һәм сату күләмнәрен арттырып, ныклы адымнар белән алга атлыйбыз.

Баштан ук үз брендының уңышын Константин маркетплейслар биргән мөмкинлекләр белән бәйли. Ул чакта базарны ныклап өйрәнеп, Заболотник сатып алучыга каш өчен сабын (!) тәкъдим иткән бердәнбер Россия җитештерүчесе була. Бизнес эшләп киткән мәлдә TonyBrowга төп керемне әлеге позиция китерә. Сатудан кергән акча, уңышны арттырып, башка төр продуктлар җитештерүгә тотыла.

– Билгеле бер продуктлар буенча без дистәләрчә ел базарда алдынгылыкны тоткан брендлар белән көндәшлек итә алдык. Бу эштә безгә маркетплейслар ярдәм итте. Беренчедән, без баштан ук тигез шартларда эшләдек. Өстәвенә, электрон сәүдә безгә сыгылмалы булырга – хаталарын тиз арада танырга һәм төзәтергә мөмкинлек бирде. Шулай бервакыт безнең рейтинг аска төшеп китте. Эш нидә? Сәбәбен сатып алучылар язган бәяләмәдән аңладык: базарга керткән яңа продуктыбыз «чи», ахырынача эшләнеп бетмәгән булып чыкты. Башка хаталар да булды, алар хакында да сатып алучылар фикере аша белдек. Хаталарны тиз арада төзәтү рейтингта югары урын билэргә, димәк, сатуны да арттырырга мөмкинлек тудырды.

– Әлегә Россия электрон мәйданчыкларына керү бик җиңел, әмма базар акрынлап байый бара, – дип кисәтә коллегаларын Татарстан маркетплейслары пионеры Алмаз Габидуллин. – Күз алдыгызга китерегез әле, Wildberriesта безнең кебек актив сатучылар – берничә дистә мең, ә Amazonда – миллионга якын! Катгый таләпләр куймыйча, мондый «армия» белән ничек идарә итәргә? Минемчә, бераз вакыт үткәннән соң, Россия электрон коммерция базарына керү җиңел булмаячак. Димәк, моны бүген эшләргә ашыгырга кирәк.

КАН ТАМЧЫСЫ БУЕНЧА КУЕЛГАН ДИАГНОЗ

Олеся Бондаревская

Татарстанда медицина фәнен практика белән бәйләүче платформа төзү буенча актив эш бара. Ул пациентлар өчен гаять файдалы булыр дип көтелә.

Кечкенә генә пластик пробирка тиз арада венадан алынган кан белән тула. Процедура биш минут эчендә башкарыла. Берничә миллилитр кан тикшерелгәннән соң үз хуҗасы турында барысын да сөйләячәк – аллергиядән алып яшәү дәвамында барлыкка килүе мөмкин булган җитди авыруларга кадәр. Нәтиҗәләр бердәм мәгълүмат базасында тупланачак. Әлеге нәтиҗәләрне һәм пациент өчен тәкъдим ителгән дәвалау тактикасын район поликлиникасы терапевты да таба алачак.

Әлеге идеяне гамәлгә ашырырга озак калмады. Бүген Казан федераль университеты галимнәре коллегалары һәм табибларга тәгаенләнгән ARACUS* платформасының беренче этабы буенча зур эш алып бара.

НӘСЕЛДӘНЛЕК ЧАГЫЛГАН ФАЙЛ

– Бүген фән бик зур күләмле мәгълүмат бирә. Без организмның һәр күзәнәген молекулаларга аера һәм анда барган бөтен процессны тасвирлый алабыз, – дип сөйли фәннәр кандидаты, PhD**, КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институтының өлкән фәнни хезмәткәре Регина Мифтахова. – Авыруны диагностикалау, дәва билгеләү, дәвалау стратегиясен эшләү өчен бу бик мөһим. Проблема шунда: табибның әлеге чи мәгълүмат белән эшләү өчен вакыты да җитми, алгоритмы да юк. КФУдагы прецизион*** һәм регенератив медицина фәнни-клиник үзәге базасында булдырылган проектның максаты – табибларга үз эшләрендә фәнни мәгълүматны максималь рәвештә куллану мөмкинлеге бирү.

Пациенттан алынган канны тикшерер өчен лабораториягә озаталар. Бирердә галимнәр омикс технологияләре ярдәмендә молекуляр дәрәҗәдә анализ ясый. Анализ организм турында тулы мәгълүмат бирә, авыруның барышын һәм нәтиҗәләрен фаразларга мөмкинлек бирә. Моңа геномны, ягъни кешенең төрле авыруларга

Фото: nkckfu.ru, iStock

* ARACUS (Analytical research and clinical University system) – АРАКУС (Аналитик-тикшерену һәм клиника системасы)
** PhD – Европа университетларында кандидат дәрәҗәсе
*** Югары төгәллек

бирешүчәнлегенә яисә аларга каршы тора алуына йогынты ясый торган нәселдәнлеге турында бөтен мәгълүмат тупланган ДНКлы «гомер китабын» тикшерену дә кирәк.

КФУ һәм «ДНК фәнни-тикшеренү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасының уртак проекты ике ел элек старт алган. Хәзер анда катнашучылар (галимнәр, табиблар, лаборатория хезмәткәрләре һәм онлайн-системаны эшләүчеләр) тарафыннан төрле авырулар, шулай ук контроль төркемне тәшкил итүче сәламәт кешеләр буенча бердәм мәгълүмат базасы төзелә. Базада тикшеренүләрдә катнашкан дүрт йөздән артык кеше турында мәгълүмат тупланган, проект ахырына алар меңнәрчә булачак. Аларның бер өлеше – КФУ клиникасы пациентлары, бер өлеше – ирекleләр. Проектка кушылганда, күпләр үзләрен сәламәт дип атый. Ләкин алга таба тикшеренүләр бу раслауларның бер өлеше, кызганычка каршы, ялгыш булуын күрсәтә. Катнашучыларның якынча чирегендә авыру яки аның башлануы билгеләре ачыклана.

– Без, мәсәлән, йөрәк-кан тамырлары авыруларының ничек баруын беләбез. Лабораториядә без, традицион күрсәткечләр (кан анализы, шикәр, холестерин, гормоннар һ.б.) белән беррәттән, авыруны китереп чыгару куркынычын арттыра торган ген мутацияләренең барлыгын, шулай ук йөрәк өчен зарарлы микроб эшчәнлеге продуктлары концентрациясен тикшерәбез, – ди фәннәр кандидаты, протеом тикшеренүләрнең дисциплинара үзәге өлкән фәнни хезмәткәре һәм үзәк директоры Татьяна Григорьева. – Анализлар исемлеге чир әле таралмаган, ләкин аның көчәю куркынычын арттыра торган халәткә бәя бирел булганда, ягъни мөмкин кадәр иртәрәк диагностикалау принцибы буенча сайлап алына. Мәсәлән, холестеринның күтәрелүе кебек күрсәткечне алыйк. Әгәр без даими рәвештә анализ биреп, «күзәтүләр көндәлеге» алып барсак, холестеринның акрынлап артуын сизәр идек. Әмма мондый җаваплылык бик сирәкләрдә генә очрый. ARACUS үзенең эшләнеп беткән формасында поликлиника яисә хастаханә терапевтына анализ нәтиҗәләрен базага кертү һәм процессны динамикада күрү мөмкинлеге бирәчәк.

АЛДАН АЧЫКЛАУ КОТКАРУ ДИГӘН СҮЗ

КФУ галимнәре вакытны узып, алга китеп эшли. Биредә Сәламәтлек саклау министрлыгы тәкъдим иткән тикшеренүләрдән тыш, якын киләчәктә әлеге хупланган исемлеккә кертелергә мөмкин булганнары да үткәрелә. Эчәклек микробиотасы, ягъни бактерияләренең кешенең сәламәтлегенә йогынты ясавы турында галимнәр күптән белә, тик тәҗрибәдә белгечләрнең кайберләре генә дәва билгеләгәндә моны игътибарга ала.

– Бер кешенең микробиомында триллионлап бактерия исәпләнә. Ул һәркем өчен уникаль. Бактерияләр нәрсә ашыйбыз, шуның белән туклана: углевод, аксым һәм майлар. Алар боларның барысын да тормыш эшчәнлеге продуктлары – метаболитлар бүлеп чыгарып эшкәртә. Метаболитлар организмның төрле системалары эшенә, шул исәптән эчәклекнең үзенә дә йогынты ясый. Эчәклек ялкынсынганда бактерияләр составы тулысынча үзгәрә. Мәсәлән, сәламәт эчәклектә өстенлек иткән фирмикутлар тибы бактероид тип белән алмашына. Файдалы бактерияләр (пробиотиклар) эчәклекнең лайлалы катын саклый торган метаболитлар эшләп чыгара һәм организмның барлык органнары һәм системалары өчен мөһим булып тора. Димәк, эчәклекнең бактериаль балансын торгыза алсак, организмны савыктырырга ярдәм итәчәкбез, – ди биология фәннәре кандидаты, үзәкнең өлкән фәнни хезмәткәре Аида Габделхакова. – Әлеге базада без сәламәт кешеләрнең һәм төрле авырулары булган пациентларның профильләрен формалаштырабыз.

Алга таба пациентның анализларын «дөрес»ләре белән чагыштырып карау гастроэнтерологка яки нутрициологка үзгәрешләр башлануын ачыкларга һәм, чир көчәеп киткәнче, тиешле микробиотны торгызырга ярдәм итәчәк. Кайбер очракларда эчәклектәге бактерияләр глютен яки лактозаны кабул итә алмау кебек симптомның килеп чыгуына йогынты ясый. Кеше бу турыда белмәскә һәм үзенә ярамаган продуктларны куллануны дәвам итәргә, аллергия, хәленең начараюы сәбәпләрен аңлый алмаска мөмкин. Асылда, тормышыбызның сыйфаты күп очракта микробиомның саулыгына бәйле.

Бер кешенең микробиомында триллионлап бактерия исәпләнә. Ул һәркем өчен уникаль.



Мондый базаны булдыру тәҗрибәгә яңа дәвалау алымнары кертергә ярдәм итәчәк.



Организмга глютенның ярамавын, шулай ук башка күп кенә авыруларның, шул исәптән нейродегенератив һәм онкологик чирләрнең килеп чыгуын билгели торган тагын бер фактор – нәсел буенча бирелә торган «ватылган» генны, мутацияне йөртү. Проектта катнашучыларның якынча дүрттән бер өлешенә диагнозлар нәселдән бирелгән. Сүз уңаеннан, иң киң таралган авырулар буенча генетик скринингны үзәктә түләүле узарга мөмкин, бу процедурага чират юк.

– Кешеләрнең кайчагында нәселдән бирелә торган авыруларны ачыкламаска тырышуын аңлап булмый. Алдан белеп тору, вакытында күреп калып чаралар күрү авыру нәтиҗәләре белән көрәшүгә караганда күпкә нәтиҗәлерәк бит. Ел саен Россиядә 600 мең кешегә онкология диагнозы куялар, шуларның 300 меңгә якыны үлә, – ди проект эксперты, табиб-онколог Әлфия Нестерова. – Бүгенге мәгълүматларга караганда, онкология авыруларының 15%ы нәсел буенча бирелә. Аларның кайберләрен әлегә дәвалап булмый, ләкин, мәсәлән, иң киң таралган сөт бизе яман шешен дәвалау буенча бик күп тактика эшләнгән, алар пациентның гомерен һәм сәламәтлеген саклап калырга мөмкинлек бирә.

Табиб билгеләп үткәнчә, бүген яман шешнең күп төрләре өчен таргет терапиясе эшләнгән. Химиотерапиядән аермалы буларак, бу вакытта дәвалау препараты зарарланган күзәнәккә генә тәэсир итә, сәламәтләренә тими. Үзәк белгечләре таргет препаратын сайлауны тизләтүче яман шеш күзәнәкләрен тикшерәләр. Әгәр инде эшләнгән препаратларның берсе дә аңа туры килми икән, бу очракта пациент онкологиянең башка төрләрен дәвалау өчен тест рәвешендә үткәрелә торган клиник тикшеренүдә катнаша ала.

Проектта катнашучыларның барысы да үзәк галимнәре һәм табиблары күзәтүендә. Алар турында яңа мәгълүмат базага кертелә бара. Инде тест рәвешендәге интерфейс эшләнгән. Аның ярдәмендә үзәк белгечләре үзләренә кирәкле критерийлар буенча базадагы мәгълүмат белән тиз арада таныша ала. Болардан тыш, базаны булдыру тәҗрибәгә яңа дәвалау алымнары кертергә ярдәм итәчәк. Алынган мәгълүматның бер өлеше КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты студентлары лекцияләренә кертелгән инде. Мәгълүмат җыю этабы тәмамланганнан соң, ARACUS нейрочелтәргә тоташтырылачак. Ул туплангannарны тиз арада анализлап, табиб өчен пациентның хәле, дәвалау ысуллары һәм башка кирәкле параметрлар буенча мәгълүмат формалаштырачак. Бу табибка төшкән эш йөкләнешен берничә тапкырга киметергә, диагностиканы тизләтергә ярдәм итәчәк һәм ахыр чиктә күпме кешенең гомерен саклап калачак. Регина Мифтахова сүзләренә караганда, КФУ клиникасы белгечләре инде бер елдан соң ук тест режимында әлеге платформага таянып эшли башлаячак.

«КОСМИК» МӨМКИНЛЕКЛӘР МӘКТӘБЕ

Фотолар Казандагы Инженерлык лицееннан алынды. РЕКЛАМА

Бүген һәр ата-ана баласының бердәм дәүләт имтиханнарын да яхшы тапшыруы, шул ук вакытта белемгә омтылышның да кимемәве турында хыяллана. Әлеге хыялны гамәлгә ашыру серен безгә Казан шәһәрендә урнашкан Инженерлык лицеенда ачтылар.

– Бүген һава торышы ничегрәк? Урамдагы һава температурасын үлчә зинһар, – дип үтенә ноутбук экранында пәйда булган Науpаша исемле малай. Балалар ноутбукка тоташтырылган тапшыргычны урам ягында тотып тора алсын өчен, педагог тәрәзәне ача.

– Шәп икән! Үземнең киберәтем белән һава суларга чыгып керим әле, – дип хәбәр итә Науpаша. – Сүз уңаеннан, температура градусларда үлчәнә. Бер градус – бик кечкенә берәмлек, син аны хәтта тоймыйсың да.

Науpаша – цифрлы лабораториянең анимацияле гиды. Аның ярдәмендә балалар табигать фәннәре нигезләре белән таныша. Мондый әзерлекне үткән балага зуррак сыйныфларда физика, химия, биология, астрономия кебек дәресләрдә бирелгән материалны үзләштерү күпкә җиңел булачак. Без сөйләгән цифрлы лабораторияне Казандагы «Лицей – инженерлык үзәге» үзенең Smart Kids балалар бакчасында ачкан. Күп кенә Казан балалары өчен белем, ачышлар һәм үз уңышлары иленә сәяхәт нәкъ менә биредән башлана.

УҢЫШНЫ ПРОГРАММАЛАШТЫРЫП

Балалар бакчасын, башлангыч, урта һәм өлкән сыйныфлы мәктәпләрне үз эченә алган лицей Казанда 2016 елда ачыла. Уку программасына Федераль дәүләт белем бирү стандартларында билгеләнгән гомум белем бирү предметлары һәм һәр укучы өчен мәҗбүри булган өстәмә түләүле дәресләр керә. Шул рәвешле лицей: а) баланы әйләнә-

тирә дөньяда һәм һөнәри яктан динамик үсешкә, б) БДИга әзерләү кебек гаять катлаулы бурычларны уңышлы хәл итә. Лицей директоры Венера Хәйретдинова да, мәктәп укытучылары да – һәрдаим үз белем-күнекмәләрен камилләштерергә омтылучы чын профессионаллар.

Өстәмә дәресләр исемлеге 2024 елга кадәр Лицейны үстерү стратегиясе нигезендә Татарстан техник вузлары вәкилләре фикеренә таянып формалаштырылган. Өстәмә белем бирү программаларының фәнни җитәкчеләре – ТИСБИ ректоры, КМТТУ-КАИ экс-проректоры Алексей Лопатин һәм икътисад фәннәре докторы, профессор Венера Вәгыйзова. Өстәмә белем бирү компонентларына әйберләр интернеты, программалаштыру, инглиз теле, физика һәм математика буенча махсус курслар, табигать фәннәре керә. Лицей инженерлык юнәлешенә караганга, биредә заманча технологияләргә зур игътибар бирелә. Укучыларның Scratch, Python яисә Java кебек программаларны, графика дизайны, 3D-модельләштерү, Raspberry Pi, Arduino платформалары белән эшләү, электроника, челтәр админлаштыруын һәм башка юнәлешләрне өйрәнү мөмкинлеге бар.

Беренче карашка лицей системасы шактый кырыс һәм академик күренә. Ә гамәлдә – бу акыллы, мавыгучан, энергияле һәм бик уңай дулкынга корылган укучылар һәм укытучылар коллаборациясе.

«Казанда ничә кеше яши?» – дип сорый программа инглиз телендә. Без телдән, шулай ук инглизчә җавап бирәбез. «Татарстан составына ничә муниципаль район керә?» – дип дәвам итә программа. Һәм тагын шундыйрак берничә сорау. Тест тәмамланганнан соң безгә туган төбәгебез икътисады турындагы белемнәребезне ныгытырга киңәш бирелә. Инглиз телен өйрәнү буенча әлеге тренажерны 15 яшьлек **Әмирә Нәбиуллина** уйлап тапкан. Ул лицейда беренче сыйныфтан ук укый, инглиз һәм немец телләрен, шулай ук Python программалаштыру телен үзләштергән.

– Миңа техник фәннәр дә, лингвистика да ошый, шуңа күрә мин аларны бер проектка берләштерергә уйладым. Минем тренажер чит сөйләмне кабул итүне, аралашу күнекмәләрен ныгытуны һәм илләр турында белемнәрне тирәнәйтүне бергә үстерү мөмкинлеге тудырыр өчен уйлап табылды, – дип аңлата Әмирә. Аның көндәлек режимында – тугыз дәрес, әмма кыз моны артык күп дип санамый.

– Уку белән беррәттән белемеңне үзең уйлап тапкан эшләнмәңдә кулланып карау бик мавыктыргыч процесс. Лицейда бик җылы мохит, укучы һәм укытучы бер дулкында. Барысы да һәрвакыт ярдәм итәргә, аңлатырга әзер, – ди Әмирә. – Моннан тыш, без гел олимпиадаларда, укучылар өчен оештырылган төбәк һәм федераль проектларда катнашабыз, призлы урыннар яулыйбыз. Бу шулай ук зур этәргеч.

Уку барышында һәр укучының үз проектын уйлап табу идеясе – төп бурычларның берсе. Мондый якын килү балаларга эзләнү, нәтиҗәләрне бәяләү, киң аудитория каршында проектыңны яклау күнекмәләрен үзләштерергә ярдәм итә. Күп кенә укучылар, шул исәптән бишенче, алтынчы сыйныфларда, үз эшләрен чит телдә (инглиз, немец) язалар. Сүз уңаеннан, гомум белем бирү предметларының берничәсе инглиз телендә алып барыла. Балалар телне балалар бакчасыннан ук өйрәнгәнгә, урта мәктәптә алалар инде



тиешле лексиканы да, сөйләшү күнекмәләрен дә үзләштергән була.

Проектларны яклау өчен лицей чын фәнни конференцияләр үткәрә – С. П. Королев исемендәге Төбәкара проектлар конференциясе һәм «М. П. Симонов исемендәге кышкы укулар» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе. Конференцияләрдә лицеистлар белән бергә, Россиянең башка төбәкләрендәге һәм БДБ илләрендәге юнәлешле белем бирү оешмаларында укучы балалар катнаша. Иң яхшы дип табылган эшләрне гамәлгә ашыру өчен грантлар тапшырыла.

ЛИЦЕЙДАН – ОРБИТАГА

Үз проектларын гамәлгә ашыру өчен финанслар эзләү принцибы шулай ук уку процессында үзләштерелә. Кемдер халыкара конкурсларда катнаша һәм чит илгә укырга китә, кемдер «Сириус» Фәнни-технология университетының федераль конкурсларында ота, кемдер Татарстандагы Талантлар университеты студенты булуга ирешә һәм үзенең эшкәртмәләрен шунда яклый. Ә кемдер барысын да бергә эшләргә өлгерә.

– Мин ракета двигателенең лазер тибындагы прицipиаль яңа төрен ясау белән шөгыльләнәм, – дип сөйли 16 яшьлек **Ринель Җамалиев**. КМТТУ-КАИның ракета двигательләре кафедрасы доценты җитәкчелегендә укучы стендлы макет төзи. Үз проектына грантны Ринель Талантлар университеты студенты булгач ала.

– Ринельның проекты аэрокосмик юнәлеш буенча өстәмә технобелем бирү темасына органик рәвештә кереп китә. Бишенче-алтынчы сыйныф укучылары иярчен-кубсат (CubeSat Cube Satellite, кубик иярчен) төзиләр, ул әлеге дә баягы двигательгә урнаштырылачак. Әлеге эшкә КМТТУ-КАИның Авиация, җир өсте транспорты һәм энергетика институтының реактив двигательләр һәм энергетика җайланмалары кафедрасы профессоры Альберт Саттаров җитәкчелек итә.

– Без орбитага чыгару өчен иярченне «Роскосмос»ка тапшырырга ниятлибез. Берничә ел дәвамында иярчен безгә һәм профессор Саттаровка лазерлы водородлы двигателенең ничек эшләве турында хәбәр җиткереп торачак. Моннан тыш, без иярченгә орбитадан Җирнең фотосурәтләрен юллап торырга ярдәм итәргә тиешле камераны камилләштерү белән шөгыльләнәбез. Һәм шулай ук «Лицей – инженерлык үзәге» – очышлар белән идарә итү үзәген (ОИҮ) төзибез. Беренче адым ясалды. Space л проектын оештыручы

КМТТУ-КАИның ракета двигательләре кафедрасы доценты җитәкчелегендә Ринель Җамалиев (фотода унда) стендлы макет ясау белән шөгыльләнә.

«Лицей – инженерлык үзәге» Очышлар белән идарә итү үзәге тарафыннан иярченнең Татарстан өстеннән очкан вакытында алынган сурәт.

һәм кураторы Иван Бортник* безне энтузиаст-радиосөюче Дмитрий Пашков җитәкчелегендәге Рузаевка (Мордовия Республикасы) командасы белән таныштырды. Дмитрий безгә элемтә антеннасы ясарга һәм шуларның беренчесен лицей түбәсенә беркетергә ярдәм итте. Үзәк метеорология иярченнәреннән фотосурәтләрне кабул итә башлады. Очышлар белән идарә үзәге алга таба да безгә укучыларыбыз арасында аэрокосмос темасын популярлаштырырга ярдәм итәчәк. Моннан тыш, ул безнең укучыларга үзләре үк ясаган иярченнәр белән эшләү өчен төп үзәк булып тора. Киләчәктә без башка мәктәпләрдәге ОИҮ белән бергә уртак элемтә антенналары челтәре төзергә уйлыйбыз, бу вакытта Россиянең төрле почмакларында яшәүче укучылар илебез өстеннән очкан иярчен аша төрле очыш нокталарыннан мәгълүмат ала алыр идек, – ди Кайзерслаутерн Техник университетын тәмамлаган, «Радиотехника» белгечлеге буенча Германия – Россия Яңа технологияләр институты магистры, лицей директоры урынбасары Никита Ильин. Лицейда Никита Александрович Python, Java, Unity телләрендә программалаштыру, Kerbal Space Program, инглиз телендә Internet of Things дәресләрен алып бара, системалы админлаштыруны, мехатрониканы өйрәтә.

Педагог сүзләренә караганда, кубсатны төзеп бетерү өчен корпус детальләре генә җитеп бетми. Кубсатны космик корабль бортына алсыннар өчен, корпус билгеле бер үлчәмнәргә туры килергә тиеш. Лицей корпус ясауга заказ бирергә ярдәм итә алырлык иганәчене эзли. Корпусның эчке өлешен тулысынча диярлек балалар үзләре төзегән. Лицейда менә дигән хакпейслар – слесарьлык, радиомонтажлау, фрезерлык, электрон җиһазлар урнаштырылган лабораторияләр бар. Моннан тыш, лицей челтәрле админлаштыру һәм әйберләр интернеты буенча WorldSkills компетенцияләр үзәге статусына ия. Берничә укучы республика җыелма командасына керә һәм һәр чемпионаттан медальләр алып кайта.

– Лицей – «Сириус» яисә «Орленок»ның белем бирү сменалары кебек мөһим федераль проектларга әзерләнү һәм аларга әләгү мөмкинлеге бирә торган мәйданчык. Безнең укучылар бөтенроссия олимпиадаларында катнаша, җиңә һәм сайлаган вузларга конкурстан тыш керүгә ирешә. Ләкин иң мөһиме – алар гел яңалыкка омтыла. Безнең хәтта кышкы һәм җәйге каникулларга исәпләнгән программаларыбыз да бар – укучылар ике атнага республика белем бирү лагерьларына бара, – дип сөйли өстәмә белем буенча лицей директоры урынбасары Руфинә Дәүләтбаева.

Укучылар кебек үк лицей укытучылары да ирешелгәннәрдә туктап калырга яратмый. Менә инде дүрт ел дәвамында алар КМТТУ-КАИ укытучылары белән бергә «Инженерлык республикасы» проектын алып бара. Атнага бер мәртәбә укытучылар Балтач, Лаеш, Биектау, Балык Бистәсе һәм Кукмара районнарына барып, Казанда уку мөмкинлеге булмаган балалар өчен дәресләр үткәрәләр. Татарстанда яшәүче һәр баланың лаеклы һәм перспективалы белем алу мөмкинлеге булырга тиеш.

** Иван Бортник – Россия галиме, Россиянең инновацияле төбәкләре ассоциациясенең Күзәтчелек советы әгъзасы, Югары икътисад мәктәбенең инновацияләр менеджменты кафедрасы профессоры*

СЫНАУЧЫ РУСЕЦКИЙНЫҢ ЙОЛДЫЗЛЫ МИЗГЕЛЕ

Әскәр Сабиров

Бу көнне ул очкычка иң чик режимда сынау уздыра. Аны пикега төшереп җибәргәндә, очышның унберенче минуты бара. Шулвакыт сигнал килә: «Сул двигательдә янгын!» Карар кылу өчен күпме вакыт бар? Бөтенләй юк...

Виктор Русецкий вертолетны коткарып кала. Янгын сүндерү системасын кушарга өлгереп, боралакны пикедан чыгара. Мәйданчык табып, очкычны җиргә утырта – боларны хәл итүгә берничә секунд җитә.

– Нинди гадәттән тыш хәл булсын инде, көндәлек эштә килеп чыга ала торган нәрсә, – ди Виктор. – Яңа техникада кайсыдыр җиһазның эштән чыгу очраклары булгалый. Әмма инструкцияләр бар, барысы да төгәл язып куелган. Безнең эш – хәлнең катлаулыгын чамалап, дөрес карар кабул итү. Һәм барысы да тиз арада, төгәл башкарылырга тиеш.

Бу вакыйганың нечкәлекләрен инженерлар тикшерә. Металлдагы ярык аша двигательнең бүлегенә кызган газлар кергәнлеге ачыклана. Пилот карар кабул итүне бераз гына тоткарласа да, янгынны сүндереп булмаган булыр иде... Ләкин очучы югалып калмый – вертолетны саклап кала.

Язмабыз каһарманы белән таныштырыр вакыт. Рәхим итегез, Виктор Русецкий, вертолет йөртүче, Россиянең атказанган очучысынаучысы. Сынаучы кеше оча торган бөтен нәрсәдә дә, хәтта очмый торганнарында да оча белергә тиеш (бераз кыенлык белән булса да!) – әлеге канатлы гыйбарә нәкъ менә Русецкий кебек кешеләр турында.

Шәп әйтелгәнме? Матур. Әмма бигүк төгәл түгел, дип төзәтә Русецкий. Чынлыкта катлаулырак. Оча алмый торган нәрсәне күккә күтәрүнең мәгънәсе юк. Машина өметле, аның киләчәге бар икән – икенче мәсьәлә. Баштагы мәлдә бераз киреләнсә дә, чиле-пешлерәк булса да. Менә аны очарга өйрәтү исә, дөрестән дә, чын сынаучы өчен эш.

Юктан бар итеп, нульдән башлап уйлап чыгарылган машинаны күккә күтәргән һәм аны серияле җитештерүгә кадәр җиткерә алган очучыларны бармак белән санарлык. Бәхет кошын эләктерүче алар. Русецкий да шулар исәбендә.

Фото: testpilot.ru, PROKAZAN.RU

БЕРЕНЧЕ ОЧЫШ ЭССЕЛЕГЕ

1999 елның 17 августы. Аның йолдызлы сәгате. Әлегә иseme дә юк очкычны үләнгә тәгәрәтеп алып чыгалар. Калаклары һаваны яра, фюзеляж дер калтырана. Руль токтасын үзенә тартасың да, боралак югары күтәрелә! Җирдән аерылып киткәч, алты метр биеклектә машина, уйланып калгандай, бераз эленеп тора. Аннары сак-сак кына, әйтерсең, капшый-капшый гына, унга таба бер адым ясый. Аннары тагын берне – бу юлы инде сулга. Алга...

Читтән һавада очу буенча гап-гади дәрес кебек күренә, чынлыкта – сенсация. Икенче көнне Жуковскийдагы МАКС авиасалонында Eurocopter белән сөйләшүләр алдыннан, Казан вертолет заводы делегациясе яңа җиңел вертолетның беренче очышы яздырылган кассетаны күрсәтә. Французлар телсез кала, сөйләшүләр кичектерелә...

– Аларга алга таба үзләрен ничек тотарга тиешлекләрен аңларга кирәк иде, – дип сөйли ул вакытта Казан вертолет заводы директоры Александр Лаврентьев. – Россиядә җимереклек хөкем сөрә, авиациядә нинди дер өметле нәрсә ясау мөмкинлеге турында күз алдына да китереп булмый. Шул вакытта Казанда һавага яңа машина күтәрәләр. Бәясе турында сорагач, аналогларыннан бер ярым тапкыр арзанрак торуын әйтәбез. Алар арзанрак бәягә вертолет ясаган көндәш пәйда булуын аңлады. Кәгазьдә генә түгел – боралак инде оча да ала!

Аның ничек очканлыгын әлегә Русецкий гына аңлый. Беренче вертолет командаларны үтәргә ашыкмый, салонда калтырау – трактордагы кебек. Гади пилотны командир урынына утыртсаң, йөртә алуы бик икеле. Ләкин идарә Русецкий кулында. Дөрес, кыска гына беренче очыштан соң комбинезонны сыгып алырлык була...

– Эссе иде, – дип тыйнак кына аңлата сынаучы. – Җәй бит...

Мәскәүдәге гражданнар авиациясенең очу-сынау үзәге методистлары «АНСАТ»ның беренче очышына һич тә рөхсәт бирергә теләмәгән, диләр. Алар үзләренә чигенер юл калдыра. Машинаны күтәрәсез икән, менә шунда карарбыз, янәсе. Тик кемдер тәвәккәлләргә тиеш бит?

Виктор Михайлович Русецкий. Россия Федерациясенең атказанган очучы-сынаучысы. 2000 елда, Дәүләтара авиация комитеты президиумы карары белән, әйдәп баручы очучы-сынаучы буларак, «Ансат»ка очу-конструкторлык сынаулары үткәрү өчен сертификат ала. Машинаның потенциаль мөмкинлекләрен яхшырткан күп кенә конструктив тәкъдимнәр кертә. Аның тарафыннан сынаулар комплексы уңышлы тәмамлану нәтиҗәсендә, МАК авиарегистры тибындагы сертификат алына, бу исә Казан вертолет заводына күпмаксатлы җиңел вертолетны 2004 елның декабреннән сериялəп җитештерә башларга мөмкинлек бирә.

НЕПАЛГА ЮЛ ТОТКАНДА

Тәвәккәллек дигән сүзгә сынаучыларның артык исе китми. Бу уңайдан алар арасында тагын бер канатлы гыйбарә йөри: «Әгәр очышка кузгалганда пилот батырлык кылырга барам, дип уйлый икән, димәк, ул очышка әзер түгел». Моның белән Русецкий да килешә. Эштә иң мөһиме – профессиональлек, дип саный ул. Аның фикеренчә, юләр тәвәккәллек, кирәкмәгәндә үзеңне куркыныч астына кую – башсыз блогерлар шөгыле.

Шулай да яңа машинаны тәвәккәлләмичә генә очарга өйрәтеп булмый. Ә очышка әзерлек асылда гомер буе, һәр көн бара. 90 нчы елларда Русецкий төркем башлыгы була, аларга ике «Ми-8» вертолетын Непалга илтергә кушалар. Барасы аэропорт тарлавыкта урнашкан, бары көндез генә ачыла. Ә безнекеләр өчен Һиндстаннан анда кадәр көн яктысында берничек тә барып җитәрлек түгел.

– Бик катлаулы аэродром, – дип искә ала Русецкий. – Боралакны утырту процессы 20 чакрым алдан башлана, биеклек – дүрт мең метр, ә тау-кыялар – кул сузымында гына. Хәер, барыбер төшеп утыра алдык...

Соңыннан гына Викторның вертолетны монда төнлә утырта алган беренче пилот булуы ачыклана.

«Непал» вакыйгасы чит күзләрдән еракта була, ә менә Ле Бурже яки Фарнборода дөньякүләм авиашоу турында һич тә алай дип әйтә алмыйсың. Анда исә Русецкий, «Ми-17»нең һавада нәрсәгә сәләтле булуын күрсәтеп, рәхәтләнеп оча. Финляндиядәге күргәзмәдә дә эссе була.

– Без анда америкалылар белән ярыштык, – дип сөйли Виктор. – Алар – «Блэк Хоук», без «Ми-8МТВ-5» боралагында. Җитди көрәш булды. Кем җиңдеме? Ә синеңчә ничек? Бер елдан Парижга, Ле Бурҗега килгәч, ни күрик – америкалылар безнең программа элементларын күрсәтә. Яхшы укучылар булып чыктылар, бер ел эчендә күпме яңа нәрсә үзләштергәннәр...

Русецкийның Фарнборо яки Ле Буржеда ничек очканын күрмәдем. Ә менә Казан янында, «Сигезле» вертолетны кулланучыларның ел саен үткәрелә торган форумында ниләр эшләгәнен берничә тапкыр күзәттем: искиткеч! Миль вертолетларының хәленнән килмәгән нәрсә юк дигән хис туа. Күктәге һәр элемент ультра-си катлаулыгында! Һәм берсеннән-берсе куркынычрак.

– Бернинди куркыныч та юк, – дип килешмәвен белдерә Русецкий. – Машинаның нәрсәгә сәләтле икәнлеген белү генә таләп ителә. Аңа үзенең өстенлекле якларын күрсәтергә ярдәм итәргә генә кирәк.

Кызганыч, Казанда эксплуатантлар форумы бүтән үткәрелми. Русецкийның күрсәтмә очышларыннан соң вертолетлар берничә тапкыр күбрәк сатылган, дип сөйлиләр...

СИЗГЕРЛЕК

2003 елның 8 августы. Виктор Русецкий бөтенләй яңа – цифрлы идарә итү системасы булган чираттагы тәҗрибә вертолетын күккә күтәрә.

Машина көндәгечә җирдән күтәрелеп китә, мәйданчык өстендә эленеп тора. Ә аннары – барысы да куркыныч төштәгечә...

Вертолет кинәт пилот командаларын үтәүдән туктый. Руль тоткасын тарткалауга да, педальләргә баскалауга да җавап бирми. Инструкциядә барысы да язылганмы? Бу очракта алай түгел. Әгәр боралакта рульләр тыңламый башлый икән, пилотка могҗизага өметләнергә генә кала...

Русецкий җиңеп чыга. Һавадагы вертолетны тигезлектә тотып торуга ирешә, ничек икәне аңлашылмаса да, аны буйсынырга мәҗбүр итә. Һәлакәт булмый кала, рәсми документта соңрак: «Эленеп калган халәттә вертолетны тигезләүгә, ә аннары төшереп утыртуга ирешә. Вертолет ватылмый кала, экипаж зыян күрми...» – дип язып куялар.

Гадәттән тыш хәлнең сәбәбен табалар. Идарә итү системасы программасына хата кергән булып чыга. Җаваплы иптәшләр үз карарын чыгара: мондый хәлдә машина бөтенләй идарә ителә алмый. Димәк, пилотның вертолетны коткарып калуын гади логика законнары һәм математик хисаплаулар белән аңлатып та булмый?!

Монда инде, телисеңме-теләмисеңме, интуиция, эчке тоемлау – оста сынаучының экстремаль ситуациядә мөмкин булган бердәнбер коткару юлын таба белү кебек үк мөһим сыйфаты икәнлегенә ышана башлыйсың. Викторның очыш вакытында үзе генә тоемлый торган билгеләр буенча проблемалы урынны таба алу сәләтен тагын ничек аңлатып була? «Ансат» проекты җитәкчесе Валерий Карташов сөйләвенчә, бер сынаудан соң Виктор авышлык белән идарә иткәндә боралакның ничектер сүлпәнрәк буйсынуын хәбәр итә. Тикшерә башлыйлар һәм нәтиҗәдә брак втулка табыла. Әгәр очучы кимчелекне сизеп алмаган булса, моның нәрсәгә китерергә мөмкин булуын күз алдына китерүе дә кыен...

Сынаучының машинаны үзен тойгандай тоя белү сәләте бик еш ярап куя: болгавыр 90 нчы елларда «Ансат»ны проектлаганда һәм күтәргәндә заводның кыйммәтле стендларга һәм контроль җиһазларга акчасы бөтенләй булмый. Күп нәрсәне «тере килеш» тикшерергә һәм сынап карарга туры килә. Аңлашыла ки, бу хәл Русецкий эшенә җиңеллек өстәми.

1999 елның октябрендә, беренче очыштан соң ике ай узгач, вертолетны рәсми тәкъдим итү кичәсе була. Боралак үзенең вак-төяк авыруларының күбесеннән арына, хәтта «Ансат» дигән исем дә ала. Әмма бу күрсәтмә очышны да, Непалда төнлә экстремаль шартларда төшеп утыру белән чагыштырганда, җиңелрәк булган дип әйтә алмыйсың.

– Кунаклар, мәскәүләр, бөтен халык басып тора, ә мин, беркемне дә күрмәс өчен, алгарак киттем. Бер мизгелгә дә күземне вертолеттан ала алмадым. Русецкий төшеп утыргач, җиңел сулап куйдым, – дип сөйли Валерий Карташов ун елдан соң. – Шуннан соң мин әлеге руль винты белән бүтән очмаячакбыз дип ант иттем...

«Ансатның» беренче презентациясеннән соң ук.

ХАЧЛЫ ҺӘМ ЯРЫМАЙЛЫ ПИЛОТАЖ

90 нчы еллар башында, әле «Ансат» дөньяга килгәнче, Русецкий бер очышны башкарырга җөрьәт итә. Бу вакыйганы Раифа монастырендә әлегәчә хөрмәт белән искә алалар. Давыл аркасында монастырьдагы бер чиркәү манарасының хачы сынып төшә. Аны урынына куярга кирәк, әмма моны ничек эшләргә? Монахлар рәсми үтенеч белән вертолет заводы директорына мөрәҗәгать итә, ә ул матур гына итеп аларны Русецкий янына җибәрә: «Менә аңа әйтеп карагыз, риза булса...»

– Эшне башкарыру өчен нервларның нык булуы кирәк иде, – дип сөйли Виктор. – Күз алдыгызга китерегез, җитмеш алты метр биеклектәге гөмбәздә – 50 миллиметрлы тишек. Аңа хачның диаметры ике-өч миллиметрга гына кимрәк булган төп терәген туры китерергә кирәк. Өстәвенә, хач арканнар белән элэктерелгән, вертолет астында төрле якка селкенә, бер-бер хәл булса, бөтен гөмбәзне җимереп төшерергә мөмкин. Вазгыятьне тагын бер нәрсә катлауландыра: без гөмбәзләр өстендә һава агымнары барлыкка килү физикасын белмибез...

Хачны урнаштырырга берничә омтылыш ясап карыйлар, ләкин барып чыкмый. Аптырыйсы юк: мондый операцияләрне башкарганда, рөхсәт ителгән тайпылыш метрлар белән үлчәнә, ә монда – миллиметрлар. Шактый җәфаланганнан соң, тагын бер – соңгы мәртәбә тырышып карарга булалар.

– Мин аста монахның киеменнән сикереп чыгардай булып шатлануын күрдем. Шунда эшне булдырганыбызны аңладым, – дип көлә Русецкий. – Бөтен гәүдәмдә ниндидер җиңеллек хисе барлыкка килде. Шунысы гаҗәп: хач шунда ук бөтен канунннарга туры килерлек итеп кереп утырды – төзәтергә туры килмәде.

Ә тиздән Викторга тагын бер катлаулы эш башкарырга туры килә – бу юлы Болгарда мәчет манарасына гөмбәз куялар. Ә гөмбәзнең авырлыгы – өч тонна, тик операцияне Виктор беренче омтылышта ук оста итеп башкарып чыга. Дөрес, тиздән бу эшнең әле иң җиңеле булуы ачыклана. Гөмбәзне бакыр пластиналар белән тышларга онытканнар икән, шуңа күрә аны күп-

медер вакыттан соң кире төшерергә һәм тагын бер тоннага авырайган хәлдә урынына кайтарырга туры килә. Русецкийга бу операция өчен бер генә омтылыш бирелә, һәм ул сынатмый…

Дини-агарту өлкәсендәге «җәмәгать эшләрен» ник нәкъ менә Русецкий башкарганы аңлашыладыр: гади пилот бу очракларда берни дә булдыра алмас иде. Аның караваы, хәзер очучыга, берәр экстремаль вазгыять килеп чыга калса, КҮКЛӘРдән ярдәм гарантияләнгән, дип шаярта хезмәттәшләре.

КЫЮЛЫКНЫҢ ИҢ ЯХШЫ СЫЙФАТЫ

2001 елның 5 августында Русецкий чираттагы сынау очышына чыга. Тизлек – сәгатенә 240 чакрым, тәҗрибә уза торган машина кабинасы каршындагы ике метрлы тимер «мөгез» (ДУАС – почмак тизлекләре тапшыргычы) очыш параметрларын җентекләп санап-язып бара. Болар барысы да, вертолетны сериягә чыгарганчы, аның абсолют ышанычлылыгына ирешү өчен эшләнә. Язмыш шаяртуымы: нәкъ менә шул «мөгез» тәҗрибә үрнәген аздан гына харап итми кала.

Барысы да секунд эчендә була, дөресрәге, секундның уннан бер өлешендә. Русецкий «мөгез»нең кинәт читкә каерылуын сизә. Шуннан соңгы мизгелдә датчик фюзеляждан куба һәм пилот нindидер иситкеч сизгерлек күрсәтеп калакларны кисәргә сәләтле тимердән тайпылып кала…

Сынаучының баш мие компьютердан тизрәк эшли. Боралакны утырту өчен яраклы мәйданчык мизгел эчендә диярлек тәгаенләнә. Вертолет төшеп утыра. Төбе-тамыры белән кубып төшкән тимер кисәге үзе электрелгән тросларда эленеп тора. Һавада тагын ике-өч секунд калганда, бу нәрсә бөтенләй өзелеп, барысын да пыран-заран китереп җимереп ташлыйсы булган. Ходай әллә чыннан да кыюларны саклый инде?..

– Ходай саклanganны саклый, – дип тагын төзәтә мине Виктор. Һәм үз сүзләрен раслап, танылган очучы-сынаучы Александр Чернавскийның яраткан афоризмын китерә: «Саклык – батырлыкның иң яхшы сыйфаты». – Безнең эштә артык тәвәккәллек урынсыз.

Тик шунысы бар: «артык» тәвәккәллекне аклаганыннан аера торган чикне ничек билгеләргә? Сынаучы Русецкий тормышында шундый очрак була: ул барлык инструкцияләр буенча җирдә калырга тиеш дип санаган вертолетны күккә күтәрә. Бу хәл 1994 елның мартында була, Татарстанны моңарчы күрелмәгән кар бураны каплап алган көннәр. Чаллы трассасында дистәләгән машина һәм автобус буран әсирлегенә эләгә, кешеләр туңа. Бу төбәк очышлар өчен тулысынча ябыла. Русецкий исә иртәдән алып көндезгә уникегә кадәр диспетчерны, очучы-сынаучы буларак, үзенең ярдәмгә очарга сәләтле икәнлегенә күндерергә маташа. Берничә сәгатькә сузылган ызгыш-талаш барышында ике як та әче-төче сүзләрне юмарт чәчә. Төш җиткәндә генә Русецкий аларны күндерүгә ирешә.

– Җил, буран… Юнәлешне чамалау өчен, ничек булса да җиргә бик якын барырга туры килде, – дип искә ала Виктор. – Миңа «Икарус»лар булышты – кар көртләре аша аларның кызыл түбәләрен күреп алдым…

Бу көнне Русецкий ике очышта вертолеты белән 128 кешене коткара. Хезмәттәшләре соңыннан аның «Ми-8»гә шулкадәр кеше сыйдыра алуына бик озак гаҗәпләнә…

Ул чактагы тәвәккәллек, әлбәттә, артык булмый. Ә штаттан тыш һәм көтелмәгән хәлләр бик еш килеп чыгарга мөмкин булган сынау очышларында тәвәккәллек?

АНЫҢ КҮКТӘГЕ ЙОЛДЫЗЧЫГЫ

Бу сорауга җавап – «Ансат». 1999 елда һавага күтәрелгән килбәтсез, «авыр сөякле» аппарат түгел, ә бүгенге, заманча һәм бик ышанычлы очкыч. Үзебезнеке, әмма уңайлылыгы ягыннан чит илнекеннән һич калышмый торган. Бик шәп чагыштырма куәтлелек күрсәткечләре, камил һәм бик гади идарә итү мөмкинлекләре… Хан заманындагы аналоглы уклар урынына – бик күп параметрларны контрольдә тоткан төсле цифрлы дисплейлар…

Беренче прототипларда һәм тәүге серияле «Ансат»ларда ике меңнән артык сәгать очкан Виктор, үзегез күргәнчә, боралакны яхшыртуда һәм камилләштерүдә мөһим роль уйный. Авиациядә хәтта язылмаган кагыйдә дә бар: әгәр очкыч серияле җитештерүгә чыккан икән, яңа машинаны күккә беренче күтәргән сынаучы, һич икеләнмичә, парад кителенең лацканында Герой йолдызы өчен тишек ясый ала. Тик безнең очракта бу кагыйдә эшләми, бәлки, советлар иленнән соңгы чорда беренче машинаны башкаладагы конструкторлык бюросында түгел, ә провинциядә ясаганга һәм аны күккә заводның очучы-сынаучысы күтәргәнгәдер? Әллә вакыты «бүләк өләшү» өчен бик уңай булмаганмы? Югыйсә Татарстанның беренче Президенты кул куйган документ – Виктор Русецкийны Россия Герое исеменә рәсми тәкъдим итү кәгазен бу юлларның авторы шәхсән үзе күргән иде…

Хәер, Русецкий бүләк турында кайгырып йөрми. Аның лаеклы йолдызчыгы менә ул – күкләр гизә!

– Кызганыч, цифрлы идарә системасы сериягә китмәде, – ди Виктор һәм мин ирексездән аның сынау уздырылган очкычны коткару эпизодын искә алам. – Юк, ул, чыннан да, революцион машина, әмма вакытны бераз узып ясалган очкыч. Аңа сертификат бирмәделәр, чөнки чагыштырырлык нәрсә юк – гражданлык вертолет авиациясендә андый очкычлар җитештерелми. Әмма киләчәк – аларда.

«Ансат»ны якты һәм озын-озак киләчәк көтә. Моның алай түгеллегенә Русецкийны беркем дә күндерә алмас. Хәтта вертолетны двигательсез калдыру белән янаган Көнбатыш санкцияләре дә. Аның эти-әнисе сүзләренә караганда, «булмаячак, очмаячак, барып чыкмаячак» дип тукып торганда ясалган очкычны инде күкләрдән аерып булмаячак.



Реклама 16+

– НАЧАР УЙЛАРДАН, ДЕПРЕССИЯДӘН БАРЫ ЭШ КОТКАРА

Руфия Фазылова

«Авито. Услуги» аналитиклары исәпләгәнчә, соңгы бер елда психолог, психиатр ярдәменә ихтыяҗ 80–90 процентка арткан. Хәер, моны шул өлкәдә эшләүче белгечләр үзләре дә яшерми – аларның буш вакыты юк диярлек. Психология фәннәре магистры, психолог, арт-терапевт Чулпан Фидаил кызы Нигъмәтҗанова белән дә шул хакта сөйләштек – ни өчен эч пошу, депрессия кебек чирләр елдан-ел арта? Моны булдырмас өчен нишләргә?

– Чулпан ханым, халык арасында мәзәккә охшаган бер сүз дә йөри. Имеш, өлкән яшьтәге әби докторга барган да: «Әйтегез әле, нервы нәрсә ул? Килен һаман: «Нервым бетте»,– дип зарлана. Мин ул әйбернең кайда икәнен дә белмим», – ди. Чынлап та, әби-бабайлар нинди авыр заманда яшәп тә, депрессиягә бирелмәгән. Ә бүген бу турыда бик күпләр белә. Аеруча яшьләр моннан интегә. Сәбәп нәрсәдә дип уйлыйсыз?

Фото Чулпан Нигъмәтҗанованың шәхси архивыннан алынды

– Беренчедән, бүген кеше ныклап торып үзен өйрәнә башлады. Балачагын, үткәнен анализлый, бу хәтта ниндидер бер яшәү рәвешенә әйләнде... Яңалык түгел – безнең эби-бабайлар ул турыда уйланмаган. Аларның максаты – тамак туйдыру, исән калу, балаларын аякка бастыру булган. Әлбәттә, аларның да ирләре, балалары белән бәйле проблемалары хәттин ашкан. Тик тирәнгә кереп анализлап утырырга, үзендә казынырга аларның вакыты җитмәгән. Ә бүген... Аллага шөкер, тамак проблемасы юк. Кешелек дөньясын икенче әйберләр кызыксындыра башлады. Үз-үзеңне анализлау, якыннарың белән мөнәсәбәтләрне өйрәнү – бүген болар беренче планга килеп басты дисәм дә була. Әле бит көн саен интернет челтәреннән, башка чыганаклардан да безгә: «Үзеңне ярат!» – дип кычкырып торалар. Нәтиҗәсе күз алдында – кеше, бигрәк тә яшьләр, гади генә проблеманы үзе генә хәл итә алмый. «Син берәүгә дә тиеш түгел», дип «акыл» биргән китаплар укыган буын үсеп җитте. Гали дә берәүгә дә тиеш түгел, Вәли дә, Галия дә... Әлбәттә, без үзебезне яратырга тиеш, тик шуның белән бергә башкаларны хөрмәт итәргә бурычлыбыз. Һәм беренче чиратта якыннарыбызны! Бүгенге тормышта исә МИН генә бар. Ә эгоизм беркайчан яхшыга илтми.

– Бүген психология белән бәйле тренинглар, курслар, марафоннар бик популяр. Ихтыяҗ булмаса, алар эшли алмас иде. Сезнең аларга мөнәсәбәтегез нинди?

– Тормышны анализлау бүген нормага әйләнде, дидем. Элек эти-әни кызын кияүгә биргәндә: «Иргә чыктың икән, ничек булса да түз, сабыр бул»,– дип өйрәткән. Ана белән кыз күзгә-күз карап серләшмәгән. Бу этиләргә дә кагыла. Ә бүгенге яшьләр бүтән, аларның бөтен сорауга да җавап аласы килә. Менә шуңа да алар психологларга йөри, төрле тренинг, марафоннарга языла. Ә алар бездә бик күп. Соңгы ике елда аларның саны берничә тапкырга артты. Һәм бу дөнья күләмендә дә шулай. Моның сәбәбе бик гади – пандемиядә кешеләр өйдә утырды. Һәм аларның үзләрендә казыну өчен буш вакытлары барлыкка килде.

– Бу начармы, яхшымы?

– Телибезме-юкмы, һәр заманның үз мавыгуы, яңалыгы формалаша. Шулай булгач, тренинг-марафоннарны начар дия алмыйм. Бу заман таләбе. Әмма моның икенче ягы да бар: бүген һәр кеше үзен акыл өйрәтә алам дип саный. Берниндн махсус белеме, тәҗрибәсе булмаган кешеләр төрле курслар үткәрә. Нәтиҗәдә, ул кешенең проблемасын ачыклый, ләкин хәл итми. Ә бит ул проблеманы «эшләп» бетермәсәң, кешедә җитди психологик аврулар башланырга мөмкин. Шуңа күрә мондый профессионал булмаган тренерларны хәтта куркыныч дияр идем. Әгәр кеше үзен өйрәнергә, якыннары белән мөнәсәбәтен анализларга тели икән, фәкать профессионалларга мөрәҗәгать итсен.

– Чулпан ханым, яз көне сезгә мөрәҗәгать итүчеләр артамы? Гомумән, психологка кайсы очракта барырга кирәк?

– Чынлап та, яз көне мөрәҗәгать итүчеләр арта. Быел февраль җылы булганга, мондый чирләр дә иртәрәк «уянды». Психологиядә кулланыла торган термин белән әйткәндә, эмоциональ тирбәнү күзәтелгән кешеләр саны нык артты. Иң кызганычы – бу чир яшьләрдә күбәя. Консультациягә йөрүчеләр арасында унҗидедән алып утыз биш яшькәчә булганнар күбрәк.

Психологка кайчан барырга кирәк дигәндә, проблемадан чыгу юлын үзең генә хәл итә алмаган очракта, дияр идем. Гаҗәеп бер хәл күзәтәм. Консультациягә килгәч: «Әй, миңа бу турыда апам, әнием әйткән иде. Тик мин аларның сүзен ишетмәдем, ә сезне ишеттем», – диләр. Ягъни күп очракта якынының сүзен кеше игътибарга алмый. Ә менә минем кебек белгеч сүзе алар өчен зур көчкә ия. Шуңа да мондый белгечләр кирәк. Әлбәттә, кечкенә генә проблема килеп туганда да психологка мөрәҗәгать итәргә диген сүз түгел бу. Кеше үзе генә хәл итә алмаган мәсьәләләр була бит.

Шулай да, нинди генә көчле белгеч булмасын, психолог кешене тулысынча үзгәртергә сәләтле түгел. Адәм баласы аерым бер холык белән туа. Психолог фәкать теге яки бу проблеманың чишелеш юлларын күрсәтә, кешегә үз бәясен күтәрергә булыша ала. Күп нәрсә кешенең үзеннән тора.

– Соңгы вакытта паника өянәкләре турында күп сөйлиләр. Шул хакта җентекләбрәк аңлатсагыз иде.

– Һәр икенче килгән кеше паника өянәгеннән зарлана. Чынлап та, бу бүген бик актуаль темага әйләнеп бара. Мондый вакытта кешенең йөрәге сикерә, кан басымы күтәрелә, сулыш җитми, күкрәктә

авырту килеп чыга, тирли, хәтта кеше аңын да югалтырга мөмкин. Шуңа курку өстәлә. Ләкин иң беренче шуны әйтим: бу үлемгә китерә торган чир түгел. Аннан кеше акылын да җуймый, үлми дә. Әмма бу авыру белән яшәргә кыен. Шуңа да аны вакытында дәваларга кирәк.

Психологиядә «триггер» дип аталган термин бар, ягъни курку. Мисал өчен, кечкенә чагында кешене эт тешләгән була. Инде зур үскәч, аның каршысына бер төркем эт очрады, ди. Һич уйламаган җирдән аның тәне калтырый башлый, сулый алмас, үзен-үзе белештермәс дәрәҗәгә җитә.

Ягъни балачакта булган теге вакыйганы баш мие истә калдырган да, куркыныч килеп тугач, искә төшергән. Мин моны мисал итеп кенә китердем, төрле очрак булырга мөмкин. Һәр паника өянәгенең сәбәбе бар, аны анализлап, төбенә төшәргә кирәк. Кеше психологка, белгечкә чынлап торып ачыла, аның ярдәменә ышана икән, бу проблеманы хәл итеп була. Ягъни мондый хәлнең чыганагын ачыклау мөһим.

– Психолог кына түгел, хәзер күпләр психотерапевтка йөри. Ә табиб гадәттә авыруны протокол белән дәвалый, ягъни төрле препаратлар яза. Нәтиҗәдә, кеше еллар буе антидепрессантлар эчә. Һәм аннан башка яши алмас дәрәҗәгә килә. Бу тозактан котылып буламы?

– Әйе, андый проблема белән еш киләләр. Дөресен әйтим, андый транквилизаторларга каршымын. Психотерапевт биргән даруны еллар буе эчеп тә файдасын күрмәүчеләр күп. Алар белән эшләргә бик авыр, чөнки баш миендә төрле үзгәрешләр башланган була. Йокысызлык, баш авыртулары – болары беренче күзгә ташланган билгеләр. Көчле дарулар тора-бара кешене «яшелчә» халәтенә китерә. Гомер буе шундый даруларда утырган кешеләр бар, бу бәйлелекнең бер төре. Шуның өчен психотерапевт язган даруларга бик сак карарга кирәк. Бәлки көчле препаратларсыз да бу халәттән чыгып булыр? Беренче эш итеп даруга барып ябышу дөрес түгел дип саныйм.

Башта психолог белән сөйләшү зарур. Курку, эч пошуны бетерә торган төрле методлар бар. Әлбәттә, башта шуларны эшләп карау сорала. Тик безнең халыкка могҗиза кирәк шул, аңа тиз генә бер таблетка эчеп, бөтен проблемаларыннан котылу яхшырак. Югыйсә кеше башта үзе утырып уйларга, теге яки бу хәлгә анализ ясарга тиеш. Проблеманы тирәнгә җибәрмәү мөһим.

– Акылдан язу кебек чир нәселдән килә аламы?

– Кызганыч, килә. Теоретик яктан мондый хәл бөтен кеше белән булырга мөмкин. Күбрәк бу чиргә психологик яктан көчсез кешеләр бирелә. Көчле рухлылар бик бирешми.

Акылдан язмас өчен кешедә бушлык булмау мөһим. Ягъни яраткан шөгыль, эш, сайлаган кыйбла – болар барысы да яшәү мәгънәсе, уңай эмоцияләр бирә. Тормышның кызыгын табарга кирәк.

– Чулпан ханым, күңел тынычлыгын ничек сакларга? Укучыларыбызга берничә киңәш бирсәгез иде.

– Әгәр сезгә тынгы бирми торган проблема бар һәм ул яшәргә комачаулый икән, белгечләргә барыгыз. Бары белгеч кенә сезгә дөрес дәвалану техникасын, методикасын сайлар. Әгәр инде кемнәндер ишетеп, укып кына үзегездә казынырга уйласагыз, бу катгый тыела! Ышаныгыз: ул тискәре нәтиҗәләргә китерәчәк! Хәтта кеше үз-үзенә кул салуга кадәр барып җитәргә мөмкин.

Төп киңәшләрнең берсе – тормышка җиңелрәк карагыз. Мин моны пациентларымда да күрәм: кирәкмәгән уйлар белән яшиләр. Имеш, ул бәхетсез, аны гына начарлык сагалап йөри...

Ә чынлыкта боларны кеше үзе уйлап чыгара. Һәм шул юләр фикерне башында йөртә башлый. Нәтиҗәдә депрессия барлыкка килә.

Икенче киңәшем – эшсез тормагыз. Начар уйлардан, депрессиядән бары эш коткара. Буш вакытыгыз калмасын! Күзәтүләрдән чыгып әйтәм – физик эш белән мавыккан кешеләрдә депрессия булмый диярлек.

Өченчесе – кичерә белегез. Кемдер, кайчандыр сезгә карата начар сүз әйткән, зарар эшләгән икән, бу хакта онытыгыз. Ул кеше үзенең бу гамәлен күптән оныткандыр. Ачу саклап яшәү кешене эчтән җимерә. Бик куркыныч әйбер.

Дүртенчесе – матурлыкны күрергә өйрәнегез. Күршеңә, коллегыңа елмай, ишек ачып керт, хәлен сора. Ул да сиңа нәкъ шулай җавап бирәчәк бит.

Нәтиҗәдә, икегез дә күтәренке кәеф белән эш башлыйсыз, яки өйгә кереп чәй эчәсез. Сиңа елмаймасалар да, син елмай. Иртәгә ул да сине күргәч елмаячак. Бу ысул эшли, үземдә бик күп тапкырлар сынаганым бар.

Әнә урамда ничек матур, кошлар сайрый, дөнья яшәрә! Яшәү үзе үк бер могҗиза бит...

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Татмедиа»да **НИЧӘ** журналист династиясе эшли

Яшь буынны һәр язмада кешене күрергә **НИЧЕК** өйрәтергә

Журналистлар гаиләсендә **НИНДИ** һөнәри серләр саклана

Балаларны гына түгел, киленне дә **НИЧЕК** журналистикага китерергә

Балалар өчен журнал **НИЧЕК** туа

Хәбәрче танылыгын **НИЧӘ** яшьтә бирәләр

PRESSA

ТАТ
МЕДИА

«Татарстан» журналының махсус проекты

«ТАТМЕДИА» ДИНАСТИЯЛӘРЕ

Әти-әниләр, абый-апалар, балалар, оныклар – алар, тулы бер династия булып, озак еллар дәвамында үзләре сайлаган журналист һөнәренә тугры калып эшлиләр. Һәр журналист гаиләсе тарихы уникаль: аларны тыңлау – үзенең төенләнеше, чишелеше һәм кульминациясе булган сериалны карауга тиң...

ДИНАСТИИ_ТМ

ЛӘЙСӘН САФИНА, ИДЕЯ АВТОРЫ:

– Барлык һөнәрләрдә дә «династия» төшенчәсе бар. Табиблар династиясе, укытучылар династиясе, юристлар династиясе – болар барысы да бик күңелле яңгырый. Ә менә шул династияләр турында язучы журналистлар, буыннар бәйләнешен күрсәтеп, ни өчендер үз һөнәрләрен таныту белән шөгыльләнми. Бәлки шуңа күрә дә бүген журналист һөнәре артык популяр түгелдер? «Татмедиа» акционерлык җәмгыятендә пиар-директор вазыйфасында бер ел эшләү дәверендә мин биредә гаиләләре белән хезмәт куючыларның шактый күп икәнен искәрдем. Уйлап куйдым: үз һөнәренә озак еллар буе тугры калып, аны буыннан буынга тапшыручы журналистлар хакында күргәзмә оештыру шәп булыр иде бит! Ун гаиләне барлап, әлеге идеямне җитәкчелеккә җиткердем. Анда тагын җиде гаилә өстәлде. Һәм Россия матбугаты көненә күргәзмә ачылды да.

Аны әзерләгәндә, фотога төшергәндә, мин бик күп кызыклы гаилә тарихларын ишеттем һәм укыдым. Мәсәлән, этисе белән әнисе икесе дә газета редакциясендә эшли, алар яңа санны тапшырганда, балалары да үз газетасын чыгарып уйный – димәк, менә дигән алмаш үсеп килә!

Яки менә тагын бер тарих. Ир белән хатын бергә эшли, ире озак еллар буе газетаның баш мөхәррире була, хатыны эштә аңа буйсына... Аннары исә урыннарын алмашалар, хәзер, киресенчә, җитәкче хатын ирен үз кубызына биетә!

Владимир Шевчукның кызы Полина этисе белән бергә өйдә стена газетасы чыгаруларын искә алды...

Күргәзмәдә катнашучыларның кайберләренең абыйлы-энеле яки ирле-хатынлы булуын моңарчы беркем белмәгән династияләр дә бар икән әле. Фотога төшергәндә, иренә хатынын кочып алырга яки хатынына башын иренең җилкәсенә салырга тәкъдим иткәч уңайсызланучылар, моны артыгын кылану дип санаучылар да булды.

Иң зур династия Витовскийлар булды. Дүрт кешене бер кадрга уңышлы сыйдыру бик җиңел түгел. Алар үзләре дә, фотограф та тырышты – матур, кызыклы фото килеп чыкты.

Күргәзмә ачылып, халык аны караганнан соң, геройларыбыз тагын да артты: башта өч гаилә, аннары тагын биш гаилә өстәлде. ТНВ, ДТРК журналистлары да килә, үз династияләрен күрсәтергә тели. Проект озакка сузылачак әле, ул инде үз тормышы белән яши, даими тулылана. Татарстан матбугаты көненә сез инде «Татмедиа» җәмгыятенең яңа династияләре хакында күргәзмә белән хозурланачаксыз.

Фото: Александр Ефремов

ДИНАСТИ_ТМ

АННА АРАХАМИЯ, ФОТОЛАР АВТОРЫ:

— Миңа әлеге проектта катнашу кызыклы булды, чөнки үзем дә «Татмедиа» династиясеннән. Әнием – Татьяна Глебовна Шмарина 1976 елдан бирле типографиядә җыю цехы мастеры һәм технолог булып эшләде. Аннары 2010 елга кадәр «Татарстан» журналында хезмәт куйды.

Апам Олеся Чегаева башта «Идел» журналында эшләде, аннары «Татмедиа» җәмгыятенең IT-бүлегендә дизайнер булды. Мин дә 2008 елдан бирле башта – «Идел», аннары «Татарстан» журналларында дизайнер булып эшләдем. Параллель рәвештә фотография белән шөгыльләндем, һәм хәзер мин – «Сөембикә» журналы фотографы.

Шунлыктан әлеге проектка бик шатланып кушылдым. Һәм коллегаларымны рәхәтләнеп фотога төшердем. Портретлы фотосессия, һәр кадрда берничә кеше иде. Кешеләр барысы да төрле-төрле, холыклары да, йөз-кыяфәтләре дә төрле, һәркайсының нindидер үзенчәлеген тотып алу мөһим. Миңа бу эш ошады. Киңәшләремне тыңлап, мин кушканча төшәргә тырыштылар. Гомумән, әлеге фотосессияләр бик күңелле узды.

«Татмедиа» – зур дөнья ул, Декабристлар урамындагы 2 нче йортка гына сыеп бетмичә, бик еракларга - бөтен республикага тарала. Фотосессия геройларының кайберләрен мин инде беләидем, районнардан килүчеләр белән эш барышында таныштым.

Династияләр дәвам иттерелсен өчен, ата-ана һөнәре белән кызыксыну зарур. Әти-әнигә исә балаларын мавыктырырга кирәк.

Тик мин улларымның фотограф булуын теләмим, бу миңа хатын-кыз һөнәре булып тоела. Ә менә журналист булсалар ярый!

PRESSA

ДИНАСТИЯ

– ЖУРНАЛИСТИКАНЫҢ ТӨП БУРЫЧЫ – КЕШЕЛӘРГӘ БУЛЫШУ

Фото: Анна Арахамия

ЗИНАИДА ИВАНОВА,
2010 елга кадәр «Зеленодольская правда» газетасының мәгълүмат һәм мәдәният бүлеге мөхәррире

Мәдәният һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәләренең уртаклыгы нидә? Асылда бернинди уртаклыгы да юк. Әмма син район газетасы журналисты булганда, якташларың үз газетасын хөрмәт итсен һәм яратсын өчен, тегесен дә, монысын да, башкасын да яхшы белергә тиеш. Зинаида Иванова бөтен гомерен «Зеленодольская правда» газетасында хезмәт итүгә багышлаган. Һәм моңа бер дә үкенми. Зинаида Ивановна һәр материалы белән шәһәр тормышын яхшы якка үзгәртергә өметләнгән һәм шуңа омтылган.

– 1980 нче еллар башында бездә баракларны сүтә башладылар. Редакциягә елый-елый бер ханым килеп керде. Аны бер бaрактан икенчесенә күчерәләр икән. Без бу мәсьәләне контрольгә алгач, аңа яхшы фатир бирделәр, – дип сөйли Зинаида Иванова. – Ул вакытларда мондый нәтиҗә журналист эшендә гадәти күренеш иде. Ә ул ханым әле берничә тапкыр килеп: «Ванна бүлмәсе дә үземнеке бит хәзер! Аерым кухня! Ышана да алмыйм!» – дия-дия, рәхмәт укыды.

Әмма якташларының уңайлы тормыш-көнкүреше өчен көрәш һәрвакытта да газетаның җиңүе белән тәмамланмый шул. 2000 нче еллар башында сәүдә үзәкләре төзелә башлый. Шуларның берсен Яшел Үзәннең үзәгендә, автовокзал янында салырга җыеналар. Ә анда кечкенә генә каен урманы үсеп утыра. «Зеленодольская правда» урманны якларга тырышып карый, әмма уңышка ирешә алмый. Ул тирәдән үткәндә, Зинаида Ивановна андагы каенкайларны хәзер дә юксынып куя... Югыйсә, шәһәрдәге шактый яшеллек утравын саклап кала алган алар.

– Мин һәрвакыт журналистиканың төп бурычы– кешеләргә төрле проблемаларны хәл итәргә булышу, дип саныйм. Хәзер вазгыять үзгәрде – матбугат чаралары нигездә мәгълүмати функцияне башкара. Бәлки, бу дөрестер дә, – ди Зинаида Иванова. – Тик безне үз вакытында башкача өйрәттеләр. Без бит алдынгы отряд идек.

Әңгәмәдәшебезгә журфакның иң яхшы укытучыларыннан белем алу бәхете тәти. Аларның студентлары журналистның һичшиксез нык холыклы, яхшы белемле, үҗәт һәм эзлекле булырга тиешлеген анык белә. «Зарар китермә!» принцибы бу һөнәрнең нигез ташын тәшкил итә, ә үзәктә кеше шәхесе тора. Зинаида Ивановнага, чыннан да, кызыклы язмышка ия кешеләр, аеруча исә хәрбиләр, эшчеләр, иҗат әһелләре турында язу бик ошый. Бу аңа соңрак, 2010 елда, Яшел Үзән шагыйрьләренең Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләре җыентыгын туплаганда, редакцияләгәндә һәм бастырып чыгару өчен финанслар эзләгәндә (район башлыгы булышлыгы белән) ярдәм итә.

Зинаида Ивановна «Зеленодольская правда» газетасына 80 нче елларда килә һәм лаеклы ялга чыкканчы биредә эшли. Кызы Светлана һәм оныгы Валерия дә тәүге һөнәри адымнарын шушы газетада ясый.

– ХӘЗЕР ВАЗГЫЯТЬ ҮЗГӘРДЕ – МАТБУГАТ ЧАРАЛАР НИГЕЗДӘ МӘГЪЛҮМАТИ ФУНКЦИЯНЕ БАШКАРА. БӘЛКИ, БУ ДӨРЕСТЕР ДӘ. ТИК БЕЗНЕ ҮЗ ВАКЫТЫНДА БАШКАЧА ӨЙРӘТТЕЛӘР. БЕЗ БИТ АЛДЫНГЫ ОТРЯД ИДЕК.

ДИНАСТИИ_ТМ

– ХИС-КИЧЕРЕШЛӘР – ОНЫТЫЛЫРЛЫК ТҮГЕЛ!

СВЕТЛАНА БЕЛОВА,
«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының рус редакциясендә баш мөхәррирнең беренче урынбасары.

Журналистика – көтелмәгән сюжетлы һөнәр ул. Һәр көнне әйтерсең лә яңабаштан башлыйсың. Яңа кешеләр, яңа урыннар... Эшкә барганда бүген язмыш сине кая китерәсен белмисең – зоопарккамы, чүплеккәме, төзәтү колониясенәме, әллә иң югары даирәләр кабинетынамы? Сюжет төшерүгә яки интервьюга күпме генә әзерләнсәң дә, очраклылык дигән нәрсәне уйлап бетереп булмый.

Бервакыт кышын «Эфир» хәбәрчесе Светлана Белова һәм оператор Оксана Маликова тау чаңгысы курорты төзелешенә юл тота. Алар Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вертолетының югарыга канатлы күтәргеч өчен каланчаларны алып менеп бастырганын төшерергә җыена. Сюжет каланча белән очып китеп барган вертолет фонында Светлананың стендапы белән төгәлләнергә тиеш була.

– Мин басып торам шулай, оператор җиһазларны көйли. Шулчак кинәт вертолет калаклары әйләнә башлады. Кар буранын күтәрде һәм Оксана белән мине туры мәгънәсендә очыртып алып китте! Без югалып калдык, шуышыбрак булса да читкәрәк китәргә һәм берәр нәрсәгә ябышырга тырышабыз, тик булмый гына бит. Шулвакыт янибызга министрлыкның матбугат секретаре Андрей Родыгин килеп, безне агачларга табарак сөйрәп алып китте дә, шуларга тотынып торырга кушты,– дип искә ала Светлана.

«Ми-26» вертолетының матур итеп күккә күтәрелүен журналистлар әнә шул агачлар яныннан күзәтә дә. Стендапны алар барыбер төшереп бетерә. Светлана исә үзенә, сюжет геройлары белән сөйләшүгә генә түгел, ә әңгәмә узачак шартларга да әзерләнергә кирәк икән, дигән нәтиҗә ясый.

Күп еллар узгач, инде «Татар-информ» агентлыгында эшләгәндә, Светлана яңадан төзелеп яткан Казан Изге Ана иконасы соборының диварларын бизәүче рәссамнар белән әңгәмәгә юл тота. Сентябрь азагы. Светлана, чиркәүгә баручы хатын-кызларга карата таләпләрне үтәп, тездән түбәнрәк итәк, плащ кия. Ә аякта – туфли.

– Бу бик зур хата иде! Соборга килеп керүгә, диварларның төзелеш баскычлары белән чуарланганын күреп алдык. Бизәк-рәсемнәрне карау өчен, баскычлар буйлап гөмбәз астына ук – 30 метр биеклеккә менергә кирәк, – ди Светлана. – Шулай итеп, миңа туфлидән, баскычларга баса-баса, югарыга үрмәләргә туры килде. Әле шунысы да бар: мин биеклектән куркам... Һич онытылмас тәэсирләр калды!

Эштә көтелмәгәнлек элементы һәрвакыт бар, аннан хәтта Светлана «Татар-информ» мәйданчыгында даими алып бара торган матбугат конференцияләрендә дә котылып калып булмый.

– Без тема, чакырылачак спикерларны каләм әһелләренә кызыклы булырлык итеп сайларга тырышабыз. Журналист булып эшли генә башлаган чагымда матбугат конференциясендә бер сорау да бирмәү уңышсызлык дип санала иде, – ди Светлана. – Хәзер кайбер яшь журналистлар сорау бирүдән оялып утыра, акылсыз булып күренүдән курка. Тик шулай да сорау бирмичә үкенеп йөргәнче, соравыңны биреп, җавап алу яхшырак. Спикер – бетмәс-төкәнмәс мәгълүмат хәзинәсе ул, аңа ачкыч кына ярата белергә кирәк. Иң гади ачкыч исә бу тема белән кызыксынудан гыйбарәт.

> **– ҺӘР КӨННЕ ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ ЯҢАБАШТАН БАШЛЫЙСЫҢ.**
> ЯҢА КЕШЕЛӘР, ЯҢА УРЫННАР... ЭШКӘ БАРГАНДА БҮГЕН ЯЗМЫШ СИНЕ КАЯ КИТЕРӘСЕН БЕЛМИСЕҢ – ЗООПАРККАМЫ, ЧҮПЛЕККӘМЕ, ТӨЗӘТҮ КОЛОНИЯСЕНӘМЕ, ӘЛЛӘ ИҢ ЮГАРЫ ДАИРӘЛӘР КАБИНЕТЫНАМЫ?

ДИНАСТИЯ_ТМ

– КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ҺӘРВАКЫТ ЭКСКЛЮЗИВТАН МӨҺИМРӘК

ВАЛЕРИЯ БЕЛОВА,
Республика клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте белгече.

Көннәрдән бер көнне «Татар-информ»ның яшь хәбәрчесе Валерия Белова Балалар республика клиник хастаханәсендә хирургларның дүрт яшьлек сабыйдагы сирәк очрый торган бөер шешен алып ташлау буенча уникаль операция уздырулары турында репортаж ясарга бара. Хастаханә үзе дә, аның табиблары да Валериянең күңелендә бик зур тәэсир калдыра.

– Мин медицинага чын-чынлап гашыйк булдым. Хастаханәдән чыктым да, матбугат чараларыннан китә калсам, менә шундый җиргә генә китәчәкмен дип уйлап куйдым, – дип искә ала ул.

Мәктәптә укыганда ук ул кешеләргә ярдәм итәргә мөмкинлек бирә торган һөнәр иясе булырга тели, әмма медицина өлкәсен сайларга кыюлыгы җитми. Ә журналистика файдалы да, кызыклы да булып тоела. Бюджетка укырга керү максатын куеп, 11 нче сыйныфта чакта Валерия «Алтын каләм» балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты республика фестивалендә җиңү яулый.

«Татар-информ» агентлыгында эшләгәндә, Валерия Балалар республика клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль Шәвәлиевтән интервью ала. Бу әңгәмә көчле тәэсир калдыра. Тиздән Шәвәлиев үз командасы белән республика клиник хастаханәсенә күчә. Матбугат сәркатибе вакансиясе барлыкка килә, һәм Валерия, ике уйлап тормыйча, шунда урнаша.

Хастаханәнең матбугат хезмәтендә эш аз түгел, әмма Валерия һәм аның хезмәттәшләре иҗат өчен дә вакыт таба. Күптән түгел алар табибларның шәхси тарихы һәм пациентларның истәлекләре аша әлеге шәфкать ияләре тарафыннан башкарылган изге эшләр турында сөйләүнең яңа форматын гамәлгә кертеп җибәрә.

– Без табиблык эше нечкәлекләреннән бихәбәр аудитория өчен кызыклы булачак материаллар әзерләргә тырышабыз. Гади, мавыктыргыч тел белән табибларыбызның нәрсәгә сәләтле икәнлеге турында сөйлибез. Хәтта республиканың иң ерак районнарыннан килгән әби-бабайлар да биредә нинди ярдәм алырга мөмкин икәнен белеп торсын. Хәзер менә фониаторларыбыз – авыру яки операция сәбәпле югалган тавышны кайтару белән шөгыльләнүче белгечләр турында берничә телерепортаж өчен материал әзерлибез.

Валериянең шушы һөнәрне сайлап алуында икесе дә, журналист булган әбисе Зинаида Ивановна һәм әнисе Светлана зур роль уйный.

– Әби мине сүзләр белән бик сак эш итәргә өйрәтте. Әни исә геройларга карата мөнәсәбәттә шундый ук пөхтәлек кирәклегенә төшендерде, – ди Валерия. – Алар ярдәмендә мин һәр язмада иң мөһиме кешеләр икәнлеген гомерлеккә истә калдырдым. Кешелеклелек һәрвакыт эксклюзивлыктан мөһимрәк.

– ӘБИ МИНЕ СҮЗЛӘР БЕЛӘН БИК САК ЭШ ИТӘРГӘ ӨЙРӘТТЕ. ӘНИ ИСӘ ГЕРОЙЛАРГА КАРАТА МӨНӘСӘБӘТТӘ ШУНДЫЙ УК ПӨХТӘЛЕК КИРӘКЛЕГЕНӘ ТӨШЕНДЕРДЕ. АЛАР ЯРДӘМЕНДӘ МИН ҺӘР ЯЗМАДА ИҢ МӨҺИМЕ КЕШЕЛӘР ИКӘНЛЕГЕН ГОМЕРЛЕККӘ ИСТӘ КАЛДЫРДЫМ.

PRESSA

ДИНАСТИИ_ТМ

– СОҢРАК БИК КҮПЛӘР: «КЕМНӘРНЕ ИЯЛӘШТЕРГӘНСЕҢ БИТ!» – ДИДЕ

РАФАЭЛЬ ХӘЛИЛУЛЛОВ,
«Чаян» журналы баш мөхәррире

1980 нче елларда күп тиражлы төзелеш газетасының яшь мөхәррире Рафаэль Хәлилуллов бетон болгатуның алдынгы методлары һәм бишьеллык планнарын үтәү турындагы материаллар арасында шагыйрь дусты Алексей Остудин шигырьләрен дә урнаштыра. Партиянең район комитетында ачуланалар: «Сез нәрсә? Бу бит безнең җитди басма!» «Беләсезме, бу егет, Алексей, бездә монтажчы булып эшли бит», – дип аклана мөхәррир. Бәхеткә, әлеге ялганы ничектер ачылмыйча кала. Ихтимал, нәкъ менә шундый стандарт хәлләрдән гайре табигый чыгу юлларын таба белүе киләчәктә Рафаэль Хәлилулловны республиканың иң шаян журналының баш мөхәррире вазыйфасына китергәндер дә.

Ул елларда «Чаян» битләренә эләгү бөтен илдә дан казануны (яки яманатың чыгуны) аңлаткан. Әмма материаллар өчен редакциянең җаваплылыгы да зур булган. Бервакыт Рафаэль Хәлилуллов аталы-уллы Камскийлардан интервью алган. «Гарри Каспаров кемнән курка?» дигән материалда 14 яшьлек талантлы шахматчы Гата һәм аның тренеры булган этисенең ниндидер бюрократик киртәләр аркасында чит илгә чыгу мөмкинлеген югалтулары хакында сөйләнгән. Интервью чыкканнан соң берничә ай үткәч, Камскийлар Нью-Йоркка очкан һәм шунда яшәп калган.

– Миңа соңыннан бик күпләр: «Кемнәрне ияләштергәнсең бит!» – диделәр. Соңрак Рөстәм Камский улы белән Татарстанга килде. Без очрашкач, ул миннән ни өчен Нью-Йоркка бармавымны сорады. Камский бер танышы аша миңа чакыру җибәргән булган, әмма курьер, күрәсең, ул чакыруны үзендә калдырган, – дип сөйли Рафаэль Хәлилуллов.

Журналның иң «чага» торган бите – аның тышлыгы. Бервакыт районга командировкага барган Рафаэль Хәлилулловны тизлекне арттырган өчен ЮХИДИ хезмәткәре туктаткан.

– Бу минем яраткан журналым бит! Штраф салмыйм, соңгы санны гына бир, – дип сөенгән тәртип сакчысы, кемне туктатуы ачыклангач. Мөхәррир машинасыннан соңгы санны алып бирмәкче дә булган, әмма аның тышлыгында таягын күтәргән ачулы юл хезмәте инспекторы сурәтләнгән икән... Штрафны түләргә туры килгән.

Көн кадагына суга торган басма булганга, «Чаян» «чагып» кына калмый, кайвакыт әле киләчәкне дә фаразлый. 2019 елның көзендә редакция гриппка каршы вакцинация кампаниясе темасын яктыртырга була. Тышлыкка битлек кигән һәм зур шприц тоткан табибтан качучы кеше рәсемен урнаштыралар. Ярты елдан соң COVID-19 эпидемиясе башлана.

2019 ЕЛНЫҢ КӨЗЕНДӘ РЕДАКЦИЯ ГРИППКА КАРШЫ ВАКЦИНАЦИЯ КАМПАНИЯСЕ ТЕМАСЫН ЯКТЫРТЫРГА БУЛА. ТЫШЛЫККА БИТЛЕК КИГӘН ҺӘМ ЗУР ШПРИЦ ТОТКАН ТАБИБЛАРДАН КАЧУЧЫ КЕШЕ РӘСЕМЕН УРНАШТЫРАЛАР. ЯРТЫ ЕЛДАН СОҢ COVID-19 ЭПИДЕМИЯСЕ БАШЛАНА.

Фото: Анна Арахамия

ДИНАСТИЯ

– ХӘБӘРЧЕ МИННӘН: «СИН НӘРСӘ ТӨШЕРДЕҢ СОҢ?» – ДИП СОРЫЙ

ШАМИЛ ХӘЛИЛУЛЛОВ,
«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы операторы

1990 нчы еллар азагында Татарстандагы «Эфир» телеканалында җитди яңалык блоклары артыннан «бантиклар» – республикадагы кызыклы һәм гайре табигый вакыйгалар яки урыннар турында кечкенә сюжетлар күрсәтүне уйлап табалар. Аларны оператор Шамил Хәлилуллов белән хәбәрче Михаил Любимов әзерли. Тандем әлеге бурычка иҗади якын килә. Мәсәлән, геологлар ярдәмендә тамашачыларга Татарстанның «кендеген» (кайдадыр Чистай районында) күрсәтәләр. Тагын бер очрак: Любимов белән Хәлилуллов 1918 елда Зөядә Иудага куелган һәйкәл хакында сюжет төшерергә ниятли. Күккә йодрык селкеп торган сынны Троцкий китерә, әмма куеп өч көн үтүгә, Иуда юкка чыга. Әлеге репортаж белән озак маташырга туры килә, йә һава торышы начарлана, йә спикерлар каядыр китеп югала. Әйтерсең лә күк үзе бу материалга каршы, шулай да сюжет эфирга чыга.

Шамил Хәлилулловның үзе турында әлегә кино төшерелмәгән, гәрчә дүрт дистә елдан артыграк эшләү дәверендә шактый материал тупланса да. 1990 нчы еллар азагында оператор һәм аның булачак хатыны – «Эфир» каналы алып баручысы Ольга Лаврова Казан урамнарыннан берсе буйлап барганда җиденче каттагы төтен ургылган фатир балконында бер кешене күреп алалар. Журналистлар ярдәмгә ашыга. Ольга янгын сүндерүчеләргә шалтыраткан арада Шамил фатирга бәреп керә. Күз ачкысыз төтендә юыну бүлмәсенә кереп сөлге ала, юешләп, башына һәм битенә урый.

– Кухня почмагында кечкенә генә әбекәйне күреп алдым. Сөлгегә уралган коткаручысын ул йә чит планета кешесе, йә фәрештә дип уйлагандыр инде. Кочагыма алдым да подъездга чыгардым үзен, – дип сөйли Шамил Хәлилуллов. Фатирда башка кеше булмавын, янгын сүндерүчеләрнең тиздән килеп җитәчәген ачыклагач, журналистлар эшкә китә. Ике атнадан соң исә Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре Шамил белән Ольгага янгында кешене коткарган өчен медальләр тапшыра.

Безнең героебызның һөнәри бүләкләре дә бар, мәсәлән, «Объектив аша караш» номинациясендә республикада беренче «Бәллүр каләм». Дөрес, хәтта үз эшенең осталары да кайвакыт мәзәк хәлләргә юлыгырга мөмкин. Бервакыт Казанда мөһим делегацияне көтәләр. Матбугат вәкилләрен аэропортка алып киләләр. Самолет төшкәнен ишеткәч, телевидение хезмәткәрләре, аппаратларын күтәреп, шунда йөгерә...

– Без эшкә кайттык, материалны тапшырдым. Бераздан мине хәбәрче чакыра һәм: «Син нәрсә төшердең соң?» – ди. Видеога йөгереп баручы аяклар гына төшкән, – дип сөйли Шамил Хәлилуллов. – Камераны кабызганмын да, онытканмын, самолет янында тагын бер тапкыр кабызам дип басып, киресенчә сүндереп куйганмын икән бит...

- КУХНЯ ПОЧМАГЫНДА КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ ӘБЕКӘЙНЕ КҮРЕП АЛДЫМ. СӨЛГЕГӘ УРАЛГАН КОТКАРУЧЫСЫН УЛ ЙӘ ЧИТ ПЛАНЕТА КЕШЕСЕ, ЙӘ ФӘРЕШТӘ ДИП УЙЛАГАНДЫР ИНДЕ. КОЧАГЫМА АЛДЫМ ДА ПОДЪЕЗДГА ЧЫГАРДЫМ ҮЗЕН.

ДИНАСТИЯ_ТМ

– КӨЧЛЕ СПОРТ РЕДАКЦИЯСЕ БУЛДЫРУ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНАМ

АРТУР ХӘЛИЛУЛЛОВ,
«Татар-информ» мәгълумат агентлыгының спорт бүлеге мөхәррире

Спорт сөючеләр арасында Корбан Бердыевның сихри көчкә ия пиджагы турында мәзәк йөри. «Рубин» командасы уйнаганда, эсседә дә, суыкта да ул гел шул пиджагын кия – команда җиңә. Аннары Бердыев командадан китә һәм кабат әйләнеп кайта, тик бу юлы инде пиджаксыз гына. Команда да җиңүдән туктый. Артур Хәлилулловның сынамышлары да, ритуаллары да юк. Ул балачагыннан спортка мөкиббән һәм һөнәрендә уңышка ирешүе нәкъ менә шуның аркасында дип уйлый. Әтисе – «Чаян» мөхәррире Рафаэль Хәлилуллов та, абзасы – телеоператор Шамил Хәлилуллов та династияне дәвам иттерүченең сайлаган юлына әллә ни тыкшынмаган.

– Мин, әлбәттә, безнең спорт журналистикасының Александр Медведев, Александр Егоров кебек виртуозлары һәм башкаларның материалларын зур кызыксыну белән укый идем, тик миңа «үзеңә кумир булдырма» принцибы белән яшәү күбрәк ошый. Материалларымны мин иң әүвәл укучы мәнфәгатьләрен күздә тотып язам, – ди Артур Хәлилуллов. – Язмам үземә ошый, аудиториягә ошамый икән, күңел төшә инде. Кайвакыт киресенчә дә була: аягөсте генә язып ташланган текстны нигәдер кинәт меңләгән кеше укый.

Журналист футболчы, баскетболчы, волейболчыларның үзләрен генә түгел, бәлки аларны җиңүгә әзерләүчеләрне дә республика спорт тормышының төп геройлары дип саный.

– Татарстанда бөек тренерлар әллә ни күп түгел. Минем өчен Зиннәтулла Билалетдинов һәм Владимир Алекно шәхесләре зур абруйга ия. Аларны һәрвакытта да ачыктан-ачык сөйләшүгә күндереп булмый, бигрәк тә уенга әзерләнгән чакларына яки кәефсез вакытларына туры килсәң. Әлеге очраклар өчен минем үз тактикам бар. Әмма бу һөнәри сер, – дип елмая Артур Хәлилуллов.

Әлеге тактикасы уңышлы эшли. Бервакыт журналист Билалетдиновка шалтырата, ул вакытта тренер «Ак Барс»тан киткән генә була. Очрашырга ниятли, әмма әңгәмәнең килеп чыгасына үзе дә ышанып бетми. Ә Билалетдинов исә Казаннан киткәннән соң беренче зур интервью бирергә ризалаша да куя.

– Карьерамны башлаганда, мин спортта шундый абруй яулаган шәхесләрдән интервью алу хакында хыялландым. Хәзер инде мин бу бурычымны үтәдем, – ди Артур Хәлилуллов. – Әмма Татарстанда спорт тормышы гел кайнап тора, бик күп сыйфатлы материаллар язып була. Хәзер мин агентлыкта бик көчле спорт редакциясе булдыру турында хыялланам.

– МИНЕМ ӨЧЕН ЗИННӘТУЛЛА БИЛАЛЕТДИНОВ ҺӘМ ВЛАДИМИР АЛЕКНО ШӘХЕСЛӘРЕ ЗУР АБРУЙГА ИЯ. АЛАРНЫ ҺӘРВАКЫТТА ДА АЧЫКТАН-АЧЫК СӨЙЛӘШҮГӘ КҮНДЕРЕП БУЛМЫЙ, БИГРӘК ТӘ УЕНГА ӘЗЕРЛӘНГӘН ЧАКЛАРЫНА ЯКИ КӘЕФСЕЗ ВАКЫТЛАРЫНА ТУРЫ КИЛСӘҢ. ӘЛЕГЕ ОЧРАКЛАР ӨЧЕН МИНЕМ ҮЗ ТАКТИКАМ БАР. ӘММА БУ ҺӨНӘРИ СЕР.

PRESSA

Фото: Анна Арахамия

– КАЙЧАНДЫР БИРЕГӘ КИТЕРГӘН ӨЧЕН, ТОРМЫШ КОМПАСЫНА РӘХМӘТ

ТАТЬЯНА ВИТОВСКАЯ,
«Татмедиа» АҖ филиалы – «Яшел Үзән» мәгълумат үзәге медиа-директоры

Татьяна Витовская «Зеленодольская правда» газетасында гади журналисттан баш мөхәрриргә кадәр барлык хезмәт баскычларын уза. «Журналистикада исем» номинациясендә «Бәллүр каләм» иясе, Татарстан Журналистлар берлеге президиумы әгъзасы ул.

– Бу һөнәргә әле аяк кына баскан чакта, Мәскәү журналисты, шагыйрь Александр Ароновның («Если у вас нет собаки...» дигән җыр сүзләре аның каләменнән төшкән) бер белешмәлегенә юлыктым. Бу китап журналист һәм су уткәрүче һөнәренең охшашлыгы турында. Пунктларның берсе менә мондый: «Суның артык күп булуы да начар». Яшь чагымда бу сүзләр текстлар язуга гына кагыладыр кебек тоела иде, ә еллар узу белән аларның тормыш фәлсәфәсе турында да икәнен аңладым. Әйтик, безнең һөнәргә хас ташкындай ыгы-зыгыда үз миссияңне билгеләү хакында.

Журналистлык язмышын кеше үзе сайлап ала. Минем тәкъдир исә 37 ел район газетасы белән бәйле. Үкенмим. Көчле журналистларның төрле буыны белән горурлана алган «Зеленодольская правда» газетасында иң мөһим нәрсәләрне күрә-аера белергә өйрәттеләр. Беркайчан да сак куелмаган, баш мөхәррир бүлмәсенә урамнан теләсә кем керә алган редакциядә укучы белән газета арасында ышаныч дәрәҗәсе бер башка югарырак.

– Сезнең монда бар яктан ачык ишегалды кебек – керәләр, чыгалар! Эшләргә ирек бирмиләр! – дип зарланды күптән түгел бер практикант кыз.

– Балакаем, беркем дә килми торган редакция – чүп тә үсми торган үле кыр ул, – дип аңлатты аңа азу ярган өлкәннәр.

Миңа бәхет елмайды, «Зеленодольская правда»да җанлылык, терелек һәрвакыт булды һәм бар, аның булачагына да ышанам. Бу терелек газетаны типографиягә басарга җибәрергә дигән соңгы минутта беренче полосаны үзгәртергә мәҗбүр итә, чөнки яңа гына килеп ирешкән берәр яңалыкны «соңыннан»га тозлап куярга ярамый. Инде бөтенесен укып чыккан, макетка салган һәм тикшереп чыккан хезмәткәрләрнең күзенә карыйсың да күрәсең: аларда икеләнүнең әсәре дә юк – әйе, үзгәртәбез!

– ЖУРНАЛИСТИКА ШУЛ ЯГЫ БЕЛӘН ДӘ ЯХШЫ: АНДА «МИНЕМ УНИВЕРСИТЕТЛАРЫМ» БЕРКАЙЧАН ДА ТӘМАМЛАНМЫЙ. БИГРӘК ТӘ МӨХӘРРИР ВАЗЫЙФАСЫНДА. БЕЗ ҺӘРВАКЫТ БЕР АДЫМ АЛДА БУЛЫРГА, ТИЗ ҮЗГӘРҮЧӘН МУЛЬТИМЕДИА ДӨНЬЯСЫНДА ЯҢАЛЫКНЫ ЭЛӘКТЕРЕП АЛА ҺӘМ БАШКАЛАРГА ТАНЫП-БЕЛҮ ОМТЫЛЫШЫН ЙОКТЫРА БЕЛЕРГӘ ТИЕШ УКУЧЫЛАР БУЛЫП КАЛАБЫЗ.

ДИНАСТИЯ_ТМ

Безнең һөнәрдә беркайчан да штиль булмый. Бетмәс-төкәнмәс мәгълүмат ташкыныннан кеше, күп очракта гап-гади халык белән бәйле булганнары хәтергә төшә. Безнең буынга чын фронтовиклардан интервью алырга туры килде. Менә шулар «туганнар каберләрендә ник хач куелмаганын» да белә, кинофильмнардагы күренешләр белән бутап, сугыш турында әкияти истәлекләр дә уйлап чыгармый. Мин кояштай якты шәхес – Михаил Шоринны онытмаячакмын. Сугыштан яраланып-теткәләнеп кайта ул, яшәсәң, берәр ел яшәрсең, диләр аңа. Ә көләч йөзле, искиткеч яхшы күңелле бу абзый, Яшел Үзәндә Йөгерергә яратучылар клубы оештырып, йөзләгән кешегә сәламәтлек бүләк итте, үзе дә 80 яшенә кадәр яшәде әле.

Яшел Үзәннең төп урамнарын гөлбакчага әйләндергән кечкенә генә буйлы, тыйнак Екатерина Ошарина белән очрашуларны да хәтерләячәкмен. Ул җылы яклардан бездә үсмәгән үсентеләр алып кайта, сирень, гөлчәчәкләрнең гадәти булмаган сортларын эзли иде. Гомеренең соңгы елларын Раифа монастыренда үткәргән Екатерина Михайловна анда да үзе турында җылы истәлекләр калдырды – ул утырткан гаҗәеп матур үсемлекләр бүген дә күзне иркәли. Без үзебез дә «сүз белән генә түгел, эш белән дә» булдыра алабыз: әнә, сиреньле журналистлар аллеясы утырттык, анда Ошарина исемендәге сертификацияләнгән үсенте дә бар.

«Үзгәртеп кору» чорларында Конструкторлык бюросында төнгә кадәр барган чәкәләшүләрне онытмаячакмын, ул чакта җитәкчелекне ачык тавыш бирү юлы белән сайлау мөмкинлеге туган иде. Ә ПАТПда машина йөртүчеләрнең хезмәт хакын түләмәгән өчен забастовкага (гасыр башында ук онытылган сүз) чыгуы турында язарга туры килде. Һәр материал үзәгендә – тормышны яхшы якка үзгәртергә теләгән кешеләр.

Безнең һөнәр кайчагында, бәлки, беркайчан да уйламаган, кыюлыгың җитмәгән эшләрне башкарырга этәрә. 90 нчы елларда шәһәребездә беренче матурлык конкурсын, иске паркта бәйрәмнәр оештырдык. 2000 нче елларда «МирСМИмай», «МедиаFest» кебек язгы матбугат форумнарын үткәрдек. Инде биш ел «ТихоТVорение» бард җырлары фестивале белән шаккатырабыз, сәләтле инвалид балалар өчен «Оранжевое настроение» бәйрәме уздырып, кәефләрен күтәрәбез.

Журналистика шул ягы белән дә яхшы: анда «минем университетларым» беркайчан да тәмамланмый. Бигрәк тә мөхәррир вазыйфасында. Без һәрвакыт бер адым алда барырга, тиз үзгәрүчән мультимедиа дөньясында яңалыкны эләктереп ала һәм башкаларга таныпбелү омтылышын йоктыра белергә тиеш укучылар булып калабыз.

Иртәнге күңелле, рәхәт мизгелне – яңа гына чыккан газетаны ачып җибәргән вакытны бүген дә яратам әле. Редакциянең уңышына куанасың, әмма үз-үзеңне битәрләрлек берәр урынны һәрвакыт табасың. Ә ишек артында редакция казаны кайный башлый: «Ә машина кайда? Кичүне фотога төшерергә кирәк, анда күпер ишелгән...», «Карале, сайтта иртәдән үк аншлаг!», «Сезнең экология турында яза торган журналистларыгыз кайда утыра?..»

Болар барысы да минеке, тугандай якын... Кайчандыр бирегә китергәне өчен тормыш компасына рәхмәт.

« **– ИРТӘНГЕ КҮҢЕЛЛЕ, РӘХӘТ МИЗГЕЛНЕ** – ЯҢА ГЫНА ЧЫККАН ГАЗЕТАНЫ АЧЫП ҖИБӘРГӘН ВАКЫТНЫ БҮГЕН ДӘ ЯРАТАМ ӘЛЕ...



ДИНАСТИЯ_ТМ

– МИНЕМ ӨЧЕН МАТБУГАТТАГЫ ТОРМЫШ – ҺӘРВАКЫТ КҮРМӘГӘН-БЕЛМӘГӘН ДӨНЬЯГА СӘФӘР УЛ

ВЛАДИМИР ВИТОВСКИЙ,
«Татмедиа» АҖ филиалы – «Яшел Үзән» мәгълүмат үзәге җитәкчесе



Владимир Витовский – Татьяна Витовскаяның улы. «Новости Зеленодольска» сайты аның җитәкчелегендә «Алтын Гонг-2019» Бөтенроссия конкурсында җиңү яулаган.

– Мәктәптә Маяковский шигырен ятлаганым истә. Анда поэзия турында болай диелгән иде: «...езда в незнаемое, та же добыча радия. В грамм добыча, в год труды. Изводишь единого слова ради тысячи тонн словесной руды...» Минем өчен матбугаттагы тормыш – һәрвакыт күрмәгән-белмәгән дөньяга сәфәр ул, беркайчан да алда ни көткәнен белмисең.

Мәктәптә чакта ук компьютерга бәйле бөтен нәрсә кызыксындыра башлаган иде, хәтта Яшел Үзәннең «Подсолнух» балалар газетасында техника яңалыклары, интернет турында үз сәхифәмне дә алып бардым. Мәктәпне тәмамлагач, техник вузга укырга кердем, озак вакыт IT-өлкәдә эшләдем. Матбугат янә минем тормышыма үтеп керер дип уйламадым да.

Әмма 2011 елда «Яшел Үзән» телекомпаниясендә тулы техник җиһазландыру белән бәйле зур эш башкарырга тәкъдим иттеләр. Шул чакта техника сатып алу мөмкинлеге туды, яңа программаларга күчә алдык, телевизион тапшыруларның эфирга чыгарылуын үзгәртеп коруга ирештек.

Сайтны һәм социаль челтәрләрне актив үстерер вакыт җитте. Сайтка 1000 кеше керә башлагач, тагын да зуррак аудиторияне җәлеп итү өчен, уникаль яңалыклар эзләүгә керештек. 24/7 режимындагы эш бөтен редакцияне, журналистларның фикерләү рәвешен үзгәртеп коруны таләп итте.

«Яндекс» һәм «Гугл» алгоритмнарын өйрәнә-өйрәнә, яңа платформаларны бергәләп үзләштердек. Яшел Үзәндә яшәүче бер ханымның сумса рецепты кичә рекорд куйды – аны 38 мең тапкыр караганнар, ә иртәгә «Замана йөзләре» дип аталган борынгы фотографияләр проекты «үсеп китәчәк». Хәзер «ВКонтакте»дагы төркемебездә генә дә 25 мең чын язылучыбыз бар. Ә «Новости Зеленодольска» сайты ил күләмендә җиңүче булды.

Әмма безнең һөнәрдәге тормыш бетмәс-төкәнмәс сынаулардан, яңа үрләрдән гыйбарәт. Һәм ул шуның белән минем өчен кызыклы да. Үстерү-арттыру стратегияләрен, контент бирү формасын булдырып, популяр социаль челтәрләрнең берсендә 15 мең язылучы туплаган гына идек, хәзер менә «Телеграм»га җайлашабыз, янә аудитория җыябыз.

Кечкенә генә Яшел Үзәннән яңалыклар дөньясына нәрсә алып килә алабыз? Кәгазь версияне ничек саклап калырга (ә без традицион матбугат аудиториясенең кадерен беләбез: газета укучылар сирәгәя, әмма кәгазь формат элеккечә үк иң табышлысы)? Digital (цифрлы контент) керем китерсен өчен нишләргә? Үз-үзебезгә шушы сорауларны биреп, Мәгълүмат үзәгенең төп эш принцибын формалаштырабыз – сыйфатны югалтмыйча, колачны киңәйтү. Ә бу исә әүвәлгечә үк күрмәгән-белмәгән дөньяга мавыктыргыч сәфәр.

– ЯШЕЛ ҮЗӘНДӘ ЯШӘҮЧЕ БЕР ХАНЫМНЫҢ СУМСА РЕЦЕПТЫ КИЧӘ РЕКОРД КУЙДЫ – АНЫ 38 МЕҢ ТАПКЫР КАРАГАННАР, Ә ИРТӘГӘ БОРЫНГЫ ФОТОГРАФИЯЛӘР ПРОЕКТЫ «ҮСЕП КИТӘЧӘК».

ДИНАСТИЯ

– КЛАССИК ЖУРНАЛИСТИКА ПРИНЦИПЛАРЫНА НИГЕЗЛӘНЕП, DIGITAL-КОНТЕНТ БУЛДЫРАМ

КСЕНИЯ ВИТОВСКАЯ,
«Playmaker» маркетинг агентлыгының башкарма директоры, Мәскәү шәһәре

Татьяна Витовскаяның кызы Ксения Витовская – «Алтын каләм» республика фестиваленең Гран-при иясе, 2013 елгы Универсиада дирекциясенең матбугат хезмәтендә эшләгән...

– Тугыз ел элек Казан федераль университетының журналистика факультетын тәмамладым, – дип сөйли Ксения. – Бу вакыт эчендә яңалыклар һәм контент куллану ысулы тамырдан үзгәрде. Укучыларның күп өлеше цифрлы чыганакларга күчте, мәгълүмат тапшыру тизлеге берничә тапкыр артты. Журналистика цифрлаштыруның яңа гасырына аяк басты, һәм без аудиторияне саклап калу өчен цифрлы проектларга көннән-көн күбрәк көчә барабыз.

Мин басма матбугатта эшли башладым, соңрак 2013 елгы Универсиада дирекциясенең матбугат хезмәтендә чарландым. Нәкъ менә шул вакытта без сайтта тиз-тиз чыгып торган яңалыкларның беренче чиратта таләп ителүен аңладык. Универсиада елында, Халыкара студентлар спорты федерациясе белән берлектә, 10 илдән килгән яшь репортерлар өчен Журналистика мәктәбе оештырырга булдык. Лектор сыйфатында, Россия журналистларыннан тыш, Канада, Швейцария, Германия һәм АКШтан да белгечләр чакырдык. Алар сафында Олимпия уеннарының баш колумнисты, «Эмми» бүләге иясе Алан Абрахамсон һәм Халыкара спорт матбугаты ассоциациясе вице-президенты Александр Долгополовның булуына без бик шат идек. Лекцияләрдән соң мин Россиядә медиа-тармакны зур үзгәрешләр көткәнен аңладым. Соңрак без журналистларның үз брендларын булдырып (Юрий Дудь, Екатерина Гордеева кебек) эшләвен дә, федераль басмаларның онлайн язылу мөмкинлеге кертергә мәҗбүр булуын да, һәм башкаларны да күрдек.

Мин нәкъ менә шушы республикабызда туып-үсүемне зур уңыш дип саныйм һәм моның өчен язмышыма рәхмәтлемен, Универсиада минем киләчәгемне билгеләде. Бүген мин Россия һәм халыкара дәрәҗәдәге спорт клублары һәм лигалары өчен креатив digital-контент булдыру белән шөгыльләнә торган агентлыкта эшлим.

Һәм без классик журналистиканың нигез принципларына таянабыз (КФУдагы укытучым, диплом җитәкчем Светлана Каим кызы Шәйхетдиновага чиксез рәхмәтләрем): фактларны һәрвакыт җентекләп өйрәнәбез, гавамга чыгарыр алдыннан мәгълүмат чыганакларын тикшерәбез, этика кагыйдәләрен бозмыйбыз, һәм иң мөһиме – үз аудиториябез өчен эшлибез һәм аның тормышын кызыклырак, кайчагында шатлыклырак, әмма шул ук вакытта мәгълүматлы һәм файдалырак итәргә тырышабыз.

– МИН НӘКЪ МЕНӘ ШУШЫ РЕСПУБЛИКАБЫЗДА ТУЫП-ҮСҮЕМНЕ ЗУР УҢЫШ ДИП САНЫЙМ ҺӘМ МОНЫҢ ӨЧЕН ЯЗМЫШЫМА РӘХМӘТЛЕМЕН, УНИВЕРСИАДА МИНЕМ КИЛӘЧӘГЕМНЕ БИЛГЕЛӘДЕ.

ДИНАСТИЯ_ТМ

– ОФЫКЛАРНЫ КИҢӘЙТӘ ТОРГАН ҺӨНӘР

ТАТЬЯНА КОВАРИНА,
«Яшел Үзән» телекомпаниясендә телетапшырулар алып баручы һәм хәбәрче

Татьяна Витовскаяның килене Татьяна Коварина журналист булырга хыялланмаган да. Ләкин...

– 2012 ел. «Икътисадчы» белгечлеге буенча КМТТУ-КАИны кызыл диплом белән тәмамладым, – дип искә ала Татьяна. – Һәм кинәт телевидениедә тапшырулар алып баручылар кастингы турында белдерүне күреп алдым, шунда катнашып карарга карар кылдым, чөнки студент елларында, иҗади һөнәрнең төгәл фәннәргә караганда җаныма якынрак икәнен аңлап, «Студентлар язы» фестивалендә, күп кенә шәһәр чараларында чыгыш ясадым. Һәм менә беренче тапкыр эфирга чыгу, хәбәрче сыйфатында беренче сюжет төшерүләр, телекомпаниянең интернет-каналында эшләү. Барысы да бөтереп алып кереп китә, барысы да кызык һәм мавыктыргыч.

Журналист һөнәренең офыкларны киңәйтүенә бер генә мисал. 2017 елның 9 июле. Чувашия белән Татарстан чигендә таң вакыты. Безнең телевизион төшерү төркеме, «Ефәк юлы» раллиен оештыручылар һәм артистлар 35 илдән килгән катнашучыларны каршы ала. «КАМАЗ-мастер»ның легендар экипажларыннан берсен көтәбез. Әмма һич уйламаганда, беренче булып Франция һәм Монако вәкилләре – танылган пилотлар Себастьян Леб һәм Даниэль Елена килеп туктый. Уйлап-нитеп торырга вакыт юк, интервью алу өчен, оператор белән машина янына очабыз. Шул арада сорауларны инглиз телендә бирергә кирәклеген дә аңлап өлгерәм. Инглизчәмнең камиллектән ерак икәнлегенә үкенергә җитешә алмыйм, шуңа күрә бөтен белгән сүзләремне искә төшереп, белмәгәнен ишарәләр белән аңлатам. Һәм беркайчан да онытылмаячак «Ефәк юлы» турында бик тулы җавап алуга ирешәм.

– УЙЛАП-НИТЕП ТОРЫРГА ВАКЫТ ЮК, ИНТЕРВЬЮ АЛУ ӨЧЕН, ОПЕРАТОР БЕЛӘН МАШИНА ЯНЫНА ОЧАБЫЗ. ШУЛ АРАДА СОРАУЛАРНЫ ИНГЛИЗ ТЕЛЕНДӘ БИРЕРГӘ КИРӘКЛЕГЕН ДӘ АҢЛАП ӨЛГЕРӘМ. ИНГЛИЗЧӘМНЕҢ КАМИЛЛЕКТӘН ЕРАК ИКӘНЛЕГЕНӘ ҮКЕНЕРГӘ ҖИТЕШӘ АЛМЫЙМ, ШУҢА КҮРӘ БӨТЕН БЕЛГӘН СҮЗЛӘРЕМНЕ ИСКӘ ТӨШЕРЕП, БЕЛМӘГӘНЕН ИШАРӘЛӘР БЕЛӘН АҢЛАТАМ.

PRESSA

ДИНАСТИЯ_ТМ

– ДӨНЬЯДА АКЛЫК ТА БАР!

ЗИННУР ХӨСНИЯР,
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Салават күпере» редакциясе җитәкчесе, «Сәхнә» журналының баш мөхәррире

Журналистика факультетында укымаса да, студент елларыннан ук Зиннур Хөсниярның язмалары төрле газета-журналларда басыла. Ә дүртенче курста укыганда аны «Ялкын» журналына эшкә чакыралар. Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетында укып йөргән егет әнә шулай үзеннән-үзе иҗат юлына кереп китә.

Зиннур Зыятдин улы Хөсниярны белмәгән кеше юктыр: язучы, нәшир, баш мөхәррир. Бүген ул «Сәхнә» журналын җитәкли. Һич кенә дә аны мәктәпнең иң шук, начар укучысы дип күз алдына китерергә мөмкин түгел. Ә бит чынлыкта шулай булган.

– Татар теле һәм әдәбияты дәресеннән башка бер фәнне дә яратмадым, – дип сүзен башлады Зиннур Зыятдин улы. – Шуның өстенә тыңлаусыз, шук укучы да идем. Ә менә урта сыйныфларга җиткәч үзгәрдем. Тәртип ягыннан да, укуым да. Акыл керү шулдыр инде.

Мәктәпне тәмамлагач, яшь егет КДПИның тарих-филология факультетына укырга керә. Укытучы булу белән бергә, тирән белем аласы килә аның.

– Бәхетем – институтта чын мөгаллимнәр, әдәбият галимнәре белән таныштым, – дип сөйли Зиннур абый. – Шуларның берсе – Рифат Сверигин, бик изге күңелле кеше иде. Ул минем беренче хикәяләремне укып, киңәшләрен биреп, биш ел буе кулдан өстерәп диярлек алып барды. Институтта «Илһам» түгәрәге бар иде. Беренче курста ук шунда язылдым, озакламый беренче повестемне яздым. Бүгенгедәй хәтерлим, басу машинкалары чыга башлаган чак. Тулай торакта студентлар оешмасы бар иде. Шунда «Прогресс» язу машинкасы кайткан. Төннәр буе качып кына әнә шул машинкада повестемне җыйдым. Нәтиҗәдә, эшләп бетергәндә секретарь-машинисткалар кебек тиз басарга өйрәндем. Һәм ул миңа киләчәктә бик кирәк булды.

Әнә шулай әрсезлеге белән Зиннур абый кул арасына, дөресрәге, редакцияләргә керә. Шул үҗәтлеге аңа егерме тугыз яшендә балалар өчен журнал нәшер итәргә булыша. Дөрес, мөхәррир бу эшен ни чарадан бичара килеп чыкты, ягъни башкача мөмкин түгел иде, дип саный.

– Студент чагыннан ук «Ялкын» журналында эшли башлаганга, газета-журналларның эчке кухнясын белә идем, – дип дәвам итте Зиннур Хөснияр. – Мин инде өйләнгән, ике кечкенә бала атасы. Бик болгавыр заманнар. Телевизорны карап булмый, бигрәк тә Мәскәү каналларын. Анда гел сугыш, кем кемне аткан, үтергән, гел пычраклык, порнография... Берсендә шулай күрәм, кечкенә кызым белән улым, дөньяларын онытып, телевизор карап утыра. Тукта, мин әйтәм, балалар бу яшьтән җүнсез әйбер күреп үсә. Болар кем булыр, кая барабыз, нишләвебез бу?! Башыма күсәк белән суккан кебек булды. Менә шунда матурлык турында яңа журнал яки газета уйлап табарга кирәк дигән фикер килде.

Зиннур абый кечкенәләр өчен төсле журнал чыгарырга дигән нияткә килә, чөнки татарда андый басма булмый. Бурычка фәлән мең акча алып торулар, кәгазьне Финляндиядән кадәр кайтартулар (Россиядә андый сыйфатлы кәгазь юк) – бүген болар барысы да гайре табигый хәл кебек тоела. Бик күпләр аңа: «Булмый ул, йөрмә», – дип «акыллы» киңәш бирә. Ләкин Зиннур Зыятдин улы бирешә торганнардан түгел, куйган максатына тугры кала.

– Ринат Мөхәммәдиев «Салават күпере» журналын Россия язучылар съездына алып барган, – диде әңгәмәдәшем. – Шунда Сергей Михалков «Салават күперен» күрсәтеп: «Менә татарлар балалар өчен затлы, ялтыравыклы фин кәгазендә, фин буяулары белән нинди журнал чыгарып ята, татарлардан үрнәк алыгыз!» – дип, бөтен съезд кунакларына күрсәткән. Бу хәлдән соң республикада безнең басмага, шул исәптән миңа да, игътибар тамырдан үзгәрде.

Әнә шундый үҗәт, көчле холыклы кеше Зиннур Хөснияр. Аның бүген дә үз кыйбласы, үз фикере бар. Шуңа да аның сүзенә колак салалар, ихтирам итәләр.

- БАЛАЛАРЫБЫЗ КЕМ БУЛЫР, КАЯ БАРАБЫЗ, НИШЛӘВЕБЕЗ БУ?! БАШЫМА КҮСӘК БЕЛӘН СУККАН КЕБЕК БУЛДЫ. МЕНӘ ШУНДА МАТУРЛЫК ТУРЫНДА ЯҢА ЖУРНАЛ ЯКИ ГАЗЕТА УЙЛАП ТАБАРГА КИРӘК ДИГӘН ФИКЕР КИЛДЕ.

Фото: Анна Арахамия

ДИНАСТИЯ_ТМ

– ЖУРНАЛДА ЭШЛИ БАШЛАГАЧ, ӨЕМӘ КАЙТКАНДАЙ БУЛДЫМ

ЗИЛӘ ФӘЙЗУЛЛИНА,
«Салават күпере» һәм «Сабантуй» балалар журналларының баш мөхәррире

Ул әле үзен чын журналист булып җитештем дип санамый. Югыйсә бүген иң актив эшләүче баш мөхәррирләрнең берсе. Иң күп тиражны да ул җитәкләгән басмалар җыя. Нәрсә бу – тыйнаклыкмы, әллә үз-үзеңә карата артык таләпчәнлекме? «Сабантуй», «Салават күпере» журналлары баш мөхәррире Зилә Зиннур кызы Фәйзуллина белән нәкъ шул хакта сөйләштек.

– Минем өчен чын журналистика – саллы, фикерле шәп язмалар ул,- ди Зилә Зиннур кызы. – Без исә кыска әкият һәм хикәяләр белән эшлибез. Ә алар күбрәк әдәбият өлкәсенә карый. Әкият, хикәяләрне үзем яза һәм редакцияли алам. Тик менә саллы язмалар турында алай дип әйтә алмыйм әле.

Шәһәр кызы булуга карамастан, Зилә Фәйзуллинаның татарчасы камил. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен яраткан, олимпиадаларда катнашкан. Хәер, Хөсниярлар гаиләсендә бүтәнчә мөмкин дә булмаган.

– Энем белән миңа беркайчан да өйдә рус телендә сөйләшергә рөхсәт бирелмәде, – дип дәвам итте әңгәмәдәшем. – Кечкенә чагымда моңа бераз аптырый идем, чөнки яшьтәшләремә әти-әниләре андый чик куймый иде. Безнең өйдә исә бөтенләй икенче мохит. Өебездә киштә-киштә китап... Нигездә алар татар телендә. Әти соңгы акчасына да китап сатып алып кайта иде. (Бу сыйфат миңа да күчкән.) Үсә төшкәч, әлеге китапларны әти мәҗбүри рәвештә диярлек безгә укытты. Энем белән икәү әнә шулай әдәбият дөньясында тәрбияләндек.

Алда әйтелгәнчә, «Салават күпере» журналын Зиннур Хөснияр нәкъ менә үз балалары өчен нәшер итә башлый. Ә редакция егерме ел дәвамында ТР Язучылар берлеге бинасында утыра. Зиләнең балачагы да әнә шунда – әтисенең эш урынында уза. Ул үзен аерым бер дәүләттә үстем, дип саный.

– «Салават күпере» белән бергә, әти тагын берничә татар газетасы да чыгарды бит, – дип дәвам итте Зилә Зиннур кызы. – Язучылар берлеге белән без яшәгән йорт арасы ике тукталыш кына, шуның өчен күп вакыт каләм әһелләре безнең фатирга кайта иде. Безнең әни бик сабыр, кунакчыл кеше, ник берсенә каршы сүз әйтсен. Гаиләсенә әзерләгән ризыкны салып бирә иде. Бик күп язучы, шагыйрьләр белән якыннан аралашып үстем. Өйдә очрашмасак, Язучылар берлегендә булса да күрешә идек.

Ни гаҗәп, әнә шулай үскән кыз әтисе юлыннан китәргә хыялланмый. Бу һөнәрнең барлык нечкәлекләрен белгәнгәме, әдәбият, журналистика юлын сайламыйм, дип кырт кисә. Һәм КДУның социология факультетына укырга керә.

– Социология юнәлешендә укыганга бер дә үкенмим, бик төпле белем бирделәр безгә, – диде Зилә Зиннур кызы. – Әле аннан соң психология факультетын да тәмамладым. Аспирантурага да психология буенча кердем. Максатым – кандидатлык диссертациясен яклау һәм алга таба студентларны укыту иде.

Ләкин, һич көтмәгәндә, югары белем алган яшь белгечнең юлы бөтенләй икенче якка кереп китә. Санаулы вакыт эчендә ул «Салават күпере» журналын чыгара башлый. Әңгәмәдәшем ул чакларны болай дип искә алды:

– Җәйге ял вакытында әти журнал укучылары арасында социологик тикшеренү уздырырга кушты. Балалар бакчалары, мәктәпләргә барып, укытучы, тәрбияче, балалар белән сөйләшеп, аларның кызыксынуларын белешүемне сорады. «Салават күпере» өчен заманга яраклаштырып, фәнни нигезләнгән яңа сәхифәләр уйлап чыгарырга кирәк иде. Мин ризалаштым һәм... килеп каптым. Журналда эшли башлагач, өемә кайткандай булдым, монда мин үземне судагы балык кебек хис итәм.

Әнә шулай, үзе дә сизмәстән, редакция эшенә кереп китә ул. Кызының күзендә очкын, ташып торган яңа идеяләрне күргән әти кеше «Салават күпере» журналын тулысынча Зиләгә тапшыра. Менә инде унике ел бу яшь ханым әлеге эшенә тугры кала. Ике ел элек «Татмедиа» җитәкчелеге аңа «Сабантуй» журналын да ышанып тапшыра. Монда да заманча идеяләр кирәк була. Төп эшкә нәниләр өчен төрледән-төрле видеопроект, китаплар чыгару да өстәлә. Ул бүген өенә йокларга гына кайта. Журналлар турында ул «балаларым» дип сөйли. Шуннан барысы да аңлашыла кебек...

– ӨЕБЕЗДӘ КИШТӘ-КИШТӘ КИТАП... НИГЕЗДӘ АЛАР ТАТАР ТЕЛЕНДӘ. ӘТИ СОҢГЫ АКЧАСЫНА ДА КИТАП САТЫП АЛЫП КАЙТА ИДЕ. ҮСӘ ТӨШКӘЧ, ӘЛЕГЕ КИТАПЛАРНЫ ӘТИ МӘҖБҮРИ РӘВЕШТӘ ДИЯРЛЕК БЕЗГӘ УКЫТТЫ. БЕЗ ӘНӘ ШУЛАЙ ӘДӘБИЯТ ДӨНЬЯСЫНДА ТӘРБИЯЛӘНДЕК.

Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store

Google Play

Реклама 6+

ДИНАСТИЯ_ТМ

– БЕРНӘРСӘ ДӘ ОЧРАКЛЫ ҺӘМ ЮККА ГЫНА ТҮГЕЛ

ЛӘБИБ ЛЕРОН,
«Безнең мирас» журналының баш мөхәррире

Лемон Лерон улы үзенең беренче тапкыр интервью алуын гомерлеккә хәтерендә калдырган. Әңгәмәдәшен, республикада беренче быргычы Ләйлә Латыйпованы да. Билгеле, кыз быргыны 1920 нче еллар башында, илдә пионер хәрәкәте аякка баскан мәлдә кычкырткан. Яшь журналист Ләбиб Лерон исә быргычы кыз белән әлеге вакыйгалардан соң 60 елдан артык вакыт үткәч әңгәмә корган.

– Сөйләшү шактый кызык килеп чыкты. Саубуллашыр вакыт җиткәндә, мин: «Ә сез хәзер ни белән шөгыльләнәсез?» – дип сорап куйдым. Ул исә: «Балык тотам!» – ди. Гаҗәпләнүдән баскан җиремдә катып калдым. Әлбәттә, безнең авылда да тракторчы кызлар бар иде, әмма яше җитмештән узган хатын-кызның кармак белән балык тотуы миңа гайре табигый тоелды.

Шунысын да әйтергә кирәктер: «Безнең мирас» журналының хәзерге баш мөхәрриренең беренче язмалары пионерларның «Яшь ленинчы» газетасында әле мәктәптә укыган чагында ук басыла. Ләбиб Лерон практикасын да шунда үтә.

Яшь журналистны «азу ярган» каләм әһеле – Нияз Акмал кулына ышанып тапшыралар.

– Иң беренче күргән мәлдә ул телефоннан сөйләшә иде, һәм бу бер тапкыр да әлеге аппаратны тотып карамаган мин фәкыйрегез – авыл малае өчен чын ачыш булды! – дип көлә Лемон Лерон улы. – Инде профессиональ журналист сыйфатында язган тәүге материалымны да хәтерлим, ул яшь хоккейчы Эдик турында иде.

Әмма журналистлык эшенең башында Ләбиб Леронның исендә калган иң кадерле хатирә – «Яшь ленинчы» редакциясенең тату коллективы белән «Пионерстан урамы» дигән стенгазета чыгарулары. Редакциянең озын коридорының буеннан буена сузылган газетаның авторлары шагыйрьләр Зөлфәт белән Нияз Акмал, Фоат Хәмидуллин һәм башкалар була. Кызык фотосурәтләр, фельетоннар, сатирик язмалар, шигырь һәм бәетләрне укырга теләүчеләр гаять күп җыела.

– Күптән түгел генә уйлап утырдым әле, – дип сөйли Лемон Лерон улы. – Хәзер мин җитәкләгән журнал «Безнең мирас» дип атала бит. Бу – тикшеренүләрдә, фотосурәтләрдә, әдәби текстларда, фольклорда сакланган тарих. Һәм нәкъ менә шул мине балачактан ук мавыктырган нәрсәләр икән бит. Малай чагымда ук мин калын дәфтәр ачтым да, анда әбием җырлаган җырларның сүзләрен, танышларым яки якыннарым сөйләгән мәзәк яки такмакларны пөхтәләп язып бара башладым. Моның ни өчен кирәк булуын үзем дә аңламадым әле ул чакта. Хәзер исә, дистәләрчә ел узгач, моның очраклы гына булмавына төшендем. Бу – балачактан ук мин сайлаган юл икән бит.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ ХӘЗЕРГЕ БАШ МӨХӘРРИРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЯЗМАЛАРЫ ПИОНЕРЛАРНЫҢ «ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ» ГАЗЕТАСЫНДА ӘЛЕ МӘКТӘПТӘ УКЫГАН ЧАГЫНДА УК БАСЫЛА.

Фото: Анна Арахамия

ДИНАСТИЯ_ТМ

– ЖУРНАЛИСТ БУЛУ НИНДИ РӘХӘТ ИКӘН, БӨТЕН ҖИРДӘ СЫЙЛЫЙЛАР!

АЙСЫЛУ ЛЕРОН,
«Тәртип» радиосының PR-бүлеге җитәкчесе

1997 ел. «Тамчы» телепрограммасының алып баручысы унике яшьлек Айсылу үзенең беренче сюжетын төшерә. Танылган җырчы Гөлзада Сафиуллина төшерү төркемен үзенең студиясенә чакыра. Әңгәмә бик җылы килеп чыга, өстәвенә, бик тәмле дә була – җырчы апа тәмле ризыклар һәм чәй белән сыйлый.

– Аннары исә без шәһәр мәктәпләренең берсендә сюжет төшердек, анда да кунак иттеләр, – дип көлә Айсылу. – Мин шул чакта: «Кара, журналист булу нинди рәхәт икән, бөтен җирдә сыйлыйлар!» – дип сөенүем хәтердә. Һөнәрдән алган тәүге тәэсирләр менә шундый җылы булып чыкты.

Сүз дә юк, журналистикадагы 25 ел эчендә төрлесен күрергә туры килә. Әмма Айсылу фикеренчә иң мөһиме – иҗат итү һәм һөнәри яктан камилләшү өчен гаять зур мөмкинлекләр булу. Аңа электрон мәгълүмат чараларында, радиода эшләргә туры килә, мәкаләләрен журналларда да бастыра. Шулай да Айсылу Лерон нәкъ менә телевидениене журналистлык эше өчен иң файдалы мәктәп дип саный.

– Телевизион журналист булу – командада эшли белү ул, – дип сөйли Айсылу. – Исемдә әле, без, кечкенә кызлар булсак та, сюжет төшерергә барганда машина йөртүчене дә үзебез эзли идек, операторлардан үзебез теләгәнчә төшерүләрен үтенә идек. Әйе, сөйләшергә, барысын да җайларга кирәк, чөнки ул елларда иң кечкенә сюжетны әзерләүгә дә 5-6 кешелек зур команда җәлеп ителде.

Айсылу кадрда эшли, аны таныйлар, чөнки 1990 нчы еллар җирле телевидениенең гөрләп эшләгән чагы була. Казан университетының журналистика факультеты мөгаллимнәре «Татарстан» БДТРК дә эшләүче яшь кызны: «Без сезне нәрсәгә өйрәтә алабыз соң инде?» – дип шаяртып каршы ала.

– Күп нәрсәгә өйрәттеләр! – дип көлә бүген Айсылу. – Кадрда эшләүнең анык кагыйдәләре булуын белү бигрәк тә кызык булды, без аларны эчке сиземләвебезгә таянып нәкъ шулай эшләгәнбез булып чыкты. Бу күп нәрсәгә ачыклык кертте. Ә менә суык көндә башлыксыз һәм хәтта пальтосыз да стендап яздырганда ни өчен бер тапкыр да салкын тимәде – монысын берничек тә аңлатып булмый. Экрандагы матур сурәт өчен әллә нәрсәләргә риза булырлык шул!

Әмма, Айсылуның тәҗрибәсе күрсәткәнчә, хикмәт сурәттә генә дә түгел. 2011 елда, радиода эшләгәндә, аңа теләкләрне тормышка ашыручы булырга туры килә! Үзенең 10 еллык юбилеена Tatar Radiosi радиостанциясе ун тугры тыңлаучысының теләген үтәргә вәгъдә бирә. Айсылу әлеге проект өчен җаваплы була.

Бер тыңлаучы «КАМАЗ» машинасын җыюны үз күзе белән күрергә тели. Автогигант җитәкчелеге белән сөйләшергә туры килә. Бәхеткә, барысы да уңай хәл ителә. Чираттагы теләк – Казан өстеннән очу! Һәм менә инде Айсылу гашыйк парларны Коркачык аэродромына алып бара.

– Мин алар икәү генә очар дип уйлаган идем, һәм кинәт тагын бер урын булуы ачыклана. Мин йөкле идем, шулай да әлеге тәкъдимнән баш тарта алмадым. Һәм бу искиткеч мизгелләр булды – очучы күктә ниләр генә эшләп күрсәтмәде! Димәк, унике яшемдә мин барысын да бик дөрес аңлаганмын: чыннан да, минем һөнәрем бик бай булып чыкты. Тәэсирләргә, әлбәттә!

2011 ЕЛДА, РАДИОДА ЭШЛӘГӘНДӘ, АҢА ТЕЛӘКЛӘРНЕ ТОРМЫШКА АШЫРУЧЫ БУЛЫРГА ТУРЫ КИЛӘ! ҮЗЕНЕҢ 10 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕНА TATAR RADIOSI РАДИОСТАНЦИЯСЕ УН ТУГРЫ ТЫҢЛАУЧЫСЫНЫҢ ТЕЛӘГЕН ҮТӘРГӘ ВӘГЪДӘ БИРӘ. АЙСЫЛУ ӘЛЕГЕ ПРОЕКТ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ БУЛА.

ДИНАСТИЯ_ТМ

– МИН ИНДЕ ҮЗЕБЕЗНЕҢ ЖУРНАЛИСТЛАР ДИНАСТИЯСЕН ДӘВАМ ИТТЕРӘМ

ФӘРИДӘ ГАТИНА (10 яшь),
«Сабантуй» журналының яшь хәбәрчесе

Яшь хәбәрче Фәридә Гатинаның журналистикага бәйле күңелле мизгелләре әле бик күп түгел. Әмма бу бит ирешеп булырлык нәрсә! Иң мөһиме, алар арасында инде озак елларга хәтергә уелачак бер очрак бар.

Күптән түгел генә «Сабантуй» журналы редакциясенә Марат Әхмәтов килде. ТР Дәүләт Советы вице-спикеры республикабыз Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясен җитәкли. Татар телендә язучы һәм Ютуб-каналларда татарча тапшырулар алып баручы яшь журналистларга ул үзенең җылы теләкләрен җиткерде. Һәм һәркайсына чын журналист таныклыгын тапшырды!

– Бу бик дулкынландыргыч һәм рәхәт булды, – дип искә ала тантаналы мизгелләрне Фәридә. – Әйе, миңа әле ун яшь кенә, тик мин инде үзебезнең журналистлар династиясен дәвам иттерәм. Хәзер инде рәсми рәвештә!

КҮПТӘН ТҮГЕЛ ГЕНӘ «САБАНТУЙ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕНӘ ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ВИЦЕ-СПИКЕРЫ МАРАТ ӘХМӘТОВ КИЛДЕ. ЯШЬ ЖУРНАЛИСТЛАРГА УЛ ҮЗЕНЕҢ ҖЫЛЫ ТЕЛӘКЛӘРЕН ҖИТКЕРДЕ. ҺӘМ ҺӘРКАЙСЫНА ЧЫН ЖУРНАЛИСТ ТАНЫКЛЫГЫН ТАПШЫРДЫ!

PRESSA

ДИНАСТИЯ_ТМ

– ЖУРНАЛИСТИКАНЫҢ АЛТЫН ЧОРЫНДА ЭШЛӘДЕК

ӘСГАТЬ ҖӘЛӘЛИЕВ:
Апас районы «Йолдыз» газетасының элеккеге баш мөхәррире

Район җирләрендә дә бик көчле журналистлар эшли. Андыйлар белән очрашкач: «Шәһәргә китсә, таулар күчергән булыр иде», – дип уйлыйсың. Апас район үзәгендә яшәүче Әсгать Җәләлиев та әнә шундыйлардан берсе. Гомерен журналистикага багышлаган каләм иясенең тормыш көндәлегендә ниләр генә юк! Гади журналисттан баш мөхәррир вазыйфасына ирешкән, әле шул аралыкта алты ел колхоз рәисе булып эшләгән бик үзенчәлекле шәхес ул.

Әсгать Борһан улы журналистика юлын ни өчен сайлаганын төгәл әйтә ала – балачактан инша язарга ярата. Өстәвенә, аның һәр нәрсәгә үз фикере була. Шуңа да мәктәптә яхшы укыган егет КДУның журналистика бүлегенә укырга керә.

– Мин үземне бик бәхетле дип саныйм – юлымда чын остазлар очрады,- дип сүзен башлады Әсгать абый. – Һичшиксез, шуларның берсе Флорид Әгъзамов иде. Университетны тәмамлагач та, юллар аерылмады – гомер буе аралаштык. Вафатына берничә атна кала, журналистика факультеты деканы Васил Гарифуллин белән Флорид абый янына хастаханәгә бардык. Остазым белән соңгы күрешү әле дә күз алдымда тора...

Әсгать Җәләлиев журналистикага 1970 нче еллар башында килә. Район газетасы «Йолдыз»да эшли башлый ул. Яшь егет район халкының тормышын гына яктыртып калмый, тәнкыйть мәкаләләре дә яза.

– 1970-2000 нче елларны журналистиканың алтын чоры дип саныйм, – дип дәвам итте Әсгать абый. – Ул чагында журналистның сүзенә игътибар гаҗәп зур иде. Бер генә дәлил китерәм: бик хөрмәт иткән, гомер буе колхоз рәисе булып эшләгән Хәмит Мингалиев бар. Уенын-чынын кушып ул болай сөйли иде: «Райком секретаре килә дип әйтсәләр, «Ярар, килер дә китәр», – дип уйлыйм, ә менә редакциядән фәлән журналист килә дисәләр, авыл башына чыгып каршы ала идем». Әлбәттә, ул моны азрак салам кыстырып сөйли, әмма аның сүзләрендә дөреслек бик зур. Әгәр журналист газетага мәкалә язып чыгарса, ул җитәкчеләр тарафыннан игътибарсыз калмады. Тәнкыйть язмасымы, мактап язылганмы – мөһим түгел.

Журналистика факультетында укыганда безне: «Сүз – иң көчле корал», – дип өйрәтәләр иде. Әсгать Борһан улы бу фикер белән тулысынча килешә. Алай гына да түгел, эшләү дәверендә ул моның дөреслегенә берничә тапкыр инанган.

– ӘГӘР ЖУРНАЛИСТ ГАЗЕТАГА МӘКАЛӘ ЯЗЫП ЧЫГАРСА, УЛ ҖИТӘКЧЕЛӘР ТАРАФЫННАН ИГЪТИБАРСЫЗ КАЛМАДЫ. ТӘНКЫЙТЬ ЯЗМАСЫМЫ, МАКТАП ЯЗЫЛГАНМЫ – МӨҺИМ ТҮГЕЛ.

Фото: Зилә Мөбарәкшина

ДИНАСТИЯ_ТМ

– Берничә мәкаләм аркасында оялырга да туры килде, – диде ул. – Сүз белән аерым кешеләрне рәнжеттем. Дөрес, аннары мин алардан гафу үтендем. Аңлаштык, дуслаштык, ләкин ул хаталар гомер буена истә калды...

Әсгать абый белән колхоз рәисе булып эшләгән чоры турында да сөйләштек. Һәр журналистка мондый бәхет (ә бәлки киресенчә) тәтеми бит!

– Журналистикадан да тәмлерәк иҗат бар. Ул – кырга чәчкән игенеңнең шытып чыгып, күкрәп үсеп утыруын күрү, – ди Әсгать Җәләлиев. – Мин моны колхоз рәисе булып эшли башлагач кына аңладым.

– Ә ничек сезне рәис итеп куйдылар? – дим.

– Артык үткен сүзле булганга, комачаулап йөрмәсен дипме, яки кешене күп өйрәттең, эшләп күрсәт дипме, районның иң зур, иң усал авылы Олы Бакырчыга колхоз рәисе итеп куйдылар. Ул минем туган авылым да. 2000 нче еллар башы, бик авыр чор. Колхозның ни техникасы, ни чәчүлеге юк... Аллаһының рәхмәте, аерым кешеләрнең ярдәме белән эшләрне җайга сала алдык. Авылдашларым миңа карата хәерхаһ булды. Бик матур эшләдек. Дөресен генә әйткәндә, андый мөнәсәбәт көтмәгән дә идем.

Алты елдан соң Әсгать Җәләлиев янәдән «Йолдыз» газетасына – баш мөхәррир вазыйфасында әйләнеп кайта. Сигез ел эшләгәннән соң, лаеклы ялга китәргә санаулы айлар калганда, үзе теләп эштән китә.

– Үз-үземә каршы килә алмыйм, холкым шундый, – ди Әсгать абый. – Җитәкчелек белән кайбер фикерләр туры килми башлагач, гариза яздым.

– Ә бүген нәрсә булса да язасызмы? – дим.

– Юк. Редакциядән киткәннән бирле бер җөмлә дә язганым юк. Кулда хәзер Коръән китабы. Ә эшләгән чорларны еш искә алам. Җитмешенче, сиксәненче елларда газета-журналларда цензура көчле иде, дип сөйлиләр. Әйе, анысы да бар иде. Ләкин журналист сүзе гел беренче булды. Ни кызганыч, бүген хәл бүтәнчә дип күрәм...

– ЖУРНАЛИСТИКАДАН ДА ТӘМЛЕРӘК ИҖАТ БАР. УЛ – КЫРГА ЧӘЧКӘН ИГЕНЕҢНЕҢ ШЫТЫП ЧЫГЫП, КҮКРӘП ҮСЕП УТЫРУЫН КҮРҮ.

Фото: Александр Ефремов

ДИНАСТИЯ_ТМ

– ӘТИ КЕБЕК ГАДЕЛЛЕК ЯРАТАМ

ЛАНДЫШ ГАЙНУЛЛИНА,
Апас районы «Йолдыз» газетасы редакциясенең бүлек мөхәррире

Әсгать Җәләлиевның эшен бүген уртанчы кызы Ландыш Гайнуллина дәвам итә. «Йолдыз» газетасында бүлек мөхәррире ул. Әтисенең хыялын тормышка ашырган дисәм, дөрес булыр.

Ландыш Әсгать кызы журналистикага урау юллар белән килеп эләккән. Дөрес, кечкенәдән этисе кебек редакциядә эшлисе килгән. Әмма... журналистика факультетына керергә батырчылык итмәгән.

– Мәктәптә яхшы укыдым, зуррак сыйныфларда гына бер-ике «4»лем чыкты, – дип хатирәләрен яңартты Ландыш Гайнуллина. – Әти журналистика бүлегенә баруымны теләде. Ләкин мин куркып калдым. Ни өчен дигәндә, әтидәге сыйфатлар миндә юк дип уйладым. Гомумән, ул чакта журналистика минем өчен буй җитмәслек өлкә кебек тоелды.

Шулай да Ландыш Әсгать кызы гуманитар юнәлешне сайлый – КФУның филология факультетына керә. Читтән торып укый.

– Татар телен яхшы белә идем, иншаларны да гел «5» ле билгеләренә яздым, – дип дәвам итте әңгәмәдәшем. – Беренче курста чагында ук районның Биеш урта мәктәбендә эшли башладым. Балалар белән эшләү бик ошый иде. Әнә шулай сигез ел узып киткәнен сизми дә калдым. Аннан «Йолдыз» редакциясенә килдем.

– Ә курку хисе беттеме? – дим.

– Күрәсең. Мәктәптә эшләгәндә үз-үземә ышаныч артты. Көн дә балалар каршында дәрес аңлату минем өчен зур тәҗрибә булды. Аннары, яшем дә утызга якынлаша иде бит. Редакциягә әти үзе чакырды. «Эшләп кара, булдыра алмасаң китәрсең», – диде. Журналист тәҗрибәм әнә шулай әти кулы астында башланды. Эшкә килгән көнне үк мине командировкага җибәрделәр. Авыл мәдәният йортында уздырыла торган бер кичәгә бардым. Кайткач, шуны тиз генә язып бирдем. Редакциядәге тәҗрибәле журналистлар карап чыккач: «Язмаң әйбәт», – диделәр. Әмма дөресен әйтим, минем күзләр янмады. Темасы бик кызык түгел идеме шунда, нииндидер могҗиза булмады.

Шулай да Ландыш Әсгать кызы күңелен төшерми – алга таба редакция кушуы буенча төрле биремнәргә бара, яза... Ә берсендә Үтәмеш авылыннан бик тетрәнеп кайта.

– Гарип баласын үстергән ялгыз әти – Марат абый шаккатырды, – диде Ландыш Гайнуллина. – Хатыны бала тапкан вакытта вафат булган. Авыру баласын аякка бастырыр өчен әти кеше ни генә эшләмәгән. Шулвакыт: «Ә мин моның кадәр авырлыкларга түзәр идемме икән?» - дип уйладым. Язманы тапшыргач та, бик озак алар турында уйлап йөрдем...

Язмыш Ландышны да сыный – берничә елдан яшь ханымда онкология табалар. Сигез ел буе ул яман чир белән көрәшә. Унбер операция генә кичерә. Казан, Мәскәү хастаханәләре дә калмый. Бер аягының тездән аскы өлешен кисәләр. Протез белән яңадан йөрергә өйрәнә... Йөрергә генә түгел, йөгерергә дә!

– Яңадан эшкә чыкканыма ике генә ел әле, – дип күз яшьләрен сөртте Ландыш Әсгать кызы. – Мин бүген дөньяга бөтенләй икенче күз белән карыйм, сөенеп... Теге куркак Ландышның эзе дә калмады. Яза-яза каләмем дә чарланды. Бүген күбрәк оста куллы, сәләтле авыл кешеләре турында язарга яратам. Андый кешеләр янынннан көч алып кайтам.

Гаделлекне ярату – Ландыш Әсгать кызына әтисеннән күчкән төп сыйфат. Моның өчен кайвакыт кыенлыклар белән дә очрашырга туры килә. Шулай да ул гел үз кыйбласына тугры кала.

– Һәр кешегә үз әтисе үрнәк, идеал, – диде әңгәмәдәшем. – Минем өчен әти иксез-чиксез зур дәрья. Сокланам дию генә аздыр. Иң авыр чакларымда әти гел янәшәмдә булды.

...Ландыш Гайнуллина ире белән ике бала үстерә. Кызы Регина КФУда «5» билгеләренә генә укый, дүртенче курсны тәмамлый. Дүрт ел буена югары стипендия алган. (Инглиз теленнән республика олимпиадасында призер булганы өчен Регинаны шул исемлеккә керткәннәр.) Улы Тимур Апас урта мәктәбенең өченче сыйныфында, апасы кебек ул да «5» билгеләренә генә укый.

– ЯҢАДАН ЭШКӘ ЧЫККАНЫМА ИКЕ ГЕНӘ ЕЛ ӘЛЕ. МИН БҮГЕН ДӨНЬЯГА БӨТЕНЛӘЙ ИКЕНЧЕ КҮЗ БЕЛӘН КАРЫЙМ, СӨЕНЕП... КУРКАК ЛАНДЫШНЫҢ ЭЗЕ ДӘ КАЛМАДЫ. БҮГЕН КҮБРӘК КӨЧЛЕ РУХЛЫ, СӘЛӘТЛЕ АВЫЛ КЕШЕЛӘРЕ ТУРЫНДА ЯЗАМ. АНДЫЙ КЕШЕЛӘР ЯНЫННАН КӨЧ АЛЫП КАЙТАМ.

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВНЫҢ НЕФТЬ ҺӘМ БАЛЫ

Ксения Сёмина

Якты киләчәкне – сәясәтчеләр, үткән көннәр данын – тарихчылар, бүгенге көнне исә журналистлар сурәтли, диләр. Әмма оста журналист боларның өчесен дә берьюлы яктырта.



Марсель Зарипов (1931–2017), журналист, язучы, тәрҗемәче. 1962–1966 елларда – «Советская Татария» газетасының республиканың нефть районнарындагы үз хәбәрчесе, 1966–1992 елларда – «Советская Россия» газетасының Татарстан буенча үз хәбәрчесе. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына нигез салучылардан берсе. «Татар иле»-«Татарские края» газетасын оештыручылардан берсе. Меңгә якын мәкалә, очерк, репортаж бастырган. 20 дән артык китап авторы. Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» (1966), Гариф Ахуновның «Артышлы тау буенда» (1973), Нурихан Фәттахның «Ител суы ака торур» (1978) һәм татар язучыларының тагын берничә танылган әсәрен рус теленә тәрҗемә иткән. Зарипов – «Звездный час Нижнекамска» документаль романы өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган Татарстан журналистлары арасында бердәнбер кеше.

1980 нче еллар азагында СССР Министрлар Советы тун-мех эшләнмәләр җитештерүне арттыру чаралары турында карар кабул итә. Аларны гамәлгә кертү өчен җаваплылардан берсе итеп партия Үзәк Комитетының авыллар буенча секретаре Виктор Никоновны да билгелиләр. «Советская Россия» газетасының Татарстандагы үз хәбәрчесе Марсель Зарипов моңа сөенүен яшерми:

– Менә ниһаять гаделлек тантана итә, Виктор Петрович. Элек мин сезнең «йомышчыгыз» идем, хәзер исә үзегез бераз мәшәкатьләнегез – газетадагы күрсәтмәләремнең үтәлүен тәэмин итегез! – ди.

Совет чорында «йомышчы» дип газета редакцияләре күрсәтмәләре белән төрле җирләргә җибәрелә торган репортерларны атаганнар. «Советская Татария» газетасы хәбәрчесе буларак, Зарипов «өстәгеләр» (шул исәптән нәкъ менә Никоновның да) кушуы буенча колхозлардан кайтып кермәгән диярлек. Бүген берәр колхозның казанышлары турында, иртәгә исә аның ук хаталары хакында мәкалә таләп ителәргә мөмкин. Ике төрле стандартларны җене сөймәгән Марсель Зарипов дөресен язарга яраткан, шуның өчен еш кына җирле түрәләрдән шелтәләр эләккәләгән. Соңрак «Советская Россия» газетасының үз хәбәрчесе буларак Зарипов сарыкчылык тармагы һәм тун тегү эшенең торышы турында кискен тәнкыйть материаллары сериясен язган. 1980 нче еллар азагында исә мондый мәкаләләр игътибарсыз калдырылмаган. Шул рәвешле, ике дистә елдан соң Марсель Зарипов үзенең үчен кайтарган.

ЗОЛУШКАНЫ ЯКЛАП

Марсель Зарипов үзенең һөнәри эшчәнлегендә дә, әдәби иҗатында да һәрнәрсәнең асылына төшенергә, проблемалы хәлдән чыгу юлларын табарга омтылган. Кайвакыт әлеге хакыйкать эзләве аркасында абруен, эшен, статусын югалту куркынычы да туган. Әмма ул барыбер үз сүзен бирмәгән.

Журналист нефть сәнәгате, автопром, төзелеш, авыл хуҗалыгы – ягъни ул чакта республика тормышына зур йогынты ясаган тармаклар белән ныклап кызыксынган. Әлеге цивилизация казанышларының татарстанлылар тормышын ничек яхшырта алуын өйрәнгән. Бервакыт, 1980 нче елларда, «Советская Россия» хәбәрчесе Марсель Зариповның күзенә карабодай турында китап чалына. Зарипов әлеге культура хакында элегрәк тә язгалаган,

Фото: sarman-rt.ru

аны кара «золушка» дип атаган – журналист фикеренчә, авыл хуҗалыгы тармагы җитәкчеләре карабодайның кадерен белеп, аңлап бетерми. Китапны язган галим, карабодайның уңдырышлылыгы бодайдан күпкә азрак, дип раслый. Әмма әлеге китап кулына эләгер алдыннан гына Зарипов бер колхозда була. Анда исә ике культурадан да бер үк күләмдә уңыш алуга ирешкәннәр. Һәм журналист «Советская Россия» газетасында галимнең сүзләрен кире кага торган мәкаләсен бастыра. Китапны әзерләгән институт Үзәк Комитетка зарлана. Зариповны партиядән чыгарырга җыеналар. Соңрак үзе искә алганча, газетаның баш мөхәррире Михаил Ненашев үз позициясендә нык тора. Редактор фикеренчә, әгәр мәкаләгә карата бернинди дә реакция юк икән, димәк, ул файдасыз, бушка язылган. Һөҗүм итәләр икән, хаклыгыңны дәлилләр белән расларга кирәк. Редакция түгәрәк өстәл оештыра. Галимнәрне һәм «җир» тармагы вәкилләрен, шул исәптән әлеге дә баягы колхоз рәисен дә чакыралар. Бәхәс кыза. Эксперименталь нәтиҗәләр карабодайның уңдырышлылыгы кимрәк икәнен күрсәтә. Рәис исә үз колхозында ике культураның да бер үк төрле уңыш бирүен, әмма карабодай өчен дүрт тапкыр артыграк түләнгәнгә, аны үстерү файдалырак булуын аңлата. Нәтиҗәдә журналистны аклыйлар.

«САЙРА ӘЙДӘ, ТИК ОЯТ БУЛМАСЫН!»

Марсель Зариповның журналистлык феноменын аңлатып булмый. Күпләр бары тик җитештерү мәшәкатьләрен генә күргән җирдә ул ничек итеп поэзия, мажаралы роман яки триллер иҗат итәрлек материал табарга өйрәнгән? Табышмак. Героебыз Татарстанның Сарман районы Янурыс авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килгән. Мөгаен, нәкъ менә әти-әниләре уллары Изаил белән Марсельдә сүзгә мәхәббәт тәрбияләгәндер. Әмма иң беренче чиратта – хезмәт сөючәнлек. 1946 елда җиде сыйныф тәмамлаган 14 яшьлек Марсель Петровка спирт заводына эшкә урнаша. Аннары Хәрби-диңгез флотында хезмәт итә, бораулау кадрлары мәктәбендә укып, электромонтер һөнәрен үзләштерә һәм республиканың нефть промыселларында эшли. Нефтьчеләр тормышы аңа бик мажаралы тоела, башкаларга да шуның турында сөйлисе килә. Шулай итеп Марсель җирле матбугатка языштыргалый башлый. Аннары «Советская Татария» газетасының үз хәбәрчесе була.

Үзенең тәүге журналистлык сәфәрен Марсель Зарипов гомерлеккә хәтеренә сеңдерә. Аны, Әлмәтнең «Знамя труда» газетасы хәбәрчесен, бирeдәге иң алдынгы бораулау бригадаларыннан берсенең җитәкчесе Михаил Белоглазовтан интервью алырга җибәрәләр.

– Безнең баш очында, болытлар янында ук, кронблоклы «фонарь», аның астында верховойның «бишеге» тора, биредә аннан да югарырак кеше юк. Ул безгә төкерә ала, ә без аңа төкерә алмыйбыз. Икенче тапкыр килгәндә штиблет түгел, резин итек киеп кил, – дип киңәшләрен бирә репортерга Белоглазов. – Язарга өйрәтергә маташмыйм, син барыбер үзеңчә сайраячаксың. Әмма шуны исеңдә тот: язганнарың өчен геройларыңа башкалар каршында оят булмасын. Син сайрап аласың да, оянга кереп качасың. Мин исә монда калам, синең язганнарың өчен мине битәрләячәкләр. Аңладыңмы?

Үзе язган сүзләр өчен кешегә оят булмасын дигән хакыйкатькә Марсель Зарипов гомере буе тугры кала. Аның гаҗәеп очеркларының күпчелегендә язма героеның сыйфатлары берсе артыннан берсе әкренләп ачыла бара. Шул рәвешле автор аны һәр укучыга аңлаешлы һәм якын итә.

УМАРТА КОРТЫ – АКЫЛЛЫ БӨҖӘК

«Марсель Зарипов – принципиаль гамәлләр кешесе. Мөгаен, бу аны башкалардан аерып тора торган бәхетле сыйфаттыр. Башында фикер кайный, бәлки әллә ни мөһим дә түгелдер, әмма кирәкле, фикер әкренләп тулылана бара... Безгә эш-гамәл кешеләре ошый, алар, энергия һәм дәртләре белән уртаклашып, үзенә күрә бер донор булып тора...» – язучы Рөстәм Кутуй дустын әнә шундый итеп сурәтләгән.

Пенсиягә чыккач та, Зарипов тик утырмый. Хәбәрче булып эшләү дәверендә ул әллә никадәр һөнәрнең теориясен бик шәпләп өйрәнә. Умартачылык исә аның икенче зур мавыгуына әйләнә. Улы Илдарны да бу шөгыльгә тарта. Дуслары һәм танышлары Зариповлардан бервакытта да тәмле балсыз китми. Бал белән бергә, аның турында китаплар да языла тора – барысы бергә дистәгә тула яза. Марсель Харис улының иң мөһим хезмәте – «Народная медовая энциклопедия» бөтен илдә чын популярлык казана. Аның һәр юлыннан умарта кортларына мәхәббәт һәм хөрмәт бөркелеп тора. Героебыз такмазаларыннан берсенә күз салыйк:

– Без урманга күч алып кайтырга хатыным белән икәү йөрибез. Агач башындагы тубалга эләккән бал кортларын күргәч, башта дога кылабыз, Аллаһ Тәгаләгә рәхмәтебезне җиткерәбез, аннары сөенечтән үбешәбез. Тагын бер күч – тагын бер дога һәм үбешү. Өченче тапкыр үбешү исә тагын да рәхәтрәк. Узган җәйдә уналты тапкыр үбештек. Умарта кортлары – бик акыллы бөҗәкләр, алар безнең сөенгәнне яхшы белә, шуңа без куйган тубалга килеп керә дә.

Марсель Зарипов өчен иң шатлыклы мәл исә оныгы Даниярга бүләк ителгән умартадан кәрәз рамын алып караган көн. Кәрәз буш булмый, оныгы кортларга ашар, үрчер өчен өчен бераз бал калдырган, димәк, аның эше дәвам итәчәк.

ВЛАДИМИР УСТИНОВСКИЙ ДӘРЕСЛӘРЕ

Әскәр Сабиров

Төзелеп бетмәгән күп катлы йорт янәшәсендәге кирпеч таулары арасындагы тәмәке төтененә чумган вагон. Кулдан ясалган җылыткыч янында кибеп утырган итекләрдән «хуш» ис аңкый. Аның каравы сөйләшү дә шундый – җитәкчеләрдән курыкмыйча, рәхәтләнеп, «саллы» сүзләр катнаш: кәгазь бите кызарырлык...



Төзелеш мәйданчыгындагы түгәрәк өстәлдән соң истәлеккә фото... Владимир Устиновский (баскан) әлеге фотоны коллегасына түбәндәгеләрне язып бүләк иткән: «Без инде беркайчан да мондый булмаячакбыз. Чөнки вакыт бик тиз үтә. Бигрәк тә безнең редакциядә...»

Владимир Устиновский (1948–2018). Журналист. 1974–2018 елларда «Республика Татарстан» («Советская Татария») газетасында хәбәрче, җаваплы секретарь урынбасары, бүлек мөдире, баш мөхәррир урынбасары, беренче урынбасары. Бер редакциядә эшләү стажы – 44 ел. Республиканың «Бәллүр каләм» конкурсында Гран-при иясе.

Икенче көнне исә инде төзелеш генераллары кызарачак. План таләп итеп, нормаль эшләү өчен шартлар тудырмаулары турында чын дөреслекне «Советская Татария» газетасыннан укыгач оялтучылар күп булачак әле аларны. Мәкалә партия өлкә комитеты бюросында тикшерелгәч, ташчы һәм буяучы-бизәүчеләрне ниһаять махсус эш киеме белән тәэмин итә башлаячаклар.

Владимир Устиновскийның турыдан-туры төзелештә түгәрәк өстәл үткәрү идеясе файдалы булып чыга, гәрчә җитди кабинетларда аның дошманнарын арттырса да. Тик аны бу куркытмый. Газета – карьера ясар урын түгел. Мөһимрәк нәрсәләр бар: журналист дөньяны бераз гына булса да яхшырта ала икән, чын ир-атның бурычы нәкъ менә шул түгелмени?! Совет тормышында башбаштаклык һәм тәртипсезлек җитәрлек, ә педант һәм искиткеч пөхтә Устиновский моңа күзен йомучылардан түгел: сүзе белән көрәшә. Һәм буш сүз сөйләүчеләрне җене сөйми.

ЯЛГАНГА КАРШЫ ДАРУ

Хакимияткә Юрий Андропов килә. Яңа генераль секретарь илдә тәртип урнаштыра башлый. Райком һәм парткомнарда барысы да бертавыштан хуплана кебек, әмма чынбарлыкта бернәрсә дә үзгәрми диярлек. Буш сүзләр, ялтыравык шигарьләр ачуны гына чыгара. Ул чакта газетада сәнәгать бүлеге мөдире булган Устиновский дилбегәне үз кулына ала. Беркөнне ул коллегасы белән Казанның Вахитов исемендәге химия комбинатына бара. Дирекция һәм парткомда журналистлар предприятиенең хезмәт дисциплинасы өчен көрәштәге уңышлары турында нотыкны сабыр гына тыңлап бетерә. Тик тырышып-тырышып сөйләгән ораторлар белми шул: журналистлар нәкъ иртәнге сәгать җидедә комбинат капкасы янында сменага гадәттәгечә соңга калып килүчеләрнең фамилияләрен бер сәгать буе теркәп барганнар.

«По обе стороны проходной» репортажы бомба шартлауга тиң була. Аның нәтиҗәләре буенча кабат кискен карарлар кабул ителә, авторның дошманнары тагын да арта.

Холкы шактый авыр булса да, редакциядә Устиновскийның кадерен беләләр. Коллегасы материалының аннан-моннан эшләнгәнен күрә икән – дәшми калмый: планеркада рәхәтләнеп кирәген бирә. Сан буенча кизү торганда, авторның вазыйфасына яки регалияләренә карамыйча, материалдагы мәгънәсезлекләрне һәм стилистик пассажларны һичшиксез төзәтә. Әмма ул өстәнөстән генә эшләргә яратучылар белән генә шундый кырыс. Үзе кебек үк чын күңелдән тырышып эшләүче коллегаларына Устиновский һәрвакыт хәерхаһ. Фикердәш. Остаз. Дус.

«БЕГЕМОТ» БАРЫНЫҢ КАРА ТАМГАСЫ

Журналистны «Советская Татария» газетасының җаваплы сәркатибе итеп куярга җыеналар. Һәм кинәт КПСС өлкә комитетының идеология бүлегенә аноним конверт килеп төшә. Эчендә – Польшадагы бер популяр журналда басылган фото: Владимир Устиновский Казанда күптән түгел ачылган «Бегемот» сыра бары фонында басып тора. Совет журналисты, сыра бары (!) янында, җитмәсә, чит ил матбугатында! Нәтиҗәсе тиз арада күренә: җаваплы сәркатип вазыйфасы хакында онытырга туры килә.

Язмыш шуклыгы: Устиновский кирәкмәгән вакытта кирәкмәгән урынга нәкъ менә обком кушуы буенча барган була. Идеологик яктан ышанычлы кеше буларак, аңа Польшадан килгән журналистка Казанны күрсәтергә кушалар. Кунак «Бегемот» барына керергә теләк белдерә, ә керер алдыннан үзен озата йөртүчене истәлеккә фотога төшерә...

Аноним исә Устиновскийның тәнкыйтенә үпкәләгән коллегасы булып чыга. Фамилиясен белсә дә, журналист аңа үч тотмый. Хәер, юк-барга сарыф итәрлек вакыты да юк аның: көн саен чыга торган газетада эшләү татлы сөргенгә тиң бит ул.

КӨНДӘЛЕК ГАЗЕТА РИТМЫНДА

«Татлы сөрген» бирелә телбизәк урынына гына кулланылмый. Материалны бик тиз арада язып бирү зарурлыгы көндәлек газетада гадәти хәл. Көннәрдән бер көнне бүлек мөдире Устиновский «гади генә» бирем ала: Казан вертолет заводының көнкүреш товарлары җитештерү тәҗрибәсе турында язарга кирәк. «Гадилеге» шунда: предприятиегә барып, тәҗрибәне өйрәнер, белгечләр фикерен ачыклар өчен нибары бер тәүлек бирелә – иртән «Советская Татария» газетасы А2 форматындагы бер полосалык материал белән КПСС өлкә комитеты бюросы утырышында «катнашырга» тиеш.

Ярты көн ябык предприятиегә керер өчен рөхсәт алуга китә, көннең икенче яртысында бүлек тулы составында – мөдир һәм хезмәткәр икәүләшеп – вертолет заводында кешеләр белән очраша, анализлый. Аннары – мәкалә языла. Төн уртасыннан соң әзер полоса оттискы өлкә комитетының пропаганда бүлеге мөдире Юрий Воронин имзасын алу өчен аның өенә китерелә. Функционер, кәнәфиендә җәелеп утырган килеш, текстны карап чыга һәм, бернинди үзгәреш тә кертмичә, имзасын куя.

Көн саен чыга торган совет газетасының чиктән тыш көчле темпына бары тик бер генә очракта түзәргә була: командада үзара идеаль аңлашу хөкем сөрергә тиеш. Устиновский җитәкләгән бүлектә мөнәсәбәтләр эшлекле генә түгел, гаиләдәгедәй җылы. Кичен, цейтнот үзенең иң югары ноктасына килеп җиткәндә, шеф балалар бакчасындагы кызларын алырга хезмәткәрен җибәрә – алайса киләсе санга кирәкле текст язылып бетмәячәк! Әмма бу мәҗбүр итү түгел, бәлки иптәшләрчә булышу. Хезмәткәргә хатынын бала тудыру йортыннан алып кайтырга кирәкме? Редакторның «Волга» машинасын алып, Устиновский коллегасы белән бәби алырга бара. Бәләкәчне күтәреп карарга да рөхсәт иткәч, ихластан сөенеп елмая. Символик егерме граммны тотып куйгач, егерме минуттан соң инде бәхетле эти кеше белән кабат газета бүлмәсенә кайта: эш бетмәгән – вакыт көтми.

ҮЗЕ ҺӘМ ТЕГЕ ЕГЕТ ӨЧЕН

Шунысы үкенечле: әлеге аяусыз еллардагы «Советская Татария» газетасында Владимир Устиновский имзалаган журналист материаллары әллә ни күп түгел. СССР чорында партия матбугатының кануны катгый: газета гавам рупоры булырга тиеш. Газетада катгый нормалар билгеләнгән: һәр хезмәткәргә аена кимендә биш авторлык мәкаләсен тапшырырга кирәк.

Эшчеләр һәм җитәкчеләр «рупор» булырга ашкынып тормый, материалларны оештыру таләп ителә. Һәм – авторлар үз инициативасы белән язганны да кеше теленә тәрҗемә итәргә туры килә. Әлеге материалларны Устиновский көнне төнгә ялгап төзәтә. Һәм могҗиза туа: кайчагында бөтенләй фикерсез сүз боткасы кинәт мантыйк һәм мәгънә белән тула. Мәкалә киң яңгыраш таба, авторлары күренеклегә әйләнә, эшче-хәбәрчеләр үз язмалары өчен кайвакыт әле хәтта дәүләт бүләгенә дә лаек була. Чит кеше иҗатына бөтен көчен биреп алҗыган Устиновский исә бер кап «Космос» тәмәкесен тартып бетерә...

Устиновскийның редакторлык даһилыгын һәм оештыру сәләтен күрми калу мөмкин түгел.

Принципиальлеген бераз киметсә, ихтимал, ул инде күптән баш мөхәррир булыр иде. Нәкъ менә аның журналистлык каләменнән соң фикерләре ачыкланган рәхмәтле авторлар арасында беренче затлар да, сәясәтчеләр дә җитәрлек үзе.

Хәер, империя таркалган чорда Устиновскийның редакция иерархиясендәге урыны болай да бик җаваплы – баш мөхәррирнең беренче урынбасары. Газета исемен алыштыра – «Республика Татарстан» булып чыга башлый. Хәзер инде партияне данлау һәм сәхифәләрне алдынгы эшчеләрнең чыгышлары белән тутыру таләп ителми. Басмалар саны хәзер күпкә артыграк, ә каләм әһелләренең һөнәри дәрәҗәсе – кызганыч ки, күпкә кимрәк...

Республиканың әйдәп баручы газетасы традицияләренең баш саклаучысы булган Устиновский хәзер, асылда, даими эшли торган осталык дәресләренең җитәкчесе дә: яшьләрне өйрәтә, газетчыларның яңа буыны материалларын җиренә җиткерә, кайвакытта исә, аларның хаталарыннан оялып, үзе яңадан яза. Яшьләр мәтрның артык бәйләнчеклегенә зарлана. Аннары исә үзләренең журналист конкурсларында җиңүләре өчен «бәллүр каләмнәрне» бер дә зарланмый гына ала... Укытучы, остаз исә һәрвакыттагыча күләгәдә кала...

Әмма журналистлар мохитендә кемнең кем булуын яхшы беләләр. 2015 елның маенда Владимир Устиновскийны көтмәгәндә «Пирамида»га чакырып, «Бәллүр каләм» бәйгесенең Гран-приен – автомобиль бүләк итәчәкләр. Мөгаен, жюри карары бернинди дә бәхәс тудырмаган сирәк очраклардан берсе була бу.

КӘНИФ ХӘКИМОВ: «АКЫЛЛЫ ҺӘМ ФАЙДАЛЫ БУЛЫРГА ТЫРЫШТЫМ»

Алсу Троицкая

Аның кәефе һәрвакыт яхшы, күңеле күтәренке кебек, тик бу шулай тоела гына. Балачагы Колымада сөргендә үткән, бик иртә өлкәнәергә туры килгән, Япония белән сугышта катнашкан. Сынауларга бирешмәү, гомерне намус белән үтү хакында парадоксаль һәм үткен фикерләрен, уйлануларын героебызның кулъязмаларыннан һәм газетада басылган материалларыннан алынган өзекләрдә тәкъдим итәбез.



Болан белән фотога төшмәкче була, ул тартыла башлый. Нәтиҗәдә төньяк гүзәленең уң мөгезе Хәкимов кулында кала. Чукотка.

Кәниф Хәкимов (1927–2020). Фронтовик, журналист, язучы, фотограф. Аның тәүге «Письма из бывшего стойбища» дигән очерклар китабы Магадан нәшриятында 1959 елда басылып чыккан. Аннан тыш тагын җиде китабы бар, шулардан бишесе Татарстан нефтьчеләренә багышланган. Шамил Бикчурин исемендәге премия лауреаты. Техникада – ике, медицинада бер патент авторы.

АЧЛЫК ҺӘМ УТЕРЕП АШЫЙСЫ КИЛУ ТЕЛӘГЕ

«30 нчы еллар башы... Унбиш яшьлек кенә булса да олы гәүдәле Кави абыем Чернушка станция шәһәренә акча эшләргә китте. Аның ярдәме, әлбәттә, сизелерлек булды, тик шулай да беребез артыннан беребезне кырган ач үлемнән коткарырлык түгел иде. Кайвакыт туфрак та ашарга туры килде. Янәсе, авызга он капкандай күз алдына китерәбез дә, аның селәгәй белән кушылып йомшаруын көтәбез. Барлыкка килгән «камыр» исә теш һәм уртларга ябышып ката. Моннан соң инде дистәләрчә ел үтсә дә, мин әлегә кадәр тешләр арасында шыгырдаган шушы балчыкның күгәрек тәмен тоям...

Дүрт елдан артыкка сузылган шундый ачлыктан соң безнең гаиләдә өч бала исән калды. Энекәшем Фрат төнлә җан тәслим кылды. Мин йокыдан уянып, кочагымда аның салкын тәнен тоеп ачыргаланып кычкырып җибәрдем. Бу турында шунда гына белделәр... Калганнарыбыздан кайсыбызны тагын Фрат язмышы көткәндер, билгесез, әмма без тәкъдиргә буйсындык – якын кешеләрне җирләүгә инде күнектек һәм моны гадәти хәлгә саный башладык. Әтиләре 58 нче маддә буенча хөкем ителгән ятимнәр күргән җәфаларны үлчәрлек үлчәү бармы икән ул?! Мин авырлыкларны өлкәннәр кебек кабул итәргә өйрәндем. Алтынчы яшем киткәч, елаша-талаша яланаяк мәктәпкә кача идем. Сыйныф бүлмәсендә салкын, мин аякларымны бөкләп парта артында утырам. Ахыр чиктә укытучы мине дәресләрдән куный башлады, иректә тыңлаучы булып тик утырдым шунда. Дәфтәрләр юк иде, шуңа газета кырыйларына яздык. Һәркайсыбызга бирелгән ярты карандашка, берәрсе «ялгыш» үзенең киндер сумкасына салып куйган очракта таныр өчен, махсус тамга салабыз. Тора-бара әнием дә минем мәктәпкә йөрүемә күнде. Шул рәвешле, сигезенче яшь белән барганда, мин инде өченче сыйныф укучысы булдым».

«ӘТИЕМ, СИН ХАКЛЫ БУЛГАНСЫҢ»

Балачагы Колымада, репрессияләнгәннәр арасында уза. Алар белән аралашу Кәнифнең дөньяга карашын формалаштыра, бу исә рәсми пропагандадан нык аерылып тора.

«Система кешеләрдә буйсынучанлык, күндәмлек тәрбияли, безнең баш миебездәге җыерчыкларны турайта, безне әти-әниебезгә караганда партиягә тугрырак итәргә омтыла. «Ленин»

Фото Хәкимовларның гаилә архивыннан

һәм «партия» сүзләре һәрвакыт «әни» сүзеннән алдарак языла... Ватан сугышы башланганда, әтием инде икенче ел иректә яши, тик аңа барыбер Колымадан күчеп китәргә ярамый иде әле.

– Бу сугыш озак һәм авыр булачак, – диде әти.

Пропаганда тарафыннан, теләсә кайсы дошманны тиз арада җиңәбез, дигән фикер сеңдерелгән кешеләргә мондыйны ишетү сәер иде. Әмма әтием хаклы булып чыкты».

УЛЫ – ӘТИСЕ ЯКЛЫ!

Кәниф Хәкимов армиядә алты ел ярым хезмәт итә, совет-япон сугышында катнашырга да өлгерә.

Рота командиры үзе янына чакырып партиягә керергә тәкъдим иткәч, Кәниф үз колагына үзе ышанмый – репрессияләнгән «халык дошманы» улы бит ул! Командир исә тыныч кына:

– Моның бер катнашы да юк. Улы атасының гамәлләре өчен җавап бирергә тиеш түгел, – ди.

Шулай да. Сәяси бүлектә партиягә керү өчен рекомендация биргәндә Кәнифтән әтисеннән ваз кичүен сорыйлар.

– Әтием мине берниндн начар нәрсәгә дә өйрәтмәде, һәм мин аннан баш тартмаячакмын, – дип каршы төшә Кәниф.

Ирексезләмиләр. Хәкимовны партиягә бертавыштан кабул итәләр, сәяси бүлек башлыгы (бәласеннән башаяк!) гына тавыш бирми.

МӨХӘРРИР ТӘКЪДИМЕ

1950 елда «Совколыма» газетасына мөхәррир итеп Рязаньнан майор (Колыма ярымхәрби шәһәр була) Иван Михайлов дигән кеше билгеләнә.

Хәкимов аны хәрбиләрчә сәламли.

– Мондый рәсмилекнең кирәге юк. Утырыгыз, – ди редактор һәм армиядән соңгы планнары турында тәфсилләп сораштыра.

Кәниф үзенең кабат «Дальстройпроект» институтына барырга ниятләвен әйтә.

– Ә безнең газетада эшләргә теләмисезме? Мин газетада сез төшергән фотоларны күрдем. Әле рәсем дә, гравюралар да ясыйсыз, дип әйттеләр. Күпме хезмәт итәсегез калды әле?

– Бер ел, бәлки, артыграктыр.

– Махсус хәбәрче буласыгыз киләме?

– Әлбәттә!

ТУНДРА БЕЛӘН ТАНЫШУ

Бервакыт СССР халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе күчмә боланчылык бригадалары турында фоторепортаж ясауны үтенеп редакциягә мөрәҗәгать итә.

– Сез нәрсә киеп барырга җыенасыз? – дип сорый рәис Козлов.

– Менә шушы киемнәрдән инде, – дип, өстендәге кышкы пальто, киез итек, күн перчаткаларын күрсәтә журналист.

– Мондый кыяфәттә сезнең өчен җавап бирәсем килми, тундрага җибәрмәячәкмен.

Тегү остаханәсендә җирле халык кия торган мех киемнәр табыла: кухлянка – мех тун, торбаза – мех итек, яланаякка киелә торган озын оеклар (чижи), болан тиресеннән тегелгән кумус бияләйләр, башка – малахай бүрек һәм, ниһаять, кардан саклану өчен мех тун өстеннән киелә торган башлыклы күлмәк – камлейка. Шуларны киеп, Хәкимов кабат Козлов янына килә. Рәис ризалыгын бирә: киемнәр уңайлы, кысан түгел, иң мөһиме – җил үткәрми.

Язу карасы салкыннан катып килгәнгә, Хәкимов үзенең хәбәрләрен карандаш белән яза, аннары телеграф бланкына күчерә һәм эфирдан редакциягә җибәрә. «Икенче кичкә без Экерультын бригадасы торлагына килеп җиттек. Апрельнең 15е, минем туган көнем, боланнар бозаулый торган чак иде... Минем күз алдымда дөньяга килгән бозау, аягына басмакчы булып, мәтәлчек ата, өстеннән җылы пар күтәрелә. 20 минуттан соң, үзен әнисе ялап бетергәч, әле аяклары калтыранса да, инде аңа ияреп китеп тә барды. Бик кызык, мавыктыргыч күренеш. Гомерлеккә хәтеремә уелып калды.

Тундраны комсызланып төшердем, ашыкмасам, нәрсәнедер күрми калырмын кебек тоелды...»

МОҢСУ КҮЗЛЕ ШАЯН КЕШЕ

1960 елның 5 декабрендә Чукотканы калдырып киткәннән соң, гомеренең азагына кадәр Хәкимов Лениногорскида яши. Биредә Татарстанның көньяк-көнчыгышы буенча цензор, фоторепортер, телевидениедә һәм газеталарда журналист булып эшли. Һәрвакыт баш киемсез. Моңсу күзле шаян кеше. Үз гомерендә бик күпне күргән, игелек, акыл, зирәклек тулы моңсу серле күзләр...

«Үземнең журналистлык хезмәте елларымда мин, ихтимал, шактый күп нәрсәгә өлгермәгәнмендер дә. Әмма хәлемнән килгәнчә эшләдем. Журналист сыйфатында акыллы һәм файдалы булырга тырыштым».

МОГҖИЗАЛАР КЫРЫ?

«Миллионлаган ватандашлары күз алдында «Могҗизалар кыры» телетапшыруында өлкән яшьтәге татар кондәшләре белән рус телен яхшырак белүдә ярышты һәм җиңүче булып чыкты...

...Тормыш нәрсә ул? Мәгълүм ки, уен... Кемдер очколарны бик тиз туплый, кемдер исә курка, шикләнә. Шул ук вакытта бездә трагедия белән комедия шулкадәр тыгыз бәйләнгән ки, хәтта гадәттән тыш хәл кертелгән көннәрдә дә без телевизион уеннар белән мавыгабыз. Ил түгел, могҗизалар кыры бу, һәм бу илдә яшәү – могҗизалар кырын үтү генә түгел шул...»

«Каниф-бабай на «Поле чудес»: о жизни и взглядах победителя веселой телеигры» мәкаләсеннән. 1993 ел, 21 октябрь, «Известия» газетасы. Аңлагансыздыр инде, «Могҗизалар кырында» Кәниф Хәкимов катнаша. Материал авторы Борис Бронштейн язуынча, «МММ акцияләре яки акча сайларга тиеш булса да, икесен дә алуга ирешә ул». Әлеге мәкаләне таба алсагыз, һичшиксез укыгыз – анда бүген дә актуаль булган гаҗәеп фикерләр шактый.

12+
«КИТАП» ТЫҢЛА!
КИТАП МИЛЛИ радио
КАЗАН 98,6 FM
АО «ТАТМЕДИА» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2 ГРН 1071690057834
Реклама

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР /

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Беренче татар газетасы **НИЧЕК** чыккан

Халыкның рухи тормышында үзгәрешләрне **НИЧЕК** аңларга

КАЙСЫ авылга исеме кире кайтарылган

Гагарин **КАЯ** төшеп утырган

Орбитага чыгып, космонавт Антон Шкаплеровка **НИЧЕК** сорау бирергә

«ТӨНЬЯКТА ЯШЬНӘГӘН БЕР НУР»

Илдус Заһидуллин

Россия башкаласы Санкт-Петербургта татарлардан беренче төпләнүчеләр отставкага чыккан хәрбиләр була. Акрынлап Рязань губернасы Касыйм өязе мөселманнары, Түбән Новгород төбәге татарлары күченә башлый. Санкт-Петербург–Мәскәү, Мәскәү–Түбән Новгород тимер юлы эшли башлагач, күченүчеләр саны күзгә күренеп арта. 1822 елда башкалада беренче мөселман мәхәлләсе теркәлә, 1870 елда икенче мөстәкыйль мәхәллә оештырыла. Мулла итеп Гатаулла хәзрәт Баязитов чакырыла.

БАШКАЛАНЫҢ 2 НЧЕ МӘХӘЛЛӘ МУЛЛАСЫ

Касыйм өязе Тәмгәнәй (Төмәнсу) авылында 1847 елда туган, этисендә башлангыч белем алганнан соң, укуын Касыйм каласыннан ерак түгел урнашкан Чутай авылындагы Байморат хәзрәт мәдрәсәсендә, аннары берничә ел Казан губернасы Кышкар мәдрәсәсендә дәвам иткән Гатаулла Баязитов, Чутай мәдрәсәсендә мөгаллимлек эшен калдырып, Санкт-Петербургка күченә.

Гатаулла мулла яңа туган балага исем кушу, никах уку, мәет җирләүне оештыру, метрика

Фотолар автордан алынды

Гатаулла Баязитов (уңнан бишенче) Санкт-Петербург Җәмигъ мәчетенә нигез ташы салу тантанасында. Үзәктә – Бохара әмире. 1910 елның 3 феврале.

кенәгәсенә дин кардәшләренең гражданлык актларын теркәп бару кебек эшләр белән шөгыльләнә башлый. Гомумән, зур шәһәр шартларында 2 нче мәхәллә Касыйм өязе татарларының дини оешмасы буларак яши. Мәхкамәи шәргыя Гатауллага 1880 елда «ахун» дини дәрәҗәсен бирә.

Касыйм өязе татарлары нигездә кафе-рестораннарда хезмәт итә, бүлмә-фатирларны да эш урыннарына якын булган шәһәр үзәгендә арендалый. Муллага торакны Кышкы сарайга якын гына, Мойка урамындагы 22 нче йортта (28 нче фатир) сайлыйлар. Санкт-Петербургта Гатаулланың гаиләсе ишәйгән, бер-бер артлы балалар туа: Биби-Мәхфузә (1873), Мөхәммәтсафа (1877), Биби-Заһидә (1880) һәм Биби-Фатыйма (1884). Ике кызы, үсеп җиткәч, Сембер фабрикантлары бертуган Акчуриннарга кияүгә чыга, шул рәвешле Баязитов татар дөньясының мәшһүр байлары белән туганлаша.

Җәмәгать намазлары җомга көнне мулла фатирының бер бүлмәсендә оештырыла торган була. 1902 елны «Православный собеседник» болай дип яза: «Санкт-Петербургта яшәүче мөселманнар, мәчетләре булмау сәбәпле, бәйрәм (җомга) көннәрендә үзләренең руханиларында, аларның шәхси фатирларында җыела. Матди мөмкинлекләр чикле булганга, бу фатирлар кысан, барлык теләүчеләрне сыйдыра алмый. Шуңа күрә кайберәүләр алгы бүлмәләрдә генә түгел, ишек алдында намаз укый».

Гатаулла хәзрәт гаиләсе яшәгән фатир янәшәсендә башлангыч мәхәллә мәктәбе эшләп килгән. Хәзрәт биредә үзе даими укытмыйча, мөгаллим яллап белем бирүне оештырган. Улы Мөхәммәтсафа, 1901 елда Мәхкамәи шәргыядә имтиханны уңышлы тапшырып, «имам-хатыйб» дини дәрәҗәсенә ия булгач, шушы мәктәптә укыта башлый.

Башта Гатаулла сәдака акчасына көн күрсә, акрынлап мулланың өстәмә табыш чыганаклары пәйда була. Мөселманнар гаепләнүче яки шаһит буларак мәхкәмәгә (судка) чакырылганда, хәзрәт исламча ант иттерүче буларак катнаша. Русча белүен исәпкә алып, хакимият аны берничә хәрби уку йортында белем алучы мөселманнарга ислам дине дәресләрен укытуга җәлеп итә. 1882 елда Гатаулла Баязитов Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментына төрки телләр тәрҗемәчесе булып эшли башлый.

1883 елда Баязитов җәдит мәктәпләре өчен «Дин вә мәгыйшәт (тормыш)» исемле уку дәреслеге әзерләп бастыра. Шулай ук татар теле һәм морфологиясе буенча, литва татарлары үтенече белән рус телендә «Иман һәм гыйбадәт» исемле китаплар яза.

Шулай итеп, Гатаулла Баязитов рухани, мөгаллим, хөкүмәт чиновнигы һәм хакимият ышанычын казанган башкала мөселманнары җәмгыяте лидеры булып таныла. Дөрес, 1905–1907 елгы инкыйлабтан соң бу образга үзгәрешләр керә. Яшьләр һәм демократия тарафдарлары аның белән идеологик каршылыкка килә. Ә хакимият консерваторлар белән хезмәттәшлек итүне өстен күрә. Бу өлкәдә Гатаулла ахун зур уңыш казана.

ИСЛАМ ДИНЕН ЯКЛАП ЯЗГАН ХЕЗМӘТЛӘРЕ

Башкалада Баязитов күренекле галим Василий Бартольд, философ Владимир Соловьев һәм башка рус галим-зыялылары белән аралаша. 1880 нче еллар азагында Төркиядән Санкт-Петербургка мөселман дөньясын яңарышка һәм берләшергә өндәүче Җәмалетдин Әфгани килгәч, бу күренекле шәхес белән әңгәмәләр кора.

XIX гасырның соңгы чирегендә Гатаулла хәзрәт башкала вакытлы матбугатында мөселманнарны кимсеткән язмаларга каршы, исламны һәм дин кардәшләрен яклап, мөселман мәгърифәте, мәдәнияте турында рус укучысын «агарту» максатында мәкаләләр бастырган бик сирәк шәхесләрдән берсе була.

Күренекле француз галиме Эрнест Ренанның исламның фәнгә дошмани дин булганын раслауга корылган докладына тискәре бәя биреп, Гатаулла хәзрәт 1883 елда зур булмаган «Возражение на речь Эрнеста Ренана. Ислам и наука» исемле китап бастыра. Доклад текстындагы исламга каршы булган җөмләләрне аерып алып, һәрберсенә тәнкыйть сүзләре яза, аларның ялган булуын дәлилли.

Гатаулла Баязитов – 1905 елның 2 сентябрендә дөнья күргән беренче татар газетасы «Нур»ның нәшире, мөхәррире һәм журналисты; башкала Җәмигъ мәчетен төзүне оештыручыларның берсе, рус телендә ислам дине турында китаплар һәм мәкаләләр язып, илдә түземле дини сәясәт булдыруга зур өлеш керткән мәгърифәтче; Санкт-Петербургта 2 нче мәхәллә имамы һәм Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында төрки телләр тәрҗемәчесе. Татар дөньясында Гатаулла ахун җәдитчеләрнең уң, консерватив лагере тарафдары; татар рухание һәм зыялысы сыйфатында империя хакимияте белән уңышлы хезмәттәшлек итеп, хөкүмәт каршында казанган ышанычны милләт мәнфәгатьләрен хәл итү өчен уңышлы файдалана белгән күренекле шәхес.

Санкт-Петербургның җәмигъ мәчете.

Соңрак Гатаулла Баязитовның шушы ук юнәлештә язган тагын берничә китабы дөнья күрә. 1887 елда «Отношение Ислама к науке и иноверцам» исемле рус телендәге китабында ислам тәгълиматының нигезен башка диннәргә түземле караш тәшкил итә дигән фикер уздырыла. Автор исламның чит халыкларга карата миһербанлы һәм яңалыкка карата ачык булуын ассызыклый.

1898 елда дөнья күргән «Ислам и прогресс» исемле китабында автор, Коръән аятьләрен һәм Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләрен мисалга китереп, мөселманнар өчен белемнең искиткеч мөһим булганлыгын аңлата. Өммиядләр һәм Габбасилар хәлифәтләре заманында фәнни белемнәр антик чор язма мирасы, шулай ук Иранда һәм Һиндстанда иҗат ителгән хезмәтләрне гарәп теленә тәрҗемә итү аша туплануын әйтә, төгәл, гуманитар һәм табигать фәннәре өлкәсендә мөселманнар язган иң мәшһүр хезмәтләрне һәм әсәрләрне атый.

Фанатизмның мөселманнарга хас күренеш булмавын раслау өчен, шулай ук күпсанлы Коръән аятьләрен мисалга китереп, Мөхәммәд пәйгамбәрнең яһүдиләргә һәм христианнарга карата уңай мөгамәләсен күрсәткән, аның исламны көчләп түгел, ә вәгазьләп таратуын раслаган күренешләргә туктала. «Изге сугыш» – Мөхәммәд пәйгамбәр өчен дини кагыйдә булмыйча, вакытлы дини һәм сәяси чара булган дип аңлата. Шәригать буенча христианнарга карата кертелгән чикләүләрне, ислам динендә коллар һәм хатын-кызларның җәмгыятьтә тоткан урыннарын, гаиләдәге хокукларын ачыклауга да беркадәр урын бирә. Ислам тәгълиматының дәүләт һәм хакимият турындагы фикерләрен китерә.

Россия мәгълүмат кырында Баязитов шушы китаплары, үзләре компилятив характерда булсалар да, рус телле укучыга ислам тәгълиматының асыл нигезләрен аңлату һәм ике конфессия вәкилләре арасында түземле мөнәсәбәт булдыру өчен хезмәт итә.

ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕН ТӨЗҮ ЮЛЫНДА

Башкалада мәчет булмау руханиларга шәһәрнең төрле районнарында яшәгән мәхәллә кешеләре белән элемтәләр урнаштырырга комачаулый. Шулай да, авыру, карт һәм ярдәмгә мохтаҗ дин кардәшләре турында кайгырту гаиләләр арасындагы элемтәләргә таянып башкарылган. Санкт-Петербургта җәмигъ мәчете булмау бигрәк тә Корбан гаете һәм Ураза гаете бәйрәмнәре вакытында зур кыенлыклар тудыра. Татарлар ул вакытта төрле оешмаларның зур заллы биналарын арендага алып, намазны шунда җыелып укый.

1881 елда алар башкалада Җәмигъ мәчете төзү Комитеты уставын раслауны сорап хакимияткә гариза тапшыралар. 1884 елда ахуннар М. Юнысов, Г. Баязитов, сәүдәгәрләр Р. Халитов, Г. Таганаев, эшмәкәрләр Н. Бикбулатов һәм Ф. Карамышевка Санкт-Петербургта әлеге игелекле эшне башлау өчен иганә җыярга рөхсәт бирелә. Бу төркемнең җитәкчесе итеп Гатаулла ахун билгеләнә, һәм аның исеме ил күләмендә яңгырый башлый.

Сүлпән генә барган иганә кампаниясен төрле эшләр белән башкалага килгән татар, азәрбайҗан байларының, Бохара һәм Хива ханнарының зур суммалар бирүе җанландырып җибәрә. 1899 елга барлыгы 37 мең сум акча җыела, актив иҗтимагый эшчәнлек алып барып, Гатаулла Баязитов шушы сумманың яртысын берүзе туплый. 1905 елга җыелган иганә 53300 сумга җитә. Гатаулла ахун дин кардәшләре арасында гадел ил агасы буларак ихтирам казана. Мәчет нигезенә беренче таш салу тантанасында мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов ахун Гатаулла Баязитовка рәхмәтен белдерә.

Империя башкаласы үзәгендә 1913 елда ачылган Җәмигъ мәчете бинасы җәмәгатьчелек тарафыннан Россия дәүләтендә исламның һәм мөселманнарның хөрмәткә лаеклы булуын, илдә дин иреге барлыгын раслый торган архитектура һәйкәле дип бәяләнә.

БЕРЕНЧЕ ТАТАР ГАЗЕТАСЫ МӨХӘРРИРЕ

Санкт-Петербургта инде исеме аталган сәүдәгәр улы Х.Бикбулатов һәм унтер-офицер А.Котлыяров 1872 елны хакимияткә «Дәфтәр мөҗдәвәр» («Хәбәрләр дәфтәре») исемле газета чыгарырга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә. Барып чыкмагач, Котлыяровның улы 1874 елда «Мөҗдәвәр» («Хәбәр») исемле газета чыгарырга рөхсәт сорап карый. Тик бер проект та тормышка ашмый.

Башкалада милли матбугат булдыру турында уйланып, Гатаулла Баязитов 1891 елда русча-татарча «Хәфтә» («Атна») газетасы чыгарырга рөхсәт сорый. Тискәре җавап алгач, 1893 елда «Чишмә» исемле газета турында сүз кузгатып карый. 1895 елда «Нур» исемле русча-татарча газета нәшер итү мәсьәләсен күтәрә. Фәкать дүртенче талпыныште гына 1905 елның 7 июнендә аның «Нур» газетасын чыгару хакындагы үтенече канәгатьләндерелә. Һичшиксез, Гатаулла Баязитовның хакимият оешмаларында эшләве, башкала түрәләре белән танышлыгы аңа нык ярдәм итә.

«Нур»ның беренче саны 1905 елның 2 сентябрендә дөнья күрә. Шушы датадан башлап, төрле шәһәрләрдә татар телендә газета-журналлар нәшер ителә. «Нур» газетасы татар зыялылары тарафыннан шатланып каршы алына. 20 яшьлек Габдулла Тукай, җәмәгатьчелек фикерен белдереп, болай дип яза:

«*Төньяктан, яшьнәп яшен, бер нур атылды,*
Яктысыннан халыкның күзе чагылды.
«Нур» дип аталуы да бит бик урынлы,
Шулай ук исеменә җисеме дә килә туры.
Милләткә никадәр байлык, бәхет, якты (...)
Киләчәк, чөнки бу көз төньяктан кояш чыкты...
Бөек, зур шәһәр – аның басылу урны,
Патшаның башкаласында чыккан ул нур.
Һәр юлы төрле мәгънәгә ия «Нур»ның,
Чөнки ул хикмәтле сүз-мәгънәдән гыйбарәт.
Аның һәр хәбәре ялган түгел, туры,
Дөрес; халык күңелен үзенә тартып тора.
Бар якка нур чәчә, шуның белән мәшһүр ул,
Сүзләре дә – энҗе кебек тезелгән.
Алдырып, укучылар саны гел үссен,
Милләт авыруына шифа булып төшсен!».

Шул рәвешле, миллион кеше яшәгән Россия империясе башкаласында 5-6 мең татар исеменнән газета чыга башлый. «Нур»ны нәшер итү Гатаулла хәзрәттән зур чыгымнар сорый. Башка милләтләрдән ким булмасын дип, мөхәррир газетаны яхшы кәгазьгә бастыра, милләт өчен кирәкле проектка, кайбер мәгълүматларга караганда, 8 мең сум акчасын сарыф итә: бу планда аның хезмәте иганәче буларак та бәяләргә лаек.

Газетаның тәүге саннары Гатаулла хәзрәт компаньон булып торган Ильяс мирза Бораганский басмаханәсе ширкәтендә, 1908 елдан аталы-уллы Баязитовларның «Нур» исемле шәхси типографиясендә басыла. Газета башта атнага бер, күпмедер вакыттан соң айга берничә санда дөнья күреп килә.

1906 елны Дәүләт Думасына сайлаулар вакытында газета конституцион демократлар партиясе өчен тавыш бирергә чакыра, либераллар лагерена карый. 1907 елдан «Нур» газетасы сәяси планда консерватив, хөкүмәт яклы фикерләрне яктырта. Бу вакытка Санкт-Петербург зыялылары арасында ике лагерь яшәп килә, аларны прогрессистлар (алгарыш яклылар) һәм консерваторлар (тотрыклылык яклылар) дип атап булыр иде. Консерваторлар лагерен Гатаулла Баязитов җитәкли.

«Нур»да татар милләтенең киләчәге, милли мәгариф, әдәбият, дин, фәлсәфә, имамнарның һәм зыялыларның бурычлары кебек темалар үзәктә була. Материалга кытлык булганга, Гатаулла хәзрәт һәр санда шушы темаларга төрле исемнәр белән берничә мәкалә бастырып тора. Аерым алганда, «Нур» беренче булып әдәби татар теле проблемасына кагыла. Көн кадагына суккан милли иҗтимагый-мәдәни мәсьәләләр буенча газета битләрендә шулай ук Дәүләт Думасы депутатлары Гайса Еникиев, Садри Максуди, Сәхибзадә Максудов, Шәрәфетдин Мәхмүтов, Котлымөхәммәд Тәфкилев, язучылар Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый, Фатыйх Кәрими, Риза Фәхретдин һ.б. чыгыш ясый. Мөхәррирлек эшендә улы Мөхәммәтсафа әтисенең аркадашы була, газетада мәкаләләр белән дә катнаша. Рус һәм татар газеталарыннан яңалык-хәбәрләр белән беррәттән, анда хикәяләр, фәнни-популяр һәм бәхәсле мәкаләләр дөнья күрә.

Гатаулла ахун 67 яшендә бакыйлыкка күчә, 1911 елның 23 апрелендә аны соңгы юлга озатырга 2 меңләп мөселман җыела. Әтисенең вафатыннан соң рухани, «Нур»ның нашире һәм мөхәррире буларак эшен улы Мөхәммәтсафа Баязитов, булачак Оренбург мөфтие (1915-1917) дәвам итә.

1911 елда «Нур»да дөнья күргән соңгы язмасында Гатаулла Баязитов кавемдәшләрен үзара тарткалашуларны туктатырга, алгарыш һәм милли мәдәниятне үстерү мәсьәләсенә бергәләп игътибарны тупларга чакыра, татар милләтенең киләчәккә башка юлы юк, дип белдерә. Мәкаләнең соңгы сүзләре игътибарны аеруча җәлеп итә: «Без, Русия татарлары өчен, үзара улан ихтиляфларны (дау-ызгышларны) ташлап, тәрәккый вә тәмәдден (мәдәният) эшләре илә мәшгуль улырга кирәк. Безем кеби артта калмыш, тәрбиясез вә мәгарифсез татар милләте өчен шуннан башка юл тотарга ярамый». Т

ЭЛГӘРЕГЕ БОЛГАРЛАРНЫҢ РУХИ ДӨНЬЯСЫ

Гамирҗан Дәүләтшин,
тарих фәннәре докторы, профессор

VIII–X гасырларда Идел болгарларына ислам дине үтеп керә башлый, әмма халыкның шактый күп өлеше әле мәҗүсилектән, тәңречелектән аерылып җитмәгән була. 922 елда ислам динен рәсмиләштергәннән соң аларның рухи дөньясында барлыкка килгән кискен үзгәрешләрне тулырак аңлар өчен, тарихыбызның элгәрерәк чорына мөрәҗәгать итү зарур.

Яшәешнең кайсы гына тармагын алып карама – икътисадмы ул, дәүләт төзелеше, идарә системасымы яисә рухи мәдәниятме – болгарлар үзләренең борынгы төрки бабалары һуннардан, Төрки каганлыгы халыкларыннан, Каспий, Кара диңгез һәм Азов буйларында яшәгән хәзәр-болгарлардан мирас итеп бик күп нәрсә алган. Академик В.асилий Бартольд, «хәзәрләрнең бөтен Көнчыгыш Европа тигезлегендәге мәдәни казанышлары ук булмаса да, Идел бассейнындагы мираслары болгарларга күчте», дип язган.

КҮК АЛЛАСЫ ХИМАЯСЕНДӘ

Идел буена ислам диненең бик иртә үтеп керүенә һәм таралышына карамастан, болгарларда күпсанлы политеизм (күпаллалык) калдыклары сакланып кала әле. Әкренләп тәңречелек дини, идеологик, фәлсәфи система буларак сүнә бара, исеме генә саклана диярлек. Тәңре исеме Кол Галинең монгол яуларына кадәр язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасында һәм болгарларның XIV гасырга караган каберташ язмаларында да очрый.

Мәсәлән, элгәреге болгарлар Тәңре яшен һәм күк күкрәү белән дә идарә итә дип уйлаган. Ибне Фадлан болай яза: «Болгар илендәге кадәр күп яшен яшьнәүне һичбер җирдә күрмәдем. Әгәр йортны яшен сукса, алар аның янына бармый, эчендә булган кешене һәм мал-мөлкәтне коткармый, барысын да, вакыт черетеп бетергәнче, шул килеш калдыралар һәм: «Бу йорт – ачуга дучар булганнарныкы», – диләр». Болгарларда яшен суккан җир изге урынга әверелгән һәм бу урынга корбан китергәннәр.

Болгарлар шулай ук кояшны, утны изгеләштергән. Көнкүреш әйберләрендә очрый торган болгар бизәкләре кояш, ут символына бик бай. Кояшны хәтерләткән мондый рәсемнәр – со-

Автор фотосы; islam.ru

ляр бизәкләр Алтын Урда чорына караган кабер ташларында да очрый. Борынгылыкта Күк, Ут, Яшен Алласы – Тәңренең символлары булган, шуңа күрә аларның кабер ташларында очравы бер дә гаҗәп түгел. Монда борынгы мәҗүсилек белән яңа монотеистик дин сыйфатлары бер-беренә керешә. Кояшны изгеләштерү һәм аның символлары – кояш бизәкләре башлыча игенчелек белән шөгыльләнүче халыкларга хас.

ТЕРЕКЛЕК ЧЫГАНАГЫ

Болгарлар суны барлык нәрсәнең – җир һәм андагы тормышның, күк җисемнәренең беренче чыганагы итеп караган. Болгар космогоник мифында Җир шары дөнья океаны төбеннән тылсымлы кош алып чыккан балчыктан барлыкка килә.

Су шулай ук гөнаһлардан арыну, явыз рухлардан саклану чарасын да үтәгән. Болгар-татар зиратлары гадәттә елга яки элекке елгадан калган чокырлар аръягына урнашкан. Шулай итмәсәң, үлгән кешеләрнең җаны кире авылга кайтыр дип курыкканнар. Шүрәледән дә елганың икенче ягына чыгып котылып була дип ышанганнар (ике арада ышанычлы су киртәсе барлыкка килә). Болгарлар суның ияләре бар дип уйлаган. Испаниядән килгән гарәп сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Гарнати (XII гасыр) Болгар илендә зур балык колагыннан чыккан балык койрыклы Сусылу турында яза. Бу – дөнья мифологиясе белән бәйләнешле әһәмиятле хәбәр. Борынгы грек философы фикеренчә, иң беренче җан ияләре суда барлыкка килә. Вакытлар узгач, балыкка охшаш бу җан ияләре коры җиргә чыга. Аларның эчендә беренче кешеләр ярала.

Бабаларыбыз төрле чишмәләрне изгеләштергән, суларын дәва буларак файдаланган. Болгар, Биләр, Иске Казандагы болгар истәлекләре белән бәйләнешле чишмәләр хәзер дә татарларда изге санала, аларның дәвалау көченә ышаналар. Биләр янындагы Хуҗалар тавы астындагы Изгеләр чишмәсе һәм тау өстендәге изгеләр күмелгән җир элек-электән үзенә күрә «хаҗ» кылу урынына әверелгән, бирегә килеп, корбан чалып китәләр.

АТ – ҖИР БЕЛӘН КҮК АРАДАШЧЫСЫ

Болгарларда үлгән кешеләрне, бабаларны, изгеләрне хөрмәтләү нигезендә теге дөньяга, шул дөньяга күчкән җаннарның яшәвенә һәм аларның тереләр тормышында зур роль уйнавына ышану яткан. Үлгән ата-бабалар культы болгарларда аеруча X гасырга кадәр, ягъни алар әле мәҗүси булган чорларда, күзгә ташлана. Олы Тархан, Танкеевка, Кайбел, Тәтеш кебек мәҗүси болгар каберлекләре бу культ турында шактый тулы материал бирә. Ибне Фадлан хәбәрләренә караганда, җирләү йоласында бөтен авыл, ыру, кабилә катнашкан. Ирекле ирләр үлгән кешенең ишеге төбендә кычкырып елаган, ә ирексезләр үрелгән камчы белән үз-үзләрен



1 Алтын чигә алкасы.

2 Болгар тәлинкәсе эчендә кояш бизәге.

3 Биләрдә «Изге чишмә» комплексы.

кыйнаган. Үлгән кешенең капкасы өстенә кайгы әләме эленгән.

Кеше үлгәннән соң да тормышын теге дөньяда дәвам итә дип ышанганга күрә, аны киендергәннәр, каберенә азык-төлек куйганнар, һәм үлгән кешене теге дөньяда да кирәк булырлык эш, сугыш кораллары белән бергә күмгәннәр. Моннан тыш, үлгән кеше каберенә теге дөньяга барып җиткәнче туклану өчен ит, чүлмәк һәм агач савытларга салып ботка яки эчемлек куйганнар.

Ат белән бергә күмү йоласы шул заманның болгар, угыр культурасына хас. Күрәсең, бу атлар, болгарлар уйлавынча, теге дөньяга барып җитү өчен кирәк булган. Борынгы төркиләрдә ат – Күк белән Җир арадашчысы, кеше җаннарын күккә ашыручы. Күк белән Җир арадашчысы – борынгы төрки язмаларда Тәңренең әмерен «җиренә җиткерүче» Юл тәңресе – алмачуар яки кара атта чаба дип хикәяләнә.

ҖИР АСТЫ ДӨНЬЯСЫ

Борынгы төркиләр, шул исәптән болгарлар да, үзләреннән элегрәк яшәгән бабаларын, аларның рухларын ничек күз алдына китергән соң? Бу җәһәттән, Биләрдән, аннан ерак түгел урнаш-

4

5

6



4
«Гарипләр»нең җиз сыннары. Татарстан Милли музее.

5
«Барска утырган җайдак» кыяфәтле җиз йозак. XII гасыр.

6
«Барска утырган җайдак» (Спас районы Маклашевка авылыннан).

кан Балынгуз шәһәрлегеннән, Чистай тирәсеннән табылган кеше сыннары бик кызыклы. Алар бронзадан коелган, очлы баш киемнәреннән генә, еш кына бер куллы, бер аяклы. Кайберләренең бер күзе юк. Димәк, үлгәч җир асты дөньясы затларына әверелгән бабалар да ямьсез, шыксыз кыяфәт ала, аларга күзләр дә кирәк булмый дип санаганнар. Алтай шаманнары бабалар рухларын «күзсез, сукырлар» дип тасвирлаган һәм еш кына аларны «күрмәсләр» дип йөрткән. Татар телендә «көн күреш, көн күрү» дигән сүз бар. Ул телебездә тормыш, яшәеш сүзләренең синонимнары буларак кулланыла. «Кояш» сүзенең борынгы тамыры – «көн». Аннан «көнеш», ә аннары хәзерге «кояш» сүзе ясалган. Ягъни «көн» сүзе кояшны да белдергән. Димәк, борынгы заманнардан ук килгән бик мәгънәле бу сүз – көнкүреш (кояшны күрү) яшәү, тормышны, ә кояшны күрмәү – үлемне белдергән. Борынгы төрки язмаларда шулай дип язылган да: «Кояш һәм Айны сизми башладым» (ягъни, «үлдем» мәгънәсендә). Барс белән бәйләнешле мондый сыннар болгарларның борынгыдан килгән генеалогик карашларын да чагылдыра.

«ТОРМЫШ АГАЧЫ»

«Тормыш агачы» сурәте болгарларның сынлы сәнгатендә киң таралган. Ул – тормыш чыганагы да, уңдырыш билгесе дә, дөнья төзелешенең шәкеле дә, туганчы һәм үлгәннән соң кеше җанының сыену урыны да.

Шушы караш нигезендә болгарларда борынгылыкта «агачка күмү» йоласы да булган. Әле бу гадәтнең калдыгы Ибне Фадлан килгән вакытта да очрый. Болгарлар акылы, гайрәте белән аерылып торучыны, Тәңрегә хезмәт итәргә иң яраклы кеше дип, агачка асып куя торган булган. Мондый күмү йоласы үзенең тамырлары белән борынгы төрки чорларга барып тоташа. Бу йола һуннарда да билгеле булган. Үлгән кеше өч ел агачта асылынып торгач, сөяген җыеп яндырганнар. Ибне Фадлан язмаларына караганда, төньяк алыбының гәүдәсе дә шактый гомер агачта асылынып торган. Ибне Фадлан сүзләре белән әйтсәк: «Яңгыр һәм кояшның эшенә дучар булганчы..., вакыт узу белән, җил очыртып бетергәнче».

«Агачка күмү», күрәсең, биек агачлар аркылы Тәңрегә корбан бирү йоласыдыр. Ул кеше җанының шул агач аркылы Күккә, Тәңрегә күтәрелүенә, биек һәм зур агачлар буйлап үлгән җаннарның Тәңрегә ирешүенә ышану белән бәйле.

Изгеләр культы үлеләрне, бабаларны хөрмәтләү белән бик тыгыз бәйләнгән. Ыруг, кабилә аксакаллары, алыплар, дин әһелләре, Тәңрегә корбан ителгән кешеләр изгегә әйләнгән.

Хәрби демократия чорында һәм соңрак та болгарлар тормышында алып (көчле, алыптай гәүдәле) сугышчыларның роле зур булган. Болгар илендә бер алыпның гайре табигый, изге булуын Ибне Фадлан да яза: ул үзенең карашы белән дә ир баланы үтерә, корсаклы хатынның баласын төшерә алган. Әбу Хәмид Әл-Гарнати алыпны болгарларның хөрмәт итүе, олылавы, ә каршыга очраса, безгә Алланың каһәре төшкән дип, аннан качулары турында яза.

Борынгы кеше тирә-юньне үзенә иң якын һәм аңлаешлы булган ыруг-кабилә мөнәсәбәтләре аша үзләштергән һәм аны табигатькә, шул исәптән хайваннар дөньясына да күчергән. Болгар чорында инде чын мәгънәсендәге тотемизмның калдыклары гына сакланып калган. Болгар иленә ислам дине шактый иртә һәм тирән үтеп керсә дә, сынлы сәнгатьтә кош-корт, хайван, җанвар сурәтләре еш очрый. Борынгы төрки чордан килгән генеалогик карашлар белән бәйле барс, Тәңре һәм аның гамәлләре белән бәйле тәкә культы калдыклары болгарларда да яшәвен дәвам итә. XII гасырдан инде барс образы дәүләт гербларына хас кайбер үзенчәлекләр ала башлый.





БАЙГЫШ – АУЧЫЛАР ЯКЛАУЧЫСЫ

Болгарларда кош-корт, киек-җәнлекләр аерым һөнәр һәм шөгыль химаячесе буларак та урын алган. Биләрдә табылган бер мөһердә байгыш – мәче башлы ябалак аучылар яклаучысы буларак гәүдәләнгән. Рәсем баш бармакны җәя кереше бәрүеннән саклау өчен ясалган сөяк кигезмәгә төшерелгән. Ике сурәтнең дә эчтәлеге охшаш – геральдик рәвештә үрелгән ике ерткыч кош үзләренең патшасын – байгышны баш очында күтәреп тора, ә байгыш койрыгыннан астарак ниндидер хайванның киселгән башы ята. Бу рәсемнәр бик гыйбрәтле. Алар байгышны (мәче башлы ябалакны), башка күп кенә халыклар мифологиясе, фольклорындагы кебек үк, кошлар патшасы, аучылар яклаучысы итеп сурәтли. Фольклор сюжетларына караганда, бу мәртәбәгә ул үзенең акыллылыгы белән ирешә. Шулай итеп, ябалак кошлар патшасы, зирәклелек символына әверелә. Байгыш һәм мәче башлы ябалакның төрки исемнәренә этимологик анализ да шушы фикергә китерә. Борынгы төркичә iabaqulaq рәвешендә йөреп, бөек төзүче, барлыкка китерүче дигәнне аңлаткан. Икенче исеме дә – байгуш (байгыш) бай кош, ягъни дәрәҗәле кош дигәнне белдерә.

ШИГЪРИЯТ ӨЧЕН МУЛ ҖИРЛЕК

Болгар мифологиясенә Көнчыгыш, аеруча Урта Азия, Иран халыклары мифларының тәэсире дә булган. Бу йогынты борынгы төрки чорда ук башланган. Болгар сынлы сәнгатендә, халык авыз иҗатында һәм матур әдәбиятында мифологиянең роле аеруча зур. Мифлардагы фантазия, хыял чын мәгънәсендәге сәнгатьчә фикерләү түгел әле, чөнки борынгы кеше өчен миф – белем дә, фәлсәфә дә, табигатькә, тормышка тәэсир итә ала торган реаль чара да. Әмма бу, Габдулла Тукай сүзләре белән әйткәндә, «шагыйранә ялган» гына әле. Чын мәгънәсендәге поэтика – сүз сәнгатенең башы фольклорда булачак. Шул ук вакытта болгар мифологиясе киләчәк дөньяны сәнгатьчә танып белү өчен, поэтика өчен мул һәм кыйммәтле җирлек әзерләгән. Болгар-татар әдәбиятының формалашуында борынгы ышанулар һәм мифларның роле гаять зур.

МӘҖҮСИЛЕКТӘН АЕРЫЛУ

Болгарлар борынгы төрки һәм Азов буе болгар чорыннан мирас итеп, беркадәр шартлылык белән әйткәндә, борынгы төрки монотеизмын – тәңречелекне, ягъни тәңрегә һәм аның белән бәйләнешле рәвештә күккә, кояшка, яшенгә һәм дә бүре, эт, ат, тәкә кебек хайваннарны изгеләштерүне кабул иткән. Ибне Фадлан хәбәренә караганда, болгарларның ут күршеләре угызлар да «бер тәңре»гә табынган. Әмма бу чиста тәңречелек булмый инде. Ул угыр, Идел буе фин мифлары, ышанулары, болгарлар килгәндә үк бу якларда таралыш алган төрки-угыр мифологик карашлары белән керешә.

Әмма бу чорда элек система рәвешендә булган тәңречелек әкренләп юкка чыга. Андагы культлар аерым хорафатларга, ышануларга, ияләр өлкәсенә күчкән. Тәңре ислам Алласының бер исеме, синонимы рәвешендә генә кулланыла башлаган. Элгәреге болгарларда мәҗүси йолаларны башкара торган урын-гыйбадәтләр хакында ышанычлы язма һәм матди чыганакларның булмавы да моны раслый.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин. VIII–IX гасырларда яшәгән болгарларның «мәҗүси» карашлары, ышанулары борынгы төркиләргә хас тулы тәңречелек системасының җимерелеп юкка чыга барган калдыкларыннан гына гыйбарәт. Бер үк вакытта элгәреге болгарларның рухи дөньясы шактый катлаулы, хәтта каршылыклы була. Болгар кабиләләре белән бер үк вакытта диярлек бу якларга күчеп килгән һәм яңа, Идел буе болгар этносы оешуга сизелерлек өлеш керткән угыр-төрки кабиләләрнең дә әкренләп ислам диненә күчү чорына хас үзенчәлекле рухи дөнья тудырудагы өлешләрен инкяр итеп булмый.

7 «Тормыш, дөнья агачы» төшерелгән калыплар.

8 Керамик сихри җайланма – «Яңгыр чакыра торган» су сипкеч. Биләрдән.

9 Җәя кереше бәрүеннән саклый торган сөяк җайланма. Биләр шәһәрлеге.

ИСКЕ-ЯҢА «ОСКАР», ЯКИ КИЛӘЧӘК ХАКЫНА ҮТКӘНГӘ КАЙТУ

Америка киноакадемиясенең 94 нче «Оскар» тапшыру тантанасы 27 мартта узды һәм быел купшылыгы, эксцентрик гамәлләре, кино сөючеләрне таң калдыра торган карарларыннан бигрәк, йомыклыгы һәм гадәтилеге белән истә калды. Дөньядагы бөтен игътибар башка темага юнәлгәндә, аның тантанасы бераз гына, хәтта бераз гына да түгел, икенче планга күчте билгеле. Ул хәтта бер айга соңгарак та күчерелде.

Кино тәнкыйтьчеләре бу тантананы әле әзерлек этабында ук «ретровайб» дип тамгалаган иде. Күрәсең, оештыручылар, чыннан да, Оскарның элеккеге данлы чорларына – кино сәнгатенең «алтын гасыры»на кайтырга омтылган. Бу аның эстетикасында да, кайбер алымнарында да күзгә чалынды. Карарларында да, билгеле.

Тантананы уздыру урыны булып элеккечә Голливудтагы «Долби» театры калды-калуын, әмма соңгы еллардагы кебек яңа элементлар белән мавыкмады быелгы тамаша. Алып баручылар да – үз урынында иде, катнашучылар арасында да – һәммәсе үз урынында диярлек. Яңалык бөтенләй юк та түгел, хәер – быелгы елдан башлап, Америка киноакадемиклары номинациягә дәгъва кылучы фильмнарны физик йөкләтүчеләрдә карарга мәҗбүр ителми. Моңа кадәр оештыручылар 8000 DVD дискны аларга, конвертларга салып, планетаның төрле почмакларына хат итеп җибәрә иде. Әлеге ретро-гадәтнең, билгеле, үз тылсымы һәм бизәге бар, ләкин, хәзерге шартларда, күрәсең, хәтта Америка киноакадемиясенә дә путаларын кысып бәйләргә туры киләдер. Оптимизация шартларында «Оскар» комитеты фильмнарны карау мөмкинлеген махсус платформада тудырды – анда нибары сайлап алучы экспертлар өчен генә персональ керү мөмкинлеге булдырып, әлбәттә.

САННАР, ҖӘНҖАЛЛАР ҺӘМ ХӘЙЛӘЛӘР

Ретрога йөз тоту быелгы номинант-фильмнар исемлегендә дә, аларны сайлау критерийларында да, кыйммәтләр шкаласында да чагылыш тапкан иде. Әле лонг, шорт исемлекләр барлыкка килү чорында ук. Моның тулыканлы анализын кино тәнкыйтьчеләре, билгеле, үз вакыты белән ясар һәм безгә, гадәти кино сөючеләргә, тәфсилләп аңлатыр, ә әлегә, әйдә, бераз гына

Рәсемнәр: kinopoisk.ru/сайтыннан алынды

саннарга һәм быелгы тантананың үзенчәлекләренә күз йөгертик.

Сер түгел, соңгы елларда «Оскар» тантанасының рейтинглары сизелерлек дәрәҗәдә төште, һәм, аңлашыла ки, бу киноакадемия вәкилләрен борчымый калмый. Шуңа да оештыручылар елдан-ел «Оскар»ның дәрәҗәсен күтәрергә, аның шанлы чакларын кайтарырга омтыла. Бүгенге цифра һәм виртуаль мөмкинлекләр заманында күз текәп тантана вакытын көтеп алучылар һәм онлайн-режимда аңа кушылучылар сирәгәю – аптырарлык күренеш түгел югыйсә, бик тә мантыйкка сыя. Гомумән, көтеп алып, нәкъ барышында туры трансляциягә кушылулар да хәзерге виртуаль дөнья кулланучылары өчен элеккеге көчен җуйды шикелле.

Тасманы кирегә таба әйләндерсәк, бу пандемия вакытында инде тәмам ялыктырган туры эфирларга да барып тоташа булса кирәк, мәгълүматны табуның кыенлыгы калмауга, һәрчак кайсы да булса платформада булуына да. Билгеле, кайдадыр түләүле, ә кайдадыр гомумән бушлай. Кайчандыр төн уртасы җитеп, тантана башланганын телевизор экраннарына күз текәп көткән безнең буын белән чагыштырсак, исәпләүләр күрсәткәнчә, яшь буынга «Оскар» гомумән кызыклы түгел. Шуңа да монда ретро булмаган алымнарга мөрәҗәгать итәләр – «Оскар» хәзер социаль челтәрләрне кулланучылардан тавыш та җыя, ул рейтингларны халыкка да тәкъдим итә.

94 нче церемония үзенең төп җәнҗалы белән дә хәтердә калыр булса кирәк, һәрхәлдә, «Долби» театрына җыелган кино сәнгате әһелләре өчен бу гадәттән тыш хәлгә әверелде. Үзенең тышкы ыспайлыгы һәм әдәплелек кодексы (бу урында «снобизм» төшенчәсен куллану кулайрак тоела) белән дан тоткан «Оскар» чын мәгънәсендә көч куллану мәйданына әверелде. Атаклы комик Крис Рок авызыннан хәләл җефете тарафына бик үк әдәпле (хәтта әхлаклы да) булмаган шаярту яңгыраганнан соң, номинантларның берсе булган актер Уилл Смит, сәхнәгә күтәрелеп, аны яңаклап ташлады.

Трансляцияне онлайн караучылар интернетта моның махсус әзерләнгән «фишка»мы түгелме икәнен ачыкларга тырышкан арада, шоуны күрсәтүчеләр туры эфирда тавышны кысарга мәҗбүр булды (бу да – символик фал). Уилл Смит кызганмый сиптергән сүгенү сүзләре, аңлашыла ки, ыспай-мәдәни аудиториянең нечкә хисләренә тими калмагандыр. Ничек кенә булмасын, бу инде – тарих. Һәм аны бүгенге тынгысыз шартларда узган тантананың бик тә күрсәткеч факторы, хәтта ки «визит карточкасы» дип атап йөртәләр.

Әмма бер үк вакытта шуны да онытмаска кирәк: Америка киноакадемиясе нәрсәнедер гафу итсә дә, кайбер нәрсәләр өчен үтә дә аяусыз җәзалый. Бу очракта Уилл Смит һәм аның фильмы продюсерлары белән командасына мөнәсәбәт шул көннәрдә үк формалашты – аны гаепләүчеләр, билгеле, күпчелек булып чыкты. Нишлисең, һәркемнең үз «Оскар»ы әле бит алда көтәдер...

КЕМ БЕЗНЕ ТЫҢЛАРГА ҺӘМ ИШЕТЕРГӘ ӨЙРӘТЕР?

Төп интригаларның берсе, әлбәттә, «Иң яхшы фильм» номинациясе булды. Бу номинациягә гадәттә классик рәвештә биш картина чыгарыла торган булса, быел алар унау үк иде. Бу да – «ретровайб», чөнки соңгы елларда кабул ителгән әлеге карар – элеккеге заманнарга әйләнеп кайту, киноакадемиянең нигезләмәсенә апгрейд ясау. Моны оештыручылар үзләре «төрле характердагы кар-

«ИҢ ЯХШЫ ФИЛЬМ» НОМИНАЦИЯСЕНДӘ ТӨП НОМИНАНТ-ФИЛЬМНАР:

«CODA: Ребенок глухих родителей» (режиссер – Шан Хейдер)
«Белфаст» (режиссер – Кеннет Брана)
«Не смотрите наверх» (режиссер – Адам Маккей)
«Сядь за руль моей машины» (режиссер – Рюсукэ Хамагути)
«Дюна» (режиссер – Дени Вильнев)
«Король Ричард» (режиссер – Рейнальдо Маокус Грин)
«Лакричная пицца» (режиссер – Пол Томас Андерсон)
«Аллея кошмаров» (режиссер – Гильермо дель Торро)
«Власть пса» (режиссер – Джейн Кэмпион)
«Вестсайдская история» (режиссер – Стивен Спилберг)

тиналарның мөмкинлекләре зуррак булсын өчен» дип аңлата. Нәтиҗәдә, 2021 ел премьералары арасыннан җиңүче булып Америка язучысы һәм кинорежиссеры Шан Хейдерның «CODA: Ребенок глухих родителей» тасмасы табылды.

CODA – оригиналда фильм шушы исем белән аталып йөртелә, бу – аббревиатура («child of deaf adult»). Жанры ягыннан картинаны инди-фильм буларак тәкъдим итәләр, нигездә ул төп героиняның җитлегү тарихын гәүдәләндерә. Провинциаль Глостерда яшәүче Руби Росси абсолют ишетү сәләтенә ия, хәтта музыкаль сәләткә дә, шул ук вакытта ишарәләр телен дә тулаем белә. Чөнки калган гаилә әгъзаларының бөтенесе дә – саңгырау.

Бу фильмның сайлануы һәм җиңүе шактый тапталган карар дип табылса да, шәхсән минем өчен ул – бүгенге вазгыятьтә үтә символик мәгънәгә ия. Һәм бу кабул итү күбрәк иҗтимагый, әхлакый ноктага карый. Без берберебезне ишетү генә түгел, хәтта тыңлау сәләтен дә җуйган чорда «CODA» иң әһәмиятле, беренчел инстинктлар һәм яшәү сәнгате турында сөйли. Бик гади, бернәрсәгә дә дәгъва итми торган тормышчан, хәтта ки көндәлек тел белән. Әнә шул тамакка төер утыртра да.

> «94 НЧЕ «ОСКАР», БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА, ГЛЯНЕЦ-ШОУ БУЛЫП ЧЫКТЫ, АНДА СӘЯСИ АКТИВЛЫККА УРЫН КАЛМАДЫ».
>
> *Тимур Алиев, кино тәнкыйтьчесе*

Руби – балык тотып көн итүче гаиләсе өчен тышкы дөнья белән бердәнбер бәйләнеш, аңардан башка алар хәтта ачык диңгезгә дә чыга алмый. Аларны тәрбияләү белән беррәттән, Руби үзен дә онытмый – ул мәктәп хорына языла, университетка керергә хыяллана. Баштарак аның тәвәккәллегенә сокланасың, һәм бер парадоксны абайламыйсың. Ә абайлап алгач, тәннәрең чымырдап, өшеп китәсең: аның иң кадерле кешеләре беркайчан да Рубиның җырлау сәләтен бәяли алмаячак! Фильмны караганда кеше гомеренең дә, тормышының да ни дәрәҗәдә кадерле һәм уалучан булуын аңлыйсың. Бу бездә яшәгән һәм инде бар яшәешкә тамыр җәйгән мин-минлекне дә, һавалылык белән эгоизмны да арткырак планга күчереп куя торган картина.

Фильм чынлыкта «Семейство Белье» дип аталган француз тасмасының ремейкы. Әмма – бик якынча, бөтенләй башка жанрда һәм чишелештә. Америка версиясендә режиссер Шан Хейдер каст уздыра һәм саңгырау геройларны чын-чынлап саңгыраулар уйнарга тиеш дигән шарт куя. Төшерү алдыннан һәм барышында актриса Эмилия Джонс амслен (американың ишарәләр телен) үзләштерә, аңа махсус консультантлар ярдәм итә.

«CODA», берсүзсез, «Оскар»ның инклюзиягә юнәлтелгән курсын дәвам итә һәм раслый. Яхшымы бу, начармы – бәягә урын юк, минемчә. Дөрес, без «Иң яхшы фильм» номинациясенең иң беренче чиратта фильмның сыйфаты өчен бирелергә тиешлеген аңлыйбыз. Әмма бу юнәлештә «Оскар»ның беркайчан да иллюзияләргә урын калдырганы булмады – ул чиста эстетика категорияләре белән генә эш итми. Хәтта моны ассызыклый да.

Фильмны техник яктан да, эстетик яктан да новаторлыкка ия түгел, бик гадәти дип күп тәнкыйтьләделәр. Аның агышы да, чишелеше дә хэппи-эндны яки нинди дә булса төгәлләүне бөтенләй күздә тотмый, ул – тормышның көндәлек бер документальлеккә якын кисемтәсе. Монда мораль белән күз яшен сыктырырга да омтылу юк. Бер алым бик көчле тәэсир итә – фильм барышында берничә мәртәбә тавышлар юкка чыга, сурәт бераз гына тоныклана, һәм без – мизгел эчендә – ишетмәүчеләр дөньясына күчеп, колакларыбыз да, хисләребез дә томаланып калабыз. Аннан кабат үзебез ияләшкән авазларга әйләнеп кайтабыз. Әмма ишетергә микән, дигән уй бораулый башлый шуннан соң баш миен.

М А Х С У С   П Р О Е К Т

Татарстан юбилярлары

ЭДВАРД АБДУЛЛАҖАНОВ: «КДЭУны ЦИФРЛЫ ҮЗГӘРТЕП КОРУ – КИЛӘСЕ БИШ ЕЛДА ХӘЛ ИТЕЛӘСЕ БУРЫЧ»

Россиянең иң яхшы 100 вузы* исәбендә һәм Үзәк Европа белән Азиядәге үсеп баручы илләренең 1500 вузы кергән QS Emerging Europe & Central – Asia (EECA) University Ranking 2022 халыкара рейтингының беренче 500 вузы арасында булу – болар барысы да Казан дәүләт энергетика университеты турында. КДЭУ ның потенциалы һәм үсеш перспективалары хакында «Татарстан» журналына университет ректоры Эдвард Юныс улы Абдуллаҗанов сөйләде.

– Эдвард Юнысович, КДЭУ РФ Фән һәм югары белем министрлыгының «Патент-2030» стратегия академия лидерлыгы программасы буенча грант отучылар арасына керә. Бу вузга нәрсә бирә?

– Бу 10 ел дәвамында университет ел саен үсеш өчен 100 миллион сум акча алып торачак дигән сүз. Ләкин, аңлыйсыздыр инде, бюджет акчалары болай гына бирелми. Грант кысаларында безгә бик мөһим биш стратегик проектны гамәлгә ашырырга кирәк була. Вуз каршында Интеллектуаль электр транспорты һәм корылма инфраструктурасын алгарышлы үстерүнең фәнсыйдырышлы технологияләре үзәге, Энергетикада водородлы технологияләр платформасы, Электр тапшыру линияләре һәм подстанцияләрен мониторинглау буенча цифрлы бүлү системаларын эшләү һәм гамәлгә кертү үзәге, Атом һәм җылылык энергетикасы институты, Яңартыла торган энергия чыганаклары базасында электр энергиясен генерацияләүнең «яшел» технологияләрен үстерү үзәге оештырыла. Шул ук вакытта энергетика университеты конкурска тәкъдим ителүчеләргә карата куелган таләпләргә туры килүен ел саен раслап торырга тиеш. Шуңа күрә конкурста җиңү – әле ул бик зур җаваплылык та, без аны һичшиксез аклаячакбыз.

– Стратегик проектларның исемнәренә караганда, вуз киләчәк технологияләре, шул исәптән «яшел» технологияләр өлкәсендә белгечләр әзерләүгә керешәме?

– Беренчедән, болар инде бүгенге технологияләр. Икенчедән, без андый белгечләрне инде әзерлибез – югыйсә без заманадан артта калыр идек. Үзегез уйлап карагыз: КДЭУ уңышлы үткән дәүләт аккредитациясе буенча әзерләнә торган 45 юнәлеш арасында «Автоном энергетика системалары», «Электромобиль һәм пилотсыз транспорт», «Атом станцияләрен проектлаштыру һәм эксплуатацияләү», «Биналарда энергия саклау һәм энергия нәтиҗәлелеге», «Автоном энергетика системалары. Водород һәм электр химиясе энергетикасы», «ТЭК предприятиеләрендә энергия нәтиҗәлелеге һәм экологик яктан куркынычсыз технологияләр», «Ясалма интеллект инженериясе» кебекләр бар.

– Фәнни өлкәдә билгеләнгән өстенлекләр шулай ук заман таләпләре белән тыгыз бәйләнгәнме?

– Һичшиксез. Мәсәлән, «Энергия нәтиҗәлелеген күтәрү өчен акыллы наноматериаллар» уникаль лабораториясен төзү идеясенә Президент тикшеренү проектлары программасы гранты ярдәм итә. Яңа лаборатория «Фән һәм университетлар» милли проекты кысаларында «Циркуляр икътисад» (Татарстан) дөнья дәрәҗәсендәге фән-мәгариф үзәге базасында РФ Фән һәм югары белем бирү министрлыгы ярдәме белән оештырылды. КДЭУның тагын бер инновацияле проекты электромобильләргә хезмәт күрсәтү инфраструктурасын төзү буенча дәүләт программасы кысаларында «Зарница» ЖБ» ҖЧҖ белән бергә гамәлгә ашырыла. Бу – электромобильләр өчен

* https://minobrnauki.gov.ru

Фото КДЭУ матбугат үзәгеннән алынды. РЕКЛАМА

энергия сыйдырышлылыгы 1 МВт/сәг.тән ким булмаган электр энергиясен туплауның интеграцияләнгән системасына ия мобиль корылма комплексы.

Белем бирү процессы белән фәнни тикшеренүләрнең үзара бәйләнгән булуы мөһим. Мәсәлән, без Россиядә беренчеләрдән булып уку программасына керткән җил көчен үлчәү теориясе башта гамәлдә сынау узды. КДЭУ галимнәре республикада җил паркларын төзү проекты өчен җил көчен үлчәүне башкарды. Хәзер алынган бөтен компетенцияләр һәм яңа мәгълүмат җил энергетикасы өлкәсе өчен белгечләр әзерләүдә киң кулланыла. Вуз студентлары уку йортында булган иң яңа җиһазлар ярдәмендә конкрет проектларга таянып белем ала.

– *Киләсе 10 елда университетны үстерү программасы фәнни оешмалар, университетлар, индустриаль партнерлар катнашында консорциумнар төзүне күз уңында тотканын беләбез. Хезмәттәшлектә мондый ысулның уңай яклары нәрсәдә?*

– Консорциумнар илнең фәнни-техник үсешендә аерым юнәлешләр буенча анык бурычларны хәл итү өчен катнашучыларның үзара хезмәттәшлеген оештырырга булыша. Бүгенге көндә КДЭУ катнашында 5 консорциум төзелгән һәм алар уңышлы эшли. Без, мәсәлән, водород технологияләре консорциумына керәбез, конкрет юнәлеш – корылма станцияләре буенча эшлибез. КДЭУ шулай ук «Недра» консорциумында катнаша, ул Санкт-Петербург тау университеты каршында төзелгән. Моннан тыш, якын елларда университетны үстерү программасын гамәлгә ашыру кысаларында яңа консорциумнар төзү һәм КДЭУның төрле юнәлешләр буенча инде эшли торган башка синдикатларга керүе планлаштырыла,

– *КДЭУның партнерлары арасында Россия вузлары гына исәпләнәме?*

– Без төрле илләрдәге консорциумнар белән хезмәттәшлек итәбез. Безне Россия-Кыргызстан техник университетлары консорциумы кысаларында Кыргызстан Республикасы белән тыгыз фәнни-белем бирү элемтәләре бәйли. Бу – уртак челтәр белем бирү программаларын үстерү һәм аларга ярдәм итү максатын күздә тоткан Россия һәм Кыргызстан вузларының ирекле берләшмәсе. Аңа Россиядән –33, Кыргызстаннан 9 белем бирү оешмасы керә.

КДЭУ Россия һәм Казахстанның техник белем консорциумында (КТОРК) Россия ягыннан куратор санала. Ул ирекле нигездә ике илнең техник университетларын берләштерә һәм Россия Федерациясе белән Казахстан Республикасы арасындагы хезмәттәшлек буенча Хөкүмәтара комиссия кысаларында һөнәри югары техник белем бирү өлкәсендә нәтиҗәле платформа булып тора. КТОРК 21 вузны берләштерә: Россиядән – 13 һәм Казахстаннан 8 уку йорты.

– *Вуз һәм ул әзерләгән белгеч. Бүген вуз дипломы һәрвакытта да белгечлек буенча эшкә урнашуны гарантияли алмый...*

– Теләсә кайсы вуз эшендәге нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләре арасында – аны тәмамлаучыларга ихтыяҗ. Безнең кичәге студентларыбызның 75 проценттан артыгрgalы белгечлек буенча эш таба. Килешәсездер, бүгенге шартлар өчен бу яхшы күрсәткеч. Вузны тәмамлаучылар эшкә урнашканда башка кандидатлар белән уңышлы көндәшлек итә алсын өчен, университет аларның һөнәри осталыклары белән беррәттән, стандарт булмаган фикер сөреше, оештыру сәләте, максатчан рәвештә нәтиҗәгә омтылу, командада эшли белү, аралашуга һәм яңалыкка әзер булу кебек шәхси сыйфатларын да үстерә. Дипломлы белгечләрне эшкә урнаштыру буенча эш даими нигездә алып барыла.

– *ТР башкаласының иң яхшы архитектура объектына конкурс нәтиҗәләре буенча Казанның иң яхшы җәмәгать бинасы номинациясендә КДЭУ бинасы җиңүче дип табылды...*

– Сүз 21 катлы тулай торагыбыз турында, ул чыннан да Казанның бизәгенә әйләнде. Тулай торак бинасын төзү Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән федераль максатчан программага кертелгән иде. Шунысын да билгеләп үтим: бу соңгы биш елда КДЭУ тарафыннан файдалануга тапшырылган икенче тулай торак. Заманча фәнни-белем бирү базасы, уку һәм яшәү, спорт белән шөгыльләнү өчен уңайлы шартлар – замана белән бергә атлаган вузны болардан башка күз алдына китереп булмый.

– *Эдвард Юнысович, узган ел ахырында КДЭУ ректорын сайлаулар үтте, анда делегатларның 93 проценты сезнең кандидатураны хуплады. Киләсе биш елга нинди планнар белән яшисез?*

– Ышаныч күрсәткәннәре өчен коллегаларыма рәхмәт. Минем өчен бу бик зур шатлык та, җаваплылык та. Һәр җитәкче өчен коллективның аны хуплавы бик мөһим. Ышанычтан башка алга бару мөмкин түгел. Татарстан Президенты һәм энергетика компанияләренең ярдәме нәтиҗәсендә без бик күпкә ирештек. Бүген университет каршында яңа зур бурычлар тора, һәм барыбыз да бергәләп куелган максатларга ирешербез, дип ышанам.

Вузны цифрлы үзгәртеп кору, приборлар базасын яңарту, шулай ук яңа фәнни базар продуктлары уйлап табу һәм аларны коммерцияләштерү – киләсе биш елга КДЭУның төп үсеш юнәлешләре әнә шулар.

Казан дәүләт энергетика университеты коллективы вуз ректоры Эдвард Юныс улы Абдуллаҗановны 65 яшьлек юбилее белән котлый!

КИЛӘЧӘККӘ «КОРЫЛУ»

Рифнур СӨЛӘЙМАНОВ,
«Татэнергосбыт» АҖ директоры

– Хөрмәтле Эдвард Юнысович!

Узган елны Энергетиклар көненә багышланган йомгаклау матбугат конференциясендә үзегезнең уку йорты казанышлары турында сөйләгәндә Сез болай дигән идегез: «Беркем дә бездән мондый җитезлекне һәм тизлекне көтмәгән иде, мин илнең иң яхшы йөз вузы арасына керүне һәм «Приоритет-2030» конкурсында җиңүне күз уңында тотам».

Хәер, мин «беркем дә көтмәде» дигән сүзләр белән килешеп бетмим. Хәтта киресенчә кебек. Сез җитәкләгән профильле уку йорты елданел үзенең хәлле булуын, уңышлы эшләвен раслап килә, аның республика энергетикасы өчен әһәмияте бәһаләп бетергесез.

Моңа ничек ирешелә соң? КДЭУның әлеге уңышына күп очракта ректорның эш стиле ярдәм итүенә иманым камил. Фәнни кыюлык, төгәл аналитик фикер сөреше һәм замана таләпләрен аңлау һәрвакытта та Сезнең өчен мөһим булды. Болар барысы да, Сездәге яңа идеяләр, максатчанлык һәм мавыгучанлык-һәвәслек белән бергә, укытучылар коллективында уңай яңгыраш таба. Һәм бездә, озак еллар дәвамында алып барылган хезмәттәшлек нәтиҗәсендә энергетика университеты чыннан да үзебезнекенә әверелгәннәрдә дә, яклау һәм хуплауга ирешә.

Казан дәүләт энергетика университеты – инженерлар әзерләү буенча алдынгы мәктәп, республика энергетикасы тармак предприятиеләренең төп өлешен тәшкил итүче күп кенә белгечләр биредә белем алган. Бүген «Татэнергосбыт» АҖндә энергетика университетын тәмамлаган 270тән артык белгеч хезмәт куя.

Ел саен КДЭУның элеккеге студентлары безнең коллективка кушыла. Яхшы әзерлек үткән, нәтиҗәлелеккә омтылучан, эш белән кызыксынучан, сәламәт амбицияләргә ия, үз һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләнгән, компания алардан ни көткәнне аңлаучы белгечләр алар.

Студент, аспирант һәм укытучыларның зур командасы белән идарә итү белән бергә, үз тирәсенә вуз җәмәгатьчелеген туплый алган кеше буларак, Эдвард Юнысович, боларның барысында да Сезнең өлешегез искиткеч зур. Чын ректор буларак, Сез уку йортында иң заманча фәнни-тикшеренү һәм белем бирү базасы, студент һәм аспирантларга яшәү өчен уңайлы шартлар булсын, алар яхшы укыган һәм фәнни эш алып барган өчен матди ярдәм алсын, күптөрле мәдәни тормыш, сәламәт яшәү рәвеше алып барсын өчен барысын да эшлисез. Университетта бөтен җәмәгать киңлекләре төзекләндерелгән – уку корпуслары, тулай торак, ашханә...

Университет белән үзара җылы, дусларча, хезмәттәшләрчә мөнәсәбәтләр урнаштырылганга без бик шат, бу безгә уртак проектларны уңышлы алып барырга ярдәм итә. Күптән түгел оештырылганнардан – «Карьера язы – 2022» һәм «Карьера digital-2022» вакансияләр ярминкәсе. Мондый турыдан-туры элемтәләр бик әһәмиятле, чөнки бу студентларны тагын яхшырак укырга дәртләндерә, ә предприятиеләр яшь белгечләр килү белән, талантлар концентрациясен һәм компаниянең нәтиҗәлелеген күтәреп, киләчәккә кадрлар «корылмасы»на ия була.

Шул ук вакытта безнең уртак миссия – Татарстан энергетика комплексын алга таба үзгәртеп кору, ә бу югары квалификацияле кадрлардан башка мөмкин түгел. Шуңа күрә «Татэнергосбыт» АҖ, уртак проектларны үзгәртеп һәм яхшыртып, аларда катнашырга һәрвакыт әзер.

Эдвард Юнысович! Сез һәрвакыт үз тирәгездәгеләрне рухландыра алу, аларга көч-дәрт өстәү сәләтенә ия!

Республиканың әйдәп баручы фәнни-белем бирү һәм инновацияле үзәге буларак Казан дәүләт энергетика университетын нығытуга керткән хезмәтегез өчен рәхмәтемне белдерәм.

«Татэнергосбыт» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән туган көнегез уңаеннан ихлас теләкләребезне кабул итегез! Сезгә нык сәламәтлек, тынычлык һәм иминлек юлдаш булсын!

Фото:@ «ТАтар-информ» МА. РЕКЛАМА

НОВАТОР ЭНЕРГИЯСЕ

– «Аның белән сезгә җиңел булмас, әмма аның белән иң яхшылар булачаксыз!» Бу сүзләрне Казан дәүләт энергетика университетының төп бинасында нәкъ биш ел элек әйткән идем. Ул чакта **Эдвард Юныс улы Абдуллаҗанов**, сайлауларда зур аерма белән җиңеп, ректорлыкның икенче срогына керешә. Чиксез шатлыгыма, 2021 елның декабрендә бу хәл кабатланды һәм бүген мин моңа кадәр әйтелгән һәр сүземне расларга әзер. Һәрвакыт вакыйгалар авангардында барган новатор кеше белән эшләү җиңел булырга мөмкинме соң? Юк. Тик нәтиҗәсе авырлыкларны аклый! Россиянең иң яхшы вузларыннан берсенә әйләнгән Казан дәүләт энергетика университеты уңышлары – моның ачык мисалы.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Фотода сулдан уңга: «Татэнерго» АҖ генераль директоры Рәүзил Хаҗиев; Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов; Казан дәүләт энергетика университеты ректоры Эдвард Абдуллаҗанов.

Фото «Татэнерго» АҖ матбугат үзәгеннән алынды. РЕКЛАМА

«Бу чыннан да бик шәп!» – болары исә ул вакытта Россиянең премьер-министры булган Дмитрий Медведевның Казанга сәфәре вакытында КДЭУның ике уку полигонын – «110/10 кВ лы подстанция»не һәм «0,4–10 кВлы бүлү челтәре»н күргәч әйткән сүзләре. Әйе, илнең энергетиклар әзерләп чыгара торган бер генә югары уку йорты да мондый байлыкка ия түгел! Абдуллаҗановның тагын бер колачлы идеясен тормышка ашыруга өлеш кертеп, башка энергетика компанияләрендәге хезмәттәшләребез белән бергә бу эшнең финанс мәсьәләсендә катнашуыбызга бик шатбыз. Шунысын да әйтергә кирәк: ул безнең тармак өчен белгечләр әзерләүне яңа биеклеккә күтәрде.

Энергетика бездән аеруча төгәл һәм грамоталы булуны таләп итә. Эшли башлаганда ук инде чын белгеч булырга кирәк. Безнең тармак өчен кадрлар әзерли торган төп уку йорты җитәкчесе белән бу яктан карашларыбыз туры килүне аеруча югары бәялим. Тик галим ни өчен хезмәтнең гамәли ягын шулкадәр кайгырта соң әле? Алай гына да түгел, бу – аны башкалардан аерып торган сыйфат! Моңа нигезле аңлатмам бар: Абдуллаҗанов безнең өлкәдә үз кеше. Ун елдан артык алдынгы энергетика предприятиеләрендә җитәкче вазыйфалар башкарган затның тармак өчен генә түгел, ә югары уку йортлары тормышка юллама биргән егет-кызлар өчен дә зур җаваплылык тоюы һич тә гаҗәпләндерми. Бүген КДЭУ студентлары сәламәтлекләре өчен бернинди дә куркыныч тудырмыйча яңа полигоннарда белем ала, булачак электромонтер һәм электр монтажлаучылар «ElectroSkills» гамәли компетенцияләр үзәгендә һөнәри күнекмәләрен шомарта. Үзган ел нәтиҗәләре күрсәткәнчә, уку йортын тәмамлап, үз белгечлеге буенча эшкә урнашкан студентларның нисбәте ягыннан Казан энергетика университеты Россия вузларының беренче бишлегенә керде. Моңа гаҗәпләнмим дә. Безнең предприятиеләр өчен кадрларны менә шул рәвешле әзерләү мине бик канәгатьләндерә.

Сүз уңаеннан, ректорлык эшенә керешкән чакта ук, Эдвард Юныс улы Татарстанның эре энергетика компанияләре белән нәтиҗәле хезмәттәшлек урнаштыруга ирешә. Безне вузга якынайту турында сүз бара. Бергәләп без энергетика университетының бүген предприятиеләрдә эшләп килгән сигез база кафедрасын ача алдык. Әлбәттә, «Татэнерго», дөресрәге, безнең предприятие базасында төзелгән «Энергопрогресс» инженерлык үзәге дә читтә калмады. «Җылылык һәм электр энергетикасында энергиянең нәтиҗәлелеге» кафедрасының эше безгә яңа этәргеч бирә! «Югары уку йортларына һәм производствога тырышлыкларны берләштерү һәм бер-береңә каршы бару күптән кирәк иде» – әйе, болары да минем сүзләр. Алдынгы фән белән прогрессив практиканың хезмәттәшлек нәтиҗәсе соклану уятмый кала алмый. Энергетика бер урында гына таптанып тормый, бергәләп без яңа технологияләрне үстерәбез – эш күп булачак әле. Һәм моңа сөенергә генә кирәк.

Хөрмәтле Эдвард Юнысович, Сезне гомер бәйрәмегез белән котлыйм! Безнең тармак өчен Сез бик кирәкле кеше! Сездәге новаторлык энергиясе, яңарышка омтылыш бер дә кимемәсен, башкарылган эшләр санын арттырсын һәм алгарышка юл ачсын. Сезгә нык сәламәтлек һәм игелекле эшегездә яңа уңышлар телим!

ШӘП ТЕОРИЯГӘ НИГЕЗЛӘНГӘН ТӘҖРИБӘДӘН ДӘ ЯХШЫРАГЫ ЮК

Бүген күп кенә эш бирүче югары уку йортын тәмамлап килүчеләрдә тиешле күнекмәләр һәм осталык җитмәве турында белдерә – аларны турыдан-туры эш урынында өйрәтергә туры килә. Җитештерү процесслары барыннан да элек нәтиҗәлелек, инновацияләр һәм ышанычлылыкка йөз тоткан компания буларак, без вакыт кебек кадерле нәрсәне файдасызга сарыф итүгә юл куя алмыйбыз. Шуңа күрә дә, персонал сайлаганда, эш эзләүчеләрнең махсус белемнәренә аеруча игътибар бирәбез.

Марат КАМАЛОВ, «ЭлектроОптима» ҖЧҖ генераль директоры

Нәкъ менә шуңа күрә бүген бездә эшләүче 185 кешенең 85% тан артыгы Казан дәүләт энергетика университетын тәмамлаган яки хәзер шунда белем ала. Энергетика университеты – бездә иң җаваплы вазыйфаларны биләгән барлык профессионаллар өчен alma mater ул.

Түбәндәге сүзләрем белән Татарстан һәм Россиянең барлык энергетиклары да килешер дип уйлыйм: бу университетны тәмамлаучылар теге яки бу эш бирүченең таләпләре турында һәрвакыт анык күзаллый. Ике базар – белем бирү һәм хезмәт базары вәкилләре булган «ЭлектроОптима» ҖЧҖ һәм КДЭУ арасында, студентларның җитештерү практикаларын оештыру һәм уздыру юнәлешен дә күздә тотып, хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды. Әйтик, бездә практика үтеп, студентлар чынбарлыктагы җитештерү шартларында эш күнекмәләрен арттыра. Шунысы да билгеле: КДЭУ студентларының шактый югары теоретик әзерлеге аларга коллективлардагы практикаларда нәтиҗәле эш алып барырга мөмкинлек бирә. Ә предприятие өчен яхшы теориягә нигезләнгән тәҗрибәдән дә яхшырак нәрсә була ала?

Сүз уңаеннан, студентларның һәм бу уку йортын тәмамлаучыларның кейс һәм компетенцияләре елдан-ел арта бара. Моны студентларның компаниябездә уза торган практикалары һәм стажировкалары раслый. Өстәвенә, алар «ЭлектроОптима» ҖЧҖдә практиканы «өлкәннәрчә» үтә – рәсми рәвештә эшкә алына, хезмәт хакы, махсус кием һәм бушлай туклану белән тәэмин ителәләр, уку белән эшне бергә алып бару мөмкинлеге өчен махсус графиклар төзелә.

Моннан тыш, персоналның квалификациясен күтәрү программаларын тормышка ашырганда, производствога яңа эшләнмәләр керткәндә, без университет профессорлары, мөгаллимнәре белән актив хезмәттәшлек итәбез.

Хөрмәтле Эдвард Юнысович!

Сез – үз эшегезнең чын остасы, Татарстан энергетика системасының эчке ягын яхшы беләсез, шуңа күрә Сез җитәкләгән профильле югары уку йорты шундый искиткеч уңышларга иреште. Соңгы елларда биредә студент, аспирант һәм укытучыларның мөмкинлекләрен төрле яклап үстерү, файдалану өчен барлык шартлар да тудырылды. Ел саен яңа лабораторияләр, инжиниринг үзәкләре, тиңе булмаган уку полигоннары ачыла. Биредә студент һәм аспирантлар өчен уңайлы көнкүреш шартлары тудырылган.

Сезнең КДЭУ хакына башкарган хезмәтләрегез, тулы куәткә эшли белүегез һәм энергиягез зур хөрмәткә лаек!

Без республикабызда шундый бай тарихлы, заманча фән һәм тәҗрибә-конструкторлык базасына ия, алдынгы укытучылар, профессорлар белем бирә торган югары уку йорты булуы белән горурланабыз. Күбесенчә Сезнең ярдәм белән КДЭУ һәм җитештерү эшенең интеграциясе даими ныгый бара. Болар барысы да Татарстан энергетика комплексының хәзергесенә һәм киләчәгенә зур кертем булып тора.

Күркәм гомер бәйрәмегез көнне «ЭлектроОптима» ҖЧҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә нык сәламәтлек, оптимизм, алга куелган барлык план һәм максатларыгызның тормышка ашуын телим!

Фото «ЭлектроОптима» ҖЧҖ тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

vk.com/protatarstann

t.me/protatarstan

youtube.com/channel/
UCuOhLcARMGm1PZnmAdaYdEQ

**БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!**

Реклама 16+

ТАТАРСТАН АВЫЛЛАРЫ

ИМӘНДӘЙ НЫК УТЫЗ ИМӘН



УТЫЗ ИМӘН

Фото: Александр Ефремов

Төрле сәбәпләр аркасында исемен алыштыручы кешеләр бар. Кайчагында авыллар белән дә шулай була. Чирмешән районының атаклы Утыз Имән авылы да ике дистә ел элек исемен алыштырган. Хәер, дөрес сөйләмим, авыл тарихи исемен кире кайтарган.

Руфия Фазылова

ҖЫР-МОҢГА ГАШЫЙК ХАЛЫК

Утыз Имәннең зур авыл икәнлеге турында ике катлы мәдәният йорты, аннан да зуррак мәктәп бинасы сөйли. Бирeдә хәтта кафе да эшли. Ни кызганыч, республиканың меңләгән авылында кебек үк, Утыз Имәндә дә халык саны кими. 155 хуҗалык бар, 378 кеше яши. 1987 елда 320 балага төзелгән мәктәптә бүген нибары уналты укучы белем ала. Шушы саннардан барысы да аңлашыла кебек...

Утыз Имән белән танышуны мәдәният йортыннан башладык. Ни өчен дигәндә, ул чын мәгънәсендә авылның үзәге булып тора. Авыл җирлеге идарәсе, китапханә, заманча җиһазландырылган спорт залы – барысы да бирeдә. Хәтта мәктәп балалары да монда укый. Эш шунда ки, Утыз Имәннең ике катлы мәктәбендә республика программасы буенча капиталь төзекләндерү эшләре бара. Шуңа да вакытлыча укытучылар белән укучылар мәдәният йортына күчкән.

– Кызганыч, җәй түгел, каршыда үсеп утырган утыз имәннең бөтен матурлыгын күрә алмыйсыз, – диде Утыз Имән авыл җирлеге башлыгы Мингәрәй Әминов.

Бактың исә, 2004 елның маенда, Утыз Имәнинең 250 еллык юбилее хөрмәтенә, мәдәният йорты каршына утыз имән утыртылган. Бүген алар шаулап үсеп утыра. Урта мәктәпкә дә Утыз Имәни исеме бирелгән. Мәдәният йортының эченә аяк баскач та, аптырап киттек – зообbooтаника бакчасы диярсең! Фойеда нинди генә гөл үсми! Чисталык белән зәвыклылык та сизелә.

– Сездә гел шулаймы соң, әллә инде кунаклар килә дип әзерләндегезме? – дим, уенынчынын кушып.



1 Мәдәният йорты чын мәгънәсендә авылның үзәге булып тора.

2 Утыз Имәндә өлкәннәр бик актив. Көн саен скандинавия таяклары белән йөрергә чыгалар. Бер очтан монда кереп, әлеге тренажерларда шөгыльләнәләр.

– Гел шулай. Бездә клубка халык аяк киемен салып керә, – диде җирлек башлыгы. – Биредә сәнгатьне аңлаган, яраткан халык яши. Мәдәният йорты сигез ел элек капиталь төзекләндерелгән иде. Ике кат буенча да йөреп чыгыгыз – ник бер җирдә пычрак эзе, ватылган урын булсын.

Чынлап та, Мингәрәй Әминов әйткән сүзләргә инандык – бина кичә ремонтланган диярсең. Биредә тагын бер нәрсә гаҗәпләндерде – спорт залы. Ул заманча тренажерлар белән җиһазландырылган. Хәтта йөгерү юлына кадәр бар.

– Капиталь төзекләндерүдән соң мәдәният йорты ачылышына нефтьчеләр бүләк итте, – диде җирлек башлыгы. – Бездә бит өлкәннәр бик актив. Көн саен скандинавия таяклары белән йөрергә чыгалар. Бер очтан монда кереп, әлеге тренажерларда шөгыльләнәләр. Аннары ансамбльгә йөрүче хатын-кызлар, ир-атлар бар. Гаиләләре белән киләләр, алар да шөгыльләнә.

Сәхнә ягына уздык. Иң беренче күз биек, алтын төсенә буялган бизәкле түшәмнәргә төште. Опера театры диярсең! Ул да түгел музыка башланды. Сәхнәдә милли киемнәрдән апалар җырлый икән! «Наз» ансамбле махсус безнең өчен мини-концерт әзерләгән...

Утыз Имәндә бер түгел, ике ансамбль эшли. Берсендә фәкать – хатын-кызлар, икенчесендә ир-атлар җырлый. Район, республика күләмендә уздырылган конкурсларда катнашалар, урыннар алалар. Сөйләшә торгач, кызлар бер үзенчәлек турында әйтте – бәйгеләрдә күбрәк Утыз Имәннең ир-атлар ансамбленә өстенлек бирәләр икән.

– Ир-атларны сәхнәгә бик алып менеп булмый бит, безнең авылда гына ул батыр һәм талантлы ир-егетләр, – диде Утыз Имәннең мәдәният йорты җитәкчесе Руша-

ния Әминова. – Кая барсак та: «Их, сезнең егетләр!» – диләр.

Кызганыч, авылның ир-атлар ансамбле – «Кади егетләре» белән танышып булмады, эштә, диделәр, ә менә «Наз» ансамбле тулы состав белән мәдәният йортында иде.

– Ансамбль 1991 елда оешты, – дип таныштырды үзләре белән «Наз» солистларының берсе Лениза Җамалиева. – Без инде шул чорлардан бирле монда. Олырак апалар ансамбльдән китә, яшьрәкләр килә. Әнә шулай традицияләрне дәвам итеп, халык җырларын тамашачыга җиткерәбез.

«Наз»га йөрүчеләр арасында укытучы, китапханәче, хисапчы, тәрбияче кебек һөнәр ияләре бар. Әллә ничә төрле сәхнә костюмы тектергәннәр. Ел әйләнәсе мәдәният йортында алар.

– Безгә мәдәният йорты кирәк. Ирләребез дә ияреп килә. Без репетиция ясаганда, алар бильярд уйный, аралаша, – ди кызлар.

Моннан тыш, Утыз Имәндә театр труппасы да бар. Спектакльләр белән төрле җирләргә баралар. Берничә ел элек халык театры исемен дә алырга йөргәннәр. Тик документларның гына очына чыгып бетә алмаганнар.

«ӘНИГӘ ҮПКӘМ ЮК»

Авылның иң өлкән кешеләреннән берсе Рәйсә апа Кыямовага күптән түгел 95 яшь тулган. Бүген ул сеңлесенең кызы Гөлйөзем Хәйруллина белән яши. Үз нигезен ташлап, бирегә килгәненә ун елдан артып киткән.

– Гомер буе икенче урамда яшәдем. Анда күршеләр дә калмады, шуңа Гөлйөзем үзләренә чакырды, – диде әбекәй.

Гөлйөзем апа үзе дә лаеклы ялда икән. Күп еллар авылда почта тараткан. Узган ел ире Мингаяз абый вафат булган, ковидтан тернәкләнә алмаган. Бүген бу нигездә өчәү яшиләр: Хәйруллинарның уллары Айрат авылда калган, нефтьче.

Чирмешән районы элек-электән суган үстерү белән дан казанган. Рәйсә апа да заманында бакчасында берүзенә икешәр тонна суган үстереп саткан. Орлыгын да үзе ясаган, утырткан, алган...

– Эшләп көн иттек, – диде әбекәй. – Үсмер чагыннан ук үгез җигеп йөк ташый башлаган идем, картайганчы колхозда эшләдем. Тормыш авыр булса да, Аллага шөкер, авырып интекмәдем. Шушы гомер эчендә бары бер тапкыр бүлнистә яттым.

Ул да түгел, Рәйсә апа бик кирәкле мәгълүматны әйтергә теләгәндәй:

– Кызым, өч төрле алфавит беләм. Латин хәрефләренә карап кириллицаны үзлегемнән өйрәндем. Газета-журналлар укырга кирәк иде бит. Укырга бик яраттым. Хәзер генә күзем начарланды, берсе бөтенләй шәүлә генә күрә.

3

4

3, 4

Утыз Имәндә бер түгел, ике ансамбль. Берсендә фәкать - хатын-кызлар, икенчесендә ир-атлар җырлый.

5

5

Рәйсә апа Кыямова сеңлесенең кызы Гөлйөзем Хәйруллина белән яши.

6

Ябиновлар өч ел элек мини-фермалар программасына кергән.

...Рәйсә апаның язмышы бик үзенчәлекле. Өч яшендә әнисе аны иренең туганнарына калдырып кияүгә чыга. Дөрес, шунда ук, Утыз Имән авылы кешесенә. Туганнарының алты баласы янәшәсендә, җиденче булып үсә ул. Иң гаҗәбе – әбекәй әнисен картайган көндә үзе карап соңгы юлга озата.

– Әни алты айлык сеңлемне үзе белән алып киткән, – диде әби. – Гөлйөземнең әнисе була инде ул.

– Ә сезне ник калдырган? – дип аптырап.

– Тегендә ят ир бит, ә монда туганнар. Юк, кызым, әнигә бер тамчы үпкәм дә юк. Бүтән чарасы булмаган инде аның. Мине туганнар рәнҗетмәде. Бик эшчән идем, бәлки шуңа да яратканнардыр. Мәктәпкә киткәнче идәннәрне юып китә идем. Кайткач тагын йөгерә-йөгерә су ташыйм, балалар карыйм. Рәхмәт, абый белән җиңгинең бер авыр сүз әйткәне булмады...

Рәйсә апаның балалары булмаган. Кияүгә чыгып, берничә ай гына яшәгән, аннан әнисе белән үги әтисе йортына кайткан. Һәм гомер буе шул нигездә яшәгән. Картлыгында ялгыз калдырмаган өчен Рәйсә апа сеңлесенең кызына рәхмәт укыды.

– Үзебезнең янибызга әни белән апаны икесен бергә алып килгән идек, – диде Гөлйөзем апа. – Әни кинәт кенә мәрхүм булып куйды. Әни урынына апа калды. Бик ипле ул, көн дә безгә дога кыла. Безгә генә түгел, авылда мәрхүм булган бик күп әрвахлар рухына багышлап догалар укый. Апаның тавышы матур, элек мәҗлесләрдә башлап җырлаучы булган. Яшәсен генә, дибез, безгә иптәш ул.

«ТӨНГЕ ӨЧТӘ ТОРАМ»

Утыз Имәндә мал асраучылар күп. Ябиновлар гаиләсендә бер генә түгел, алты баш сыер бар. Өч ел элек мини-фермалар программасына кергәннәр. Аның шартлары бик гади – үзеңнең өч баш сыерың янына тагын өчне аласың да, биш ел дәвамында баш санын киметмисең. Шуның өчен аларга дәүләт 200 мең сум кайтарылмый торган субсидия биргән. Ягъни өч сыерларын дәүләт акчасына сатып алганнар.

– Каралты салырга исә район администрациясе ярдәм итте – кирпеч, бер тонна цемент, биш кубометр такта бирде, – дип санап китте гаилә башлыгы Әнәс абый. – Әле урманнан агачлар да тәкъдим иткәннәр иде, анысыннан баш тарттым. Саву аппаратын да дәүләт программасы буенча бушка алдык.

Чирмешән районында йөз утызлап мини-ферма бар. Әлеге программага кергән хуҗалыклар саны буенча алар республикада беренче урында.

Ябиновларның биш кешелек пай җирләре дә бар, ләкин ул арендага бирелгән. Гаилә башлыгы иген, печән үстерүне кирәксенми. Аның үз фәлсәфәсе:

– Бер ай сөт саткан акчага печән, икенче айныкына иген аласың да, калган айларда сөттән кергән акча үзеңнеке. Пай җирләренә печән, иген алабыз. Саламны исә «Әккәрәй» җәмгыяте күпме кирәк, шуның кадәр бушка бирә. Авыл җирлеге идарәсе тракторы саламны пресслап бирә, мал асраучыларга ул яктан бик җайлы.

– Игенне көздән сатып алдыгызмы? – дим.

– Әйе, көздән. Килосын 12 сум 50 тиен белән алдык. Иген сакларга зур келәтебез бар.

Фермерның хуҗалыгында бүген алты сыер, бер бозау бар. Бозауларны яшь килеш сата баралар икән. Шулай җайлырак, диделәр. Әнәс абыйның төп эш урыны да бар – халыктан сөт җыя. Төнге өчтә торып, дүртенче яртыда эшкә чыгып китә икән.

– Бүген сөтнең литрын 27 сум белән җыябыз, – диде ул. – Күрше Иске Кади авылында шәхси эшмәкәр бар. Ул авыллардан сөт җыю белән шөгыльләнә. Мин аның машинасында эшлим.

– Сез таң белән чыгып киткәч, сыерларны кем карый? – дим.

– Хатын инде. Улыбыз Илназ эшкә иртәнге алтыда гына китә, ул ярдәмгә чыга.

Алты сыер савуны Сирин апа бер дә авырсынмый, чөнки гомер буе мал асраганнар. Аның да төп эш урыны бар – мәктәптә идән юа. Ир белән хатын икесе дә Утыз Имәннән. Егерме тугыз ел элек гаилә корганнар. Бер кыз белән бер ул тәрбияләп үстергәннәр. Кызлары кияүдә, шәһәрдә яшиләр. Әле йортта Әнәс абыйның әнисе Гөлсирә апа да бар.

– Без гел эштә булдык, балаларны әни үстерде, – диде Сирин апа. – Хәзер дә йортка күз-колак ул. Бездә эш беркайчан бетми. Җәй көне җитмеш сутый бакчада бәрәңге, чөгендер, яшелчә үстерәбез. Тырышмасаң, авыл җирендә яшәп булмый бит.

Әнәс абыйның ишек алдында ике тракторы да тора. Җир сукалау, печән алып кайту – бер эшкә дә кешегә ялынмыйлар. Бу гаиләне тырыш дип әйтү генә аз, тиктормаслар дияр идем.

«УРА, СУГА, ҖИЛГӘРӘ...»

Утыз Имәннең тагын бер гаҗәп уңган кешесе белән таныштык – Сания апа Гыйләҗева. Дистә елдан артык эретеп ябыштыручы булып эшләгән бу сөйкемле ханым бүген авылдашларына кайнар ипи, камыр ризыклары пешерә.

Алда әйткәнемчә, Утыз Имәндә кафе бар. Хуҗасы – Утыз Имәндә туып-үскән Әдип Нуруллин. Гомер буе хәрби хезмәттә булган Әдип абый, лаеклы ялга чыккач, туган авылыннан йорт сатып алган. Аннан исә әнә шулай кибет һәм банкет залыннан торган зур бина төзеп куйган. Казанда яшәсәләр дә, Әдип Нуруллин гаиләсе белән Утыз Имәнгә еш кайтып йөри, бигрәк тә җәйләрен.

– Кафе ачылганга ун ел инде, – диде Сания апа. – Мин беренче көннән үк биредә эшлим. Үзем кебек уңган кыз – Ландыш Әхмәтҗанова бар. Нигездә, камыр ризыкларын аның белән икәү пешерәбез. Зур банкетлар булганда, ярдәмгә тагын бер ханым килә.

– Камыр ризыкларын көн дә пешерәсезме? – дим.

– Көн дә ипи пешерәбез, арышныкын да, бодайныкын да. Ә камыр ризыкларын заказ буенча әзерлибез. Шимбә, ял көннәрендә заказлар аеруча күп була – күрше авыллардан да киләләр. Пирог, бавырсак пешерәбез, каз каклыйбыз – Аллага шөкер, барысына да өйрәндек.

Сания апа пешергән пирогларны без дә авыз иттек – бик тәмле. Эчлекләрен дә үзе әзерли икән. Кызыл, кара җимешләрне алырга Казанга махсус бара.

– Мәҗлесләргә менюны да үзем төзим, ризыкларны да үзем сатып алам, – диде.

– Ә барысының да рәтен кайдан беләсез? Махсус белемегез юк икән, – дим.

7 Утыз Имәнинең 250 еллык юбилее хөрмәтенә мәдәният йорты каршына утыз имән утыртылган.

8 – Шимбә, ял көннәрендә заказлар аеруча күп була – күрше авыллардан да киләләр, – ди Сания апа Гыйләҗева.

– Тәҗрибә һәм кыюлык – иң мөһиме шул. Гомергә бер эштән курыкмадым. Кафе ачылган вакытта Әдип абыйга үзем тәкъдим иттем. Эшләп карыйсым килә, булдыра алмасам китәм, дидем. Миңа ул вакытта илле өч яшь иде. Ун ел вакыт бер мизгел булып узып киткән.

– Күз тимәсен, йөгереп кенә йөрисез. Алтмыш өч яшь дип кем әйтсен! Болай яшь булып калу өчен нишләргә кирәк? – дим.

– Кешеләрне яратырга, эшеңнән тәм табарга кирәк. Хезмәт юлымны эретеп ябыштыручы булып башлаган идем, Чаллыда эшләдем. Инде үзебезнең авыл егетенә кияүгә чыккач, Утыз Имәнгә кучәнеп кайттым. Ун елдан артык колхоз паркында машина, тракторларны ремонтладык. «Сания эретеп-ябыштырсын әле», – дип әйтә иде ир-атлар. Әйтәм бит, эшеңне яратсаң, һәр җирдә уңышка ирешеп була.

...Җир җимертеп эшләү диләр бездә. Утыз Имән халкына карата, җир җимертеп яшиләр, дип әйтсәң дә килә. Кунакчыллык, җыр-моңга хирыслык һәм хезмәт сөю – үзендә татарның иң күркәм сыйфатларын туплаган халык яши биредә.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Авылга нигез салучы беренче татар Кади булган дип уйлыйбыз. Авылның мәктәп музеенда Кади бабайның борынгы шәҗәрәсе саклана. Анда аның җиде буыны язылган. Кади нәселе шәҗәрәсендә теркәлгән соңгы кеше – Мөхәммәтшәриф, ул 1820 елда туган. Һәр буынга утызар ел биреп, артка кучереп санаганда, нәсел, кимендә, 180 ел яшәгән диген сүз. Кади бабайның авылга килгәндә бик яшь кеше булмавын исәпкә алсак, Утыз Имәннең оешу датасы якынча 1655 ел дип уйларга мөмкин. Һәм тарихтан да беләбез – Кама артында оешкан авыллар нәкъ шул чорга карый.

XVIII гасыр азагында ясалган ревизия документларында авыл «Кади. Утыз Имән» дип теркәлгән. 1754 елда биредә туган атаклы мәгърифәтче, шагыйрь һәм фәлсәфәче Габдерәхим авылның исемен үзенә псевдоним итеп ала. Димәк, ул чагында авылның Утыз Имән атамасы булган.

Төбәкне өйрәнүче тарихчылар белә – бу якларда чувашлар 1650 нче елларга кадәр үк яшәгән. Казан ханлыгы җимерелгән чорда, Казан янынннан качкан беренче мөһаҗирләр булырга бик мөмкин. Утыз Имән менә шул чорлардан калган исем булырга тиеш.

2000 елның июнендә Яңа Кади авылына Габдерәхим Утыз Имәнинең исемен мәңгеләштерү максатыннан аның элеккеге исеме кайтарыла.

(Авыл кешеләре сөйләгәннәрдән).



ГАГАРИННЫ КҮРГӘН

Руфия Фазылова

– Бу фотоны ясаганда, Юрий Гагарин җиргә төшеп, санаулы минутлар гына узган, әле битендәге тирләре дә кипмәгән иде,– дип планетаның беренче космонавтына бәйле истәлекләрне яңартты Данил абый Сәләхетдинов. 1961 елның 12 апреле аның хәтерендә гомерлеккә калган. Хәер, гаҗәп тә түгел, галәмнән «кайтып килүче» кешене үз күзең белән күр әле!

«ГАДИ СОЛДАТЛАР ИДЕК»

Данил абый тумышы белән Арча районы Әзәк авылыннан. Гомеренең күбрәк өлеше исә Әтнә район үзәгендә узган. Кырык елдан артык мөгаллимлек стажы бар. Күптән түгел сиксән ике яшен тутырган.

– Әтине хәтерләмим диярлек, миңа өч яшь чагында сугышка киткән дә шуннан кайтмаган,– диде Данил абый. – Без дүрт бала үстек, мин төпчеге. Апа-абыйларым дөньялыкта юк инде, әйбәт кешеләр иде. Өчебез укытучы һөнәрен сайладык, әниебез моңа бик сөенеп яшәде...

Данил абый укытучы һөнәрен үзләштергәнче өч ел Саратов өлкәсенең Энгельс шәһәре янында армиядә хезмәт итә. 108 минут дәвамында галәмне әйләнгән беренче космонавт белән очрашу да нәкъ шунда була.

– Хәрби хезмәткә 1959 елда чакырылдым, – дип хәтер йомгагын сүтте әңгәмәдәшем. – Энгельс шәһәре янында беренче классслы хәрби аэродром иде. Без аның көньягын сакладык. Терновка авылы тирәсе... Аэродромны солдатлар төньяк, көнчыгыш, көнбатыштан да саклады. Без килгәндә әлеге Терновка авылы янында дала гына иде, казармаларны өр-яңадан үзебез салдык.

Әнә шулай тыныч кына хезмәт иткән көннәрдә Данил абый олы вакыйганың чын шаһиты булып куя!

– 1961 елның 12 апреле иде, – дип сүзен дәвам итте ул. – Көндезге унбер тулып киткәндер. Без, солдатлар, гадәттәгечә ракета чистартабыз. Дөресен генә әйткәндә, башка әллә ни эш тә юк иде. Кыш көне кар көрибез, яз көне су ерабыз... Безнең бит төп эш – аэродромны дошманнан саклау. Каравыл, ашарга пешерү – алары инде көн саен

Фото: Александр Ефремов

чиратка салынган. Ул көн дә энә шундый гадәти булырга тиеш иде. Берзаман колакка әллә нинди ят тавыш ишетелде, аптырап киттек. Энгельс шәһәреннән самолетлар көн-төн оча, аңа күнеккән, тик бу самолет тавышы түгел иде. Шуннан күккә карадык, еракта ике парашют төшеп килә. Ул бездән берәр чакрым ераклыкта иде, шуңа да анык кына аңлашылмады. Ике-өч минут уздымы икән, солдатлар арасында: «Гагарин төшкән»,- дигән сүз таралды. Дивизия командиры, машинасына утырып, тиз генә шул якка китте.

– Ә сез бу вакытта Юрий Гагаринның космоска очканлыгын ишеткән идегезме соң? – дим.

– Әйе, радиодан космоска беренче кеше очты, дип әйттеләр. Тик бу хакта алай озак сөйләшкәнне хәтерләмим. Гагарин Саратов өлкәсенә түгел, Волгоград өлкәсенә төшәргә тиеш булган. Шуңа күрә бу вакыйга безнең өчен генә түгел, командирлар өчен дә көтелмәгән хәл булды.

Озак та үтми, яңа гына галәмнән төшкән Юрий Гагаринны солдатлар янына алып киләләр, дөресрәге, хәрби частька. Иң беренче эш итеп космонавт командир бүлмәсендәге телефонны җыя. Гагаринның сөйләшүен ачык ишеткән барысы да, шул исәптән солдатлар да, ишетеп тора:

– Никита Сергеевич, Юрий Алексеевич бу. Партия биремен үтәдем, мин җирдә! – ди.

Телефон чыбыгының икенче очында Хрущевның ни әйткәнен солдатлар ишетми, әмма космонавт командир бүлмәсеннән бик күтәренке кәеф белән чыга. Ул да түгел, берсе фотоаппарат белән йөгереп килә. Юрий Гагарин дивизия командиры, рота солдатлары белән бергә фотога төшә.

– Ә Гагаринның үзе белән сөйләштегезме? Космонавтның кәефе ничек иде? – дим.

– Безнең янга килгәндә Гагарин әле каскасын да салмаган, битендәге тирләре дә кипмәгән иде. Ботинкасында нәрсәдер бар дип күрдем, җиргә төшү өчен уңайлы итеп ясалган иде алар. Ә сөйләшүгә килгәндә, барыбыз да уратып алдык аны. «Галәмдә куркыныч булмадымы?» – дидек. «Төрле чак булды», – дип кенә җавап кайтарды ул. Ләкин тарихка керәчәк бу очышы турында бүтән сүз әйтмәде. Күрәсең, ярамагандыр... Озакламый Энгельстан вертолетлар, самолетлар килеп җитте. Берсе төшеп, тиз генә Гагаринны утыртып алып та китте.

– Сезнең өчен Гагарин ул мәлдә герой идеме? – дим.

– Ул чакта бу хәлләрне тулысынча аңлап җиткермәгәнбез, дип уйлыйм. Бик тиз, көтмәгәндә килеп чыкты бит. Һәм шулай ук китеп тә барды, ай күрде – кояш алды дигәндәй, талчыккан иде дип истә калган.

КАВЫШУ

Данил абый хәләл җефете Фирадия апа белән ун ел элек Энгельс шәһәренә барып кайткан. Белгәнебезчә, Саратов өлкәсендә Гагарин төшкән урында мемориаль таш куелган. (Гомумән, Саратов өлкәсендә Юрий Гагарин исемен еш очратырга мөмкин).

– Хезмәт иткән урыннарны карап, яшьлек эзләре буйлап йөреп кайттык, – диде Данил абый.

– Бик матур ясаганнар анда, – дип сүзгә кушылды Фирадия Сабирова. – Скафандр кигән Гагарин сыны да балкып тора. Аллея да ясаганнар. Чиста, бик тәртипләп тоталар икән. Яшьләр өйләнешкәч шунда бара, диделәр.

– Данил абый хезмәт иткән хәрби часть бармы соң? – дим.

– Юк, аны бетергәннәр. Ул бит хәрби аэродромны саклар өчен оештырылган полк булган. Аэродромы булмагач, сакларга да кирәк түгел...

Аралаша торгач, ир белән хатынның гаилә тарихы турында да сүз чыкты. Икесенең дә икенче никахлары икән. Икесе дә гомер иткән парларын югалткан – тол калганнар. Бергә кавышып яши башлауларына унҗиде ел тулган.

– Безне уртак дустыбыз таныштырды, – дип елмайды Данил абый. – Фирадия миннән нәкъ ун яшькә кечерәк. Ул вакытта Биектау районы Дөбьяз авылында балалар бакчасы мөдире булып эшли иде. Эштән соң өенә алып кайттым. Берәр сәгатьләп сөйләшеп утыргач: «Син минем турында барысын да беләсең, мин синең турында. Бик ошаттым үзеңне, әгәр син дә ошатсаң, әйдә, никах укытабыз», – дидем.

Фирадия апа җавабын ул көнне үк әйтми. Өенә кергәч, барысын да төпләп уйлый. Гомер иткән йортыңны, авылны ташлап, Әтнәгә чыгып китү уен эш түгел бит. Икенче көнне Данил абый янә килә...

– Иремнең үлемен бик авыр кичердем, – диде Фирадия апа. – Матур яшәдек без. Ике ул үстердек. Мактаулы укытучы иде. Данилның да укытучы булуы күңелгә хуш килде – димәк, тәрбияле. Шуңа да кияүгә чыгарга ризалык бирдем. Ялгыз яшәү бик авыр бит. Аллага шөкер, Данил ипле, аңлашып яшибез. Әллә кайчан белгән кешем кебек. Дөнья шулай икән ул...

Данил абый оста йөзүче, заманында спорт мастерлыгына кандидат исемен алган. Шуңа өстәп чаңгычы да. Тик бернечә ел элек инфаркт булган, хәзер инде әлеге шөгыльләрне ташлаган. «Суга билдән генә керәм дә, азрак торгач, чыгып китәм», – ди. Бүген Данил абый фәкать акыл белән бәйле ярышларга – шахмат, шашка турнирларына бара, призлы урыннар алып кайта. Әтнәдә аны белмәгән кеше юк – кырык ел Әтнә авыл хуҗалыгы техникумында физкультура укыткан. Мәктәптә эшләү тәҗрибәсе дә бар.

– 1971 елда КДПИның физкультура факультетын тәмамладым, – диде Данил абый. – Шуннан өч ел Биектау район Татар Әйшәсе мәктәбендә укыттым. Аннан Әтнә районының Күңгәр мәктәбенә күчтем. Ә калган кырык елны студентлар белән эшләдем.

Данил абыйның да ике улы бар. Икесе дә Әтнәдә яши. Олы улы отставкадагы полковник, икенчесе – дизайнер. Балалар хәл белергә төп йортка еш килеп тора. Гомер көзендә кавышкан ир белән хатын энә шулай матур гына гомер кичерә. Алар өчен сөенеп кайттык.

АЙ КӘЕФЕ: КОСМОС

ГАЛӘМГӘ СӘЯХӘТ

Ел саен 12 апрельдә илебез Космонавтика көнен билгеләп үтә. «Татарстан» үз гомерендә 101 тапкыр «галәмгә сәяхәт кылды»:

- 1961 елның мартында галәмгә күтәрелгән Чернушка атлы эт төшеп утырган Иске Тәкмәк авылына;
- Чернушкага һәйкәл куелган Зәйгә;
- Казанның аэрокосмик юнәлешле 35 нче мәктәбенә;
- Телескопта йолдызлы күкне күзәтеп була торган Энгельгардт исемендәге обсерваториягә;
- Бөгелмә космонавты Рыжиков янына – космик корабта аның нинди китаплар укуын белештек...

Тагын әле:

- «Гагарин» исемле кешесыман робот белән көнүзәк темаларга әңгәмә кордык;
- Айда Казан белән бәйле дистә ярым чамасы урынны санадык;
- Совет чорының «Луна-1» планетара станциясенең 60 еллык юбилеенда йөрдек;
- Язучы Ярослав Хотеев белән Марста «космик якорь» ташладык;
- Казанлы Сергей Сушков белән бергә «сукыр тычкан оялары» буйлап сәяхәт иттек;
- Казанның яшь галимнәре белән бергәләп космосны яуладык;
- Базарлы Матакның сәүдәгәрләр-космос музеенда сәүдәгәрле борынгы заман белән космослы бүгенге көн арасында бәйләнеш эзләдек;
- Кама Тамагы районында Юрий Гагаринны уха белән сыйлаган пешекчене эзләп таптык һәм шундый ук балык шулпасын авыз иттек...

Фото facebook.com/antoniadigeorge, aznakaevo-rt.ru битләреннән алынды

Быелгы космик апрельдә «Татарстан» кая юл тотты дип уйлыйсыз?

Әлбәттә, Азнакайга. Андагы җирле аэродромда урнашкан коллектив яшьләр радиостанциясендә космик элемтә сеансы узды. Аны радиостанция җитәкчесе Ринат Вәлиев оештырды. Яшь азнакайлылар бу вакытта нәкъ менә Азнакай өстеннән очып барган космонавт Антон Шкаплеровка белән Олег Артемьевка сораулар бирде.

– RC4P – Роман-центральная-четыре-Павел... Рэди-Чарли-фор-папа... – радиостанциянең чакыру сигналы бу. Беренче булып «Татарстан» журналының соравы яңгырый. Космонавтларга аны яшь хәбәрчебез – 15 яшьлек Софья Туманская бирә:

– Фантастик фильмнарда космоска космонавтлар белән бергә роботлар да оча. Сезнеңчә ничек, шундый көннәр тиздән килеп тә җитәчәкме һәм сез янәшәгездә нинди роботны күрергә теләр идегез?

– Көн саен станцияне җыештырырга ярдәм итә торган роботны күрәсе килә, – дип җавап бирә Антон Шкаплеров.

Аннары инде сораулар бер-бер артлы сибелеп кенә тора башлый, аларны Азнакайдагы «Маяк» газетасының яшь хәбәрчеләре яудыра:

– Космоска очачагыгызны белгәч, әниегез нәрсә диде?

– Әнием бик сөенде, чөнки бу хакта балачактан ук хыяллана идем.

– Сезгә метеоритлар якын арадан күренәме һәм Халыкара космик станцияне алар белән бәрелешүдән ничек саклап калырга була?

– Метеоритлар якын арадан күренми, әлбәттә. Әгәр без аларны күргәнбез икән, Җиргә бөтенләй әйләнеп кайтмавыбыз да бар.

– Сезгә космонавт булу ошыймы?

– Ошый, бу – бик кызыклы эш.

– Кешеләр ни өчен Айга төшеп утырмый?

– Кешеләр Айга оча бит. Американың 12 астронавты инде Айда булырга өлгерде. Чиратта сез булырсыз дип өметләнәм.

– Әгәр бер малай авыру сәбәпле начар йөри икән, сезнеңчә, космоста аңа йөрү җиңелрәк булыр идеме?

– Биредә нигездә куллар, бик көчле куллар кирәк.

– Имгәнү очракларыгыз булганы юкмы, һәм сездә ашыгыч ярдәм бармы?

– Ашыгыч ярдәм юк, әмма без теләсә кайсы очракта үз-үзебезгә ярдәм итә алыр өчен әзерлек узабыз.

– Туганнарыгыз белән ничек элемтә тотасыз?

– Видеоканал аша. Бу – Җирдәге скайп кебегрәк.

– Космоста ризыкларыгыз нindирәк?

– Бик тәмле, ул сезгә бик ошар иде. Бердәнбер нәрсә – чәкчәк кенә юк. Шуңа күрә сезгә кунакка килеп, чәкчәктән авыз итеп карыйсы килә.

– Космоста үсемлекләр тизрәк үсә дигән сүз дөресме ул?

– Мин моны сизмәдем. Без төрле селекция тикшеренүләре үткәрәбез һәм космоста үсә ала торган үсемлекләрне сайлыйбыз.

– Галәмдә тузан бармы?

– Әйе, без аны тузан утырган өслекләрдә күрә алабыз.

– Халыкара космик станциянең эчендә һәм аның тышкы ягында нинди температура?

– Эчтә – 24 градус тирәсе, бортның теге ягында – яктылык дәрәҗәсенә бәйле. Әгәр без караңгы якта икән, бу минус 150 градус дигән сүз. Кояш тарафында – плюс 150 градуска кадәр.

– Галәмдә курку хисе туганы бармы?

– Бөтен куркулар Җирдә кала.

– Халыкара космик станциядә чәчне ничек алалар?

– Гравитация вакытында без махсус чәчалгыч кулланабыз.

– Янгын чыга калса, ниләрне эшлисез?

– Гап-гади эшләрне. Безгә ул янгынны сүндерергә кирәк.

– Космоста ничек йоклыйлар?

– Һәркемнең үз каютасы бар, шунда йоклыйбыз.

– Кешеләр космоска нигә оча?

– Запас планетабыз булсын өчен.

Яшь азнакайлыларга Халыкара космик станция экипажы әгъзалары Антон Шкаплеров, Олег Артемьев, Петр Дубров, Денис Матвеев һәм Сергей Корсаков белән реаль вакыт режимында сөйләшү мөмкинлеге Ринат Вәлиев тырышлыгы белән инде бишенче тапкыр тудырыла. Балалар мондый очрашуларга алдан әзерләнә, сораулар уйлап табалар, репетиция ясыйлар, барысы да үз сорауларын бирергә өлгерсен өчен, һәр сүзне секундлап саныйлар, чөнки космик интервьюга нибары ун минут вакыт бирелә – нәкъ менә шулкадәр вакыт эчендә Халыкара космик станция Татарстан өстеннән очып уза.

– Яшь буын өчен мондый очрашулар аерым әһәмияткә ия. Кайберәүләргә, бәлки, мондый әңгәмәләр киләчәктә һөнәр сайларга да ярдәм итәр әле, – дип, үз фикерен белдерә Ринат Вәлиев.

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама